# 1нче бүлек. Фәлсәфәгә кереш.

1нче сорау. Дөньяга караш буларак фәлсәфә.

*1. Дөньяга караш турында гомуми төшенчә һәм аның төрләре.*

Дөньяга тулы караш һәм анда кешенең урыны. Кешелек тарихында билгеләнгән өч төп дөньяга караш формасы

Мифология

Дин

Фәлсәфә

*2. Дөньяга караш буларак фәлсәфә.*

Мифология – әйләнә-тирә чынбарлыкны фантастик һәм шул ук вакытта реалистик кабул итүне үзендә берләштергән иҗтимагый аң формасы.

Мифлар җавап бирергә тырышкан төп мәсьәләләр:

*Галәм, Җир шары һәм кеше барлыкка килүе;

*табигать күренешләрен аңлату;

*кешенең яшәеше, язмышы һәм үлеме; кешенең эшчәнлеге һәм казанышлары

* намус, бурыч, этика һәм әхлак мәсьәләләре.

Миф сыйфатлары:

*табигатьне сынландыру;

*фантастик Аллалар барлыгы, аларның кеше белән аралашуы, үзара бәйләнеше

*абстракт фикерләр юклыгы (рефлекция)

*мифларның конкрет тормыш мәсьәләләрен (хуҗалык, табигать көчләре һ.б.) хәл итүгә юнәлдерелүе;

* Бертөрлелек һәм мифологик сюжетларның сайлыгы.

## *3. Дөньяга караш буларак дин*

**Дин — кеше гомеренә һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясаучы фантастик, гадәттән тыш көчләр булуына ышануга нигезләнгән дөньяга караш формасы. Дини дөньяга караш булганда әйләнә-тирә чынбарлыкны кешегә хисси, образ-тойгылы (рациональ түгел) кабул итү хас. Дин миф тикшергән үк мәсьәләләрне тикшерә.**

Дөньяның төп диннәре:

* христиан дине

* ислам

* буддизм

Дөньяда киң таралган һәм эре милли диннәр:

*синтаизм

* индуизм

* иудаизм

Дин функцияләре (дөньяга караштан соң):

*берләштерүче (җәмгыятьне идея тирәсендә яки идея хакына бергә туплый)

*культурологик (билгеле бер мәдәниятка таратуга булыша, мәдәниятка йогынты ясый)

*әхлакый-тәрбияви (җәмгыятьтә якыныңа мәхәббәт, аны кызгану, намуслылык, сабырлык, тәртиплелек, бурыч кебек идеалларны тарата.

## *4. Дөньяга караш буларак фәлсәфә*

Фәлсәфә — үзгә бер, фәнни-теоретик дөньяга караш. Ул рациональлеге, системалылыгы, мантыйклыгы һәм теоретик оешканлыгы белән аерылып торган югары дәрәҗәле һәм дөньяга караш төрен гәүдәләндерә.

Фәлсәфи дөньяга карашның дини һәм мифологик дөньяга караштан аермасы:

- белемгә нигезләнгән (ә ышануда яки уйдырмада түгел);
- рефлексив (уйның үз-үзенә юнәлтелгән булуы);
- мантыйклы (эчке берлек һәм системага ия);
- төгәл төшенчә һәм категорияләргә таяна

Дөньяга караш буларак фәлсәфәнең төп эволюция стадияләре:

*Космоцентризм* — нигезендә әйләнә-тирә мохитне, табигать күренешләрен югары көч - Галәмнең (космос) бөеклеге, куәтлелеге, чиксезлеге аша аңлату яткан фәлсәфи дөньяга караш һәм аңа ярашлы, барлык тереклек Галәмгә һәм галәм циклларына бәйле (бу фәлсәфә Борынгы Һиндстан, Борынгы Кытайга, башка Көнчыгыш илләренә, шулай ук Борынгы Грециягә хас).

*Теоцентризм* - нигезендә барлык тереклекне аңлатып биреп булмый торган, гадәттән тыш көч - Алла яткан фәлсәфи дөньяга караш төре (урта гасыр Европада таралган була).

*Антропоцентризм* — үзәгендә кеше мәсьәләсе торган фәлсәфи дөньяга караш төре (Яңарыш чоры Европасы, яңа һәм өр-яңа вакыт, хәзерге фәлсәфә мәктәпләре).

# 2нче сорау. Фәлсәфә белеменең үзенчәлеге.

## Фәлсәфә белеменең үзенчәлекле сыйфатлары

- Фәлсәфә белеменең төп үзенчәлеген аның ике төрлелегендә, чөнки аның фәнни белем белән уртаклыгы күп, шулай да ул саф төрдәге фәнни белем була алмый.
- Фәлсәфәнең башка фәннәрдән төп аермасы аның теоретик дөньяга караш булуына,кешелек тарафыннан алда туплаган белемнәрне гомумиләштерүдән тора.
- фәлсәфә фәне теләсә кайсы аерым фән тикшерүләре предметыннан киңрәк, фәлсәфә гомумиләштерә, башка фәннәрне тулыландыра, әмма аларны йотмый, бөтен фәнни белемне үзенә алмый, аның өстендә тормый.
- катлаулы структурага ия (онтология, гносеология, мантыйкны һ.б. үзенә кертә);
- бик нык гомуми, теоретик характерда;
- башка фәннәр нигезендә ятучы база, нигез булып торучы идеяләре һәм төшенчәләренә ия;
- күпчелек субъектив — үзендә аерым шәхес эзе һәм аерым фәлсәфәчеләр карашлары бар;
- объектив белем һәм кыйммәтләр, үз заманының әхлакый идеаллар җыелмасы булып тора, үзендә чор йогынтысын сыный;
- танып белү предметын гына түгел, танып белүнең үз механизмын да өйрәнә;
- үз-үзен тикшерү сыйфаты бар — фикернең үз-үзенә мөрәҗәгате хас (ягъни белем предметлар дөньясына да, үзенә дә мөрәҗәгать итә);
- алдагы фәлсәфәчеләр эшкәрткән доктриналар йогынтысын үзендә тоя;
- шул ук вакытта хәрәкәтчән — даими үсә һәм яңарып тора;
- категорияләргә таяна — бик нык гомуми төшенчәләр;
- асылы белән иксез-чиксез;
- кешенең танып белү сәләтләре белән чикләнгән (танып белүче субъектның), бүгенге көнне мантыйк юлы белән дөрес хәл ителә алмаган хәл итеп булмаслык, «мәңгелек» проблемаларга ия (яшәеш барлыкка килүе, материя яки аңның беренчеллеге,яшәешнең барлыкка килүе, җанның үлемсезлеге, Алла булуы яки булмавы, аның дөньяга булган йогынтысы.

3нче сорау. Фәлсәфә фәне һәм методы.

## *1. Фәлсәфә фәненең эчтәлеге*

### Фәлсәфә фәне

**Фәлсәфәнең төп бүлекләре:**

- онтология (яшәеш турындагы тәгълимат);
- гносеология (аң турындагы тәгълимат);
- кеше;
- җәмгыять.

Дүрт төп фәлсәфә бүлеге кысаларында өйрәнелгән аерым сораулар:

* яшәеш асылы;
- яшәешнең барлыкка килүе;
- материя (субстанция), аның формалары;
- аң,аның барлыкка килүе һәм табигате;
- материя һәм аңның үзара мөнәсәбәте;
- аңсызлык;
- кеше, аның асылы һәм яшәеше;
- җан, кешенең рухи дөньясы;
- җәмгыять;
- җәмгыять һәм кеше;
- табигать;
- табигать һәм җәмгыять;
- җәмгыять тормышының рухи өлкәсе;
- җәмгыять тормышының матди-икътисадый өлкәсе;
- җәмгыятьнең социаль өлкәсе;
- иҗтимагый-икътисадый формацияләр, цивилизацияләр;
- кеше, җәмгыятьнең киләчәге;
- экология, исән калу проблемасы;
- танып белү үзенчәлеге;
- танып белүче субъектның танып белү процессына йогынтысы һәм аның нәтиҗәсе;
- аңның чикләнгәнлеге һәм чиксезлеге;
- хәрәкәт;
- фәлсәфә категорияләре;
- диалектика һәм аның законнары;
- башка сораулар.

## 2.Фәлсәфә методларының гомуми төшенчәсе һәм эчтәлеге

Фәлсәфә методлары – фәлсәфә тикшеренүләрен тормышка ашыручы юллар, чаралар

Фәлсәфәнең төп методлары: Диалектика - фәлсәфә тикшеренүе методы, ул булганда әйберләр, күренешләр, аларның эчке каршылыкларын, үзгәрешләрен, үсешен, сәбәп һәм нәтиҗәләрен, берлеген һәм каршылыклар көрәшен исәпкә алып сыгылмалы, тәнкыйди, эзмә-эзлекле итеп карала.

Метафизика — диалектикага капма-каршы метод, бу методта объектлар аерымланып карала, мөстәкыйль итеп (ә үзара элемтә карашы ягыннан түгел) ; хәрәкәтсез (даими үзгәрешләр, үзхәрәкәт,үсеш фактларын игътибарга алмый); бер мәгънәле (абсолют (чикләнмәгән) хакыйкать эзләү бара, каршылыкларга игътибар ителми, аларның берлегенә төшенелми).

Догмачылык — әйләнә-тирә дөньяны догмалар призмасы аша үзләштерү — бер һәм мәңгелеккә кабул ителгән, исбат ителмәслек, «югарыдан бирелгән" һәм абсолют характердагы йөреткән караш. Әлеге метод урта гасыр теология фәлсәфәсенә хас.

Эклектика — аерым-аерым , бердәм иҗади факт, төшенчә, концепция башлангычларын ирекле берләштерүгә нигезләнгән метод, аның нәтиҗәсендә сай, әмма тыштан чынга ошаган, ышанычлы тоелган нәтиҗәләргә ирешелә. Еш кына эклектика масса аңын җәлеп итә торган нинди дә булса карашларны, идеяләрне нигезләү өчен кулланыла, әмма ни онтологик, ни гносиологик реаль кыйммәте һәм дөреслеге юк (урта гасырларда – диндә, хәзерге заманда — рекламада).

Софистика — ялган, әмма оста һәм ялгыш дөреслек дип тәкъдим ителгән фикер, яңа юнәлеш, мантыйк ягыннан чын, тик бу методны кабул итүче өчен эчтәлеге белән ялган булган метод. Софистика Борынгы Грециядә таралу ала, хакыйкать табуны максат итеп куймый, ә бәхәстә җиңү, «теләсә ни, теләсә кемгә» дәлилләүне һәм ораторлык сәнгате ысулы итеп кулланыла.

Герменевтика — текстлар эчтәлеген дөрес уку һәм аңлату методы. Көнбатыш фәлсәфәсендә киң таралган.

Бер үк вакытта фәлсәфә юнәлешләре булган фәлсәфә методлары:

Материалистик метод, чынбарлык реаль итеп кабул ителә, материя - беренчел субстанция буларак, ә аң - аның модусы(төрчәсе) -материянең чагылышы. (Материалистик-диалектик метод совет фәлсәфәсендә хакимлек итә һәм хәзерге Россиядә киң таралыш алган).

Идеалистик, метод асылы — идеяне башлангыч сыйфатында һәм аның көчен билгеләүче итеп тану, ә материя — идея чыгармасы буларак, аның гәүдәләнеше итеп. Идеалистик метод аеруча АКШта һәм Көнбатыш Европа илләрендә (мәсәлән, Германиядә) киң таралган.

Эмпиризм — танып белүдәге метод һәм юнәлеш, аңа ярашлы танып белү процессы, белем нигезендә хисси танып белү нәтиҗәсендә алынган тәҗрибә ята. («уй-фикерләрдә моңа кадәр тәҗрибә һәм хисси тойгыларда булмаган бернәрсә дә юк".)

Рационализм — фәлсәфәдәге фәлсәфи метод һәм юнәлеш, аңа ярашлы хак, абсолют дөрес белемгә бары тик акыл ярдәмендә генә ирешеп була (ягъни акылның үзеннән чыгарыла) тәҗрибә һәм тойгылардан башка (барысын да шиккә алырга мөмкин, ә теләсә кайсы шик — ул инде фикер, акыл эше.)

# 4нче сорау. Фәлсәфә функцияләре

Фәлсәфә функцияләре — максаты, бурычы, билгеләнеше башкарыла торган фәлсәфәне куллануның төп юнәлешләре.

**Дөньяга караш функциясе** дөнья турында тулы күзаллау формалаштыруга ярдәм итә, аның төзелеше турында, кеше урыны, әйләнә-тирә мохит белән үзара элемтә принциплары турында күзаллау.

**Методологик функциянең асылы** фәлсәфәнең әйләнә-тирә чынбарлыктагы танып белүнең төп методларын эшкәртеп чыгаруыннан гыйбарәт. (карагыз 3нче сорау «Фәлсәфә фәне һәм методлары» философии")

**Фикер йөртү-теоретик функция** түбәндәгедән гыйбарәт: фәлсәфә концептуаль фикерләргә һәм теоретик мәсьәләләр турында фикер йөртергә өйрәтә — әйләнә-тирә чынбарлыкны бик нык гомумиләштерергә, фикер-мантыйк схемалар, әйләнә-тирә дөнья системасын төзергә өйрәтә.

**Гносеологик** — төп нигез салучы функцияләрнең берсе — әйләнә-тирә чынбарлыкны дөрес һәм чын итеп танып белүне максат итеп куя (ягъни танып белү механизмы).

**Критик функция роле** -әйләнә-тирә дөньяны һәм булган белемнәрне шик астына алу, аларның яңа сыйфатларын, үзенчәлекләрен эзләү, каршылыкларын ачу. Ахыргы бурычы — танып белү чикләрен киңәйтү, догмаларны чишү, белемнең катып калуын, аны модернизацияләү,белемнең дөреслеген арттыру.

**Аксиологик функция** (грек теленнән *axios — кыйммәтле*) әйберләрне, әйләнә-тирә дөнья күренешләрен төрле кыйммәтләр күзлегеннән - мораль-әхлак, этика, социаль идеологик һәм башка кыйммәтләрне бәяләүдән гыйбарәт. Максаты — «иләк» булу, аның аша кирәкле, кыйммәтле һәм файдалыны үткәреп, тоткарлаган, гомере узганнарны алып калу. Аксиологик функция аеруча тарихның борылышлы вакытларында көчәя (урта гасыр башы — Рим җимерелгәч яңа (теологик) кыйммәтләр эзләү; Яңарыш чоры; Реформация; XIX гасыр ахыры— XX гасыр башындагы капитализм кризисы һ.б.).

**Социаль функция** — җәмгыятьне, аның барлыкка килү сәбәпләрен аңлату, эволюция, хәзерге торышы, структурасы, элементлары, хәрәкәт итүче көчләре; каршылыкларны ачу, аларны юк итү яки йомшарту юлларын күрсәтү,җәмгыятьне камилләштерү.

**Тәрбияви-гуманитар функция** гуманистик кыйммәтләрне һәм идеалларны тарату, аларны кешедә һәм җәмгыятьтә тәрбияләү, әхлакны ныгытуга ярдәм итү, кешегә әйләнә-тирә мохиткә өйрәнергә һәм гомеренең мәгънәсен табарга булышудан гыйбарәт.

**Прогностик функция әйләнә-тирәдәге дөнья һәм кеше турындагы** булган фәлсәфи белемнәре, танып белү юнәлеше казанышлары нигезендә, материя, аң, белем алу процесслары, кеше, табигать һәм җәмгыять киләчәген прогнозлаудан гыйбарәт.

## 5нче сорау. Фәлсәфәнең төп мәсьәләләре һәм төп юнәлешләре

### *1.Фәлсәфәнең төп мәсьәләсенә гомуми төшенчә,аның яклары*

**Фәлсәфәнең төп мәсьәләсе итеп гадәттә фикерләүнең яшәешкә, ә яшәешнең фикерләүгә (аңга) карата мөнәсәбәте мәсьәләсе дип исәпләнелә.**

**Төп мәсьәләнең ике ягы**

Үзенчәлекләре:

Бу мәсьәләнең мөһимлеге аның дөрес хәл ителүеннән чыгып, әйләнә-тирә мохит һәм анда кеше урыны турында тулы белем төзелә, ә бу фәлсәфәнең төп мәсьәләсе булып тора.

Материя һәм аң (рух) — ике аерылгысыз һәм шул ук вакытта капма-каршы яшәешнең сыйфатланышы. Моның белән бәйле ике як яшәп килә — онтологик һәм гносеологик.

Онтологик һәм гносеологик якларга бәйле төп юнәлешләр булеп чыгарыла — аңа ярашлы материализм һәм идеализм, шулай ук эмпиризм һәм рационализм.

Онтологик (яшәеш) як проблеманы куюда һәм хәл итүдән тора: нәрсә беренчел — материяме әллә аңмы?

Онтологик (яшәеш) якны караганда шундый юнәлешләрне бүлеп чыгарып була:

- объектив идеализм;
- субъектив идеализм;
- материализм;
- вульгар материализм;
- дуализм;
- деизм;

Гносеологик (танып белү) ягы: дөньяны танып белеп буламы яки танып белеп булмыймы, танып белү процессында нәрсә беренчел?

гносеологик (танып белү) ягы:

- гностицизм;
- агностицизм;
- эмпиризм (сенсуализм);
- рационализм.

## 2. Фәлсәфәнең төп мәсьәләсенең онтологик ягы

**Материализм ("Демокрит линиясе« дип аталучы)** — фәлсәфә юнәлеше, аның яклылар материя һәм аң мөнәсәбәтендә материя беренчел дип исәпләгәннәр.

Төп фикерләре:

• материя чынлап та бар;

• материя аңга бәйсез рәвештә яши (ягъни фикер йөртүче тереклекләрдән бәйсез рәвештә һәм аның турында кем булса да фикер йөртәме юкмыга карамыйча яши);

• материя мөстәкыйль субстанция булып тора — үзеннән башка бернигә дә мохтаҗ түгел;

• материя үзенең эчке законнары буенча яши һәм үсә;

• аң (рух) югары оештырылган материянең үз-үзен (материяне) гәүдәләндерү үзенчәлеге (модус) ул;

• аң материя белән янәшәдә яшәп килә, мөстәкыйль субстанция түгел;

• аң материя (яшәеш) белән билгеләнә.

Үзенчәлекләре:

Материалистик юнәлешкә Демокрит; Милет мәктәбе фәлсәфәчеләре (Фалес, Анаксимандр, Анаксимен); Эпикур; Бэкон; Локк; Спиноза; Дидро һәм башка француз материалистлары; Герцен; Чернышевский; Маркс; Энгельс; Ленин кебек фәлсәфәчеләр карады.

Материализмның яхшы яклары — фәнгә таяну, аеруча төгәл һәм табигать фәннәре (физика, математика, химия һ.б.), күпчелек материалистларның кагыйдәренең мантыйк ярдәмендә дәлилләнүе.

Материализмның йомшак ягы — аң асылы тиешенчә аңлатылуы, материалистик караштан аңлатып булмый торган әйләнә-тирә дөньядагы күренешләр булуы.

Материализмда үзгә бер юнәлеш бүлеп чыгаралар — вульгар материализм. Аның вәкилләре (Фохт, Молешотт) материя ролен абсолютлаштыра, материяне физика, математика һәм химия карашыннан тикшерү белән шөгыльләнәләр, аның механик ягын, узаңны асыл буларак инкарь итәләр һәм аның материягә җавап бирү мөмкинлеген инкарь итәләр.

Материализм фәлсәфәнең хакимлек итүче юнәлеше буларак демократик Грециядә, эллинистик дәүләтләрдә, буржуаз революция чоры Англиядә (XVII гасыр), СССР һәм XX гасыр социалистик илләрдә таралыш ала.

**Идеализм (" Платон линиясе")** — фәлсәфә юнәлеше, аның яклылар материя һәм аң мөнәсәбәтендә беренчел дип аңны (идея, рух) исәпләгәннәр.

Идеализмда бүленеп чыгарылган мөстәкыйль юнәлешләр

Объектив идеализм (Платон, Лейбниц, Гегель һ.б.);

Төп кагыйдәләр:

- чынбарлыкта тик идея генә яши;
- идея беренчел;
- барлык чынбарлык «идеяләр дөньясы”на һәм “әйберләр дөньясына” бүленә;
- «идеяләр дөньясы”(эйдослар) баштан ук Дөнья Акылында яши (Илаһи Ният һ.б.);
- “әйберләр дөньясына” — материаль дөньяның мөстәкыйль яшәеше юк һәм “әйберләр дөньясына” гәүдәләнеше булып тора;
- һәр аерым әйбер — әлеге әйбернең идеяләр гәүдәләнеше (эйдосның) (мәсәлән, ат — гомуми ат идеясе гәүдәләнеше, йорт- йорт идеясе, кораб - кораб идеясе һ.б.);
- «саф идея»не конкрет әйбергә әйләндерүдә зур рольне Тудыручы - Аллаһ уйный;
- аерым идеяләр ("идея дөньясы") безнең аңнан бәйсез рәвештә объектив яшәп килә.

Субъектив идеализм (Беркли, Юм).

Төп кагыйдәләр:

- барысы да танып белүче субъект (кеше) аңында гына яши;
- идеяләр кеше акылында була;
- материаль әйберләр образлары (идеяләр) хисси тойгылар аша шулай ук тик кеше акылында гына яши;
- аерым кешенең аңыннан тыш материя дә, рух (идеяләр) та юк.

Үзенчәлекләр:

Идеализмның йомшак сыйфаты — «саф идеяләр» булуы һәм «саф идея»нең конкрет әйбергә (материя һәм идея барлыкка килү механизмы) хакында дөрес (логик) аңлату булмавы.

Идеализм фәлсәфә юнәлеше буларак Платон Грециясендә, урта гасырларда хөкемлек итә, хәзерге вакытта АКШта, Германиядә, башка Көнбатыш Европа илләрендә киң таралган.

Фәлсәфә юнәлеше буларак дуализмга Декарт тарафыннан нигез салына.

Төп кагыйдәләр:

- ике бәйсез субстанция яши — материаль (дәвамлылык үзенчәлеге булган) һәм рухи (фикер йөртү үзенчәлеге булган);
- дөньяда барысы да чыгарылма (модус була) яки беренче яки икенче күрсәтелгән субстанциядән (материаль әйберләр — материальдән, идеяләр — рухидан);
- кешедә бер үк вакытта ике субстанция берләшә — материаль дә, рухи да;
- материя һәм аң (рух) — бер яшәешнең ике капма-каршы һәм үзара бәйләнешле яклары;
- фәлсәфәнең төп мәсьәләсе (нәрсә беренчел — материя яки аң) чынлыкта исә юк, чөнки материя һәм аң бер-берсен үзара тулыландаралар һәм һәрвакыт бар.

Деизм — фәлсәфә юнәлеше, аның яклылар (күбесенчә XVIII гасыр француз мәгърифәтчеләре) Аллаһ барлыгын таныйлар, ул, алар фикеренчә, бер тапкыр дөньяны барлыкка китереп, инде аның киләчәк язмышына катнашмый, һәм кешеләр тормышына һәм эшләренә йогынты ясамый (ягъни бернинди дә «вәкаләтләре» булмаган Аллаһны таныйлар,ул нибары әхлакый символ буларак хезмәт итәргә тиеш). Деистлар материяне күтәренке рухлы дип санаганнар һәм материя белән рухны (аңны) каршы куймыйлар.

# 3. Фәлсәфәнең төп мәсьәләсенең гносеологик ягы

Эмпиризм

Үзенчәлекләре

Эмпиризмга нигез салучы итеп Фрэнсис Бэкон исәпләнелә.

Эмпиристлар танып белү нигезендә тәҗрибә һәм хисси тойгылар гына була дип санаганнар. («Моңа кадәр тәҗрибә һәм хисси тойгылар да булмаган, берни дә фикерләрдә( акылда) юк").

Рационализм

Үзенчәлекләре

**Р. Декарт рационализмга нигез салучы** (от лат. *ratio* — разум) дип санала

Рационализмның төп идеясе хак(дөрес) белем тик акылдан гына чыгарыла ала һәм хисси тәҗрибәдән тормый.(Беренчедән,тик бар нәрсәдә шикләнү генә реаль булуы ихтимал, ә шикләнү — фикер-акыл эшчәнлеге. Икенчедән,акыл өчен бәхәссез һәм тәҗрибә белән дәлилләү таләп ителмәгән хакыйкать (аксиомалар) бар,— «Алла бар", «Квадратның почмаклары туры", «Бөтен аның өлешенә караганда зуррак" һ.б.)

**Иррационализм аерым юнәлеш сыйфатында бүленеп чыга** (Ницше, Шопенгауэр). Аңа ярашлы дөнья тәртипсез, буталчык, әчке мантыйгы юк, димәк, беркайчан да акыл белән танып бетерелмәячәк.

**Гностицизм вәкилләре** (гадәттәгечә, материалистлар)

Төп положениеләр

- дөньяны танып булмый;

танып белү мөмкинлекләре кеше акылы мөмкинлекләре белән чикләнгән

Агностицизм теоретикларына Иммануил Кант (1724 - 1804) та кергән. Кант фикеренчә, кеше акылы зур мөмкинлекләргә ия, тик аларның үз чикләре бар. Кеше акылының танып белү мөмкинлекләренең чикләнгәнлеге аркасында кеше беркайчан да җавабын белмәячәк табышмаклар (каршылыклар) бар. Мәсәлән, Аллаһ бар. Аллаһ юк. Кант барлыгы шундый дүрт каршылык (антиномияләр) бүлеп күрсәтә (карагыз 36 сорау "Иммануил Кант фәлсәфәсе ").
Тик Кант буенча, кешенең танып белү мөмкинлекләренә кергәннәр дә барыбер беркайчан да танып бетерлмәячәк, чөнки акыл әйберләрнең гәүдәләнешен хисси тойгылар аша гына таный ала, ләкин әлеге әйбернең әчке асылына төшенә алмаячак — «әйберләр үзендә».

Төп кагыйдәләр

- дөньяны танып булмый;

Танып белү мөмкинлекләре кеше акылы мөмкинлекләре белән чикләнә.

## *4. Фәлсәфәнең төп мәсьәләсенең хәзерге торышы һәм аның киләчәге*

Фәлсәфәнең төп мәсьәләсенең хәзерге торышы һәм аның киләчәге

Үзенчәлекләре

Хәзерге вакытта, фәлсәфәчеләрнең меңнәр ел эзләнүләренә карамастан, фәлсәфәнең төп мәсьәләсе онтологик яктан да, гносеологик яктан да дөрес хәл ителмәгән һәм шуңа да мәңгелек (хәл ителмәс) фәлсәфә проблемасы булып кала.

XX гасырда көнбатыш фәлсәфәсендә бу мәсьәләгә азрак игътибар ителә башланды, чөнки ул авыр хәл ителә һәм тора-бара үзенең көнүзәк булуын(актуальлеген) югалта.

Ясперс, Хайдеггер, Камю һ.б.лар киләчәктә башка төп мәсьәлә экзенстенциализм проблемасы барлыкка киләчәк дигән фикергә нигез салалар, ягъни кеше проблемасы, аның яшәеше, рухи дөньясы белән идарә итүе, җәмгыять эчендә һәм җәмгыять белән үзара мөнәсәбәте, аның ирекле сайлау мөмкинлеге, яшәү мәгънәсе һәм тормыштагы урынын эзләү, бәхете.

## ...нчы сорау: Кытай фәлсәфәсенең гомум төшенчәләре һәм характерлы сыйфатлары

## *1.Кытай фәлсәфәсенең төп этаплары һәм характерлы сыйфатлары*

Кытай фәлсәфәсе

- ✔ Кытай фәлсәфәсенең төп үсеш этаплары
- ✔ Безнең эрага кадәр VII гасыр – безнең эраның III гасыры - борынгы милли фәлсәфә мәктәпләре барлыкка килү
- ✔ Безнең эраның III – XIX гасырлары – Кытайга Һиндстаннан буддизмның үтеп керүе(б. э. III гасыры) һәм аның милли фәлсәфә мәктәпләренә булган йогынтысы;
- ✔ Безнең эраның XX гасыры – хәзерге этап – Кытай җәмгыятенең йомыклыктан чыгуы, Кытай фәлсәфәсенең Европа һәм дөнья фәлсәфәсе казанышлары белән баетылуы.

Кытай фәлсәфәсендә чагылдырылган дөньяны һәм әйләнә-тирә чынбарлыкны кытайларча күрү :

- ✔ үз илен кабул итү – Кытайны – яшәп килгән дөньяның үзәге

Ь

- ✔ аерем вакыйгаларны, тулы тарихны цикллы процесс буларак аңлау;
- ✔ галәм циклларын Җирдә тормышка дөрес ашыру өчен Күк һәм Җир алдындагы җаваплылыкны төшенү;
- ✔ кеше, табигать һәм галәмне бербөтен итеп кабул итү;
- ✔ Аң консерватизмы, үткәнгә юнәлдерелгәнлек, үзгәрешләрдән курку;
- ✔ Аерым кеше шәхесен коллективтан бүлеп карамау;
- ✔ Табигать көчләре белән (елга ташулар, гарасатларга һ.б.) көрәштә аерым кешенең көчсезлегенә төшенү; коллектив хезмәткә өстенлек бирү (Бөек Кытай стенасын, буалар төзү, каналлар казу, су ташулар белән көрәшү, сугару игенчелеге һ.б.); моңардан – оештыручы көч - дәүләт алдында хөрмәт һәм калтырану;
- ✔ Кеше шәхесен, коллективны, җәмгыятьне һәм дәүләтне бербөтен итеп кабул итү; җәмгыятьтә вертикаль элемтәләр таралуы(власть һәм буйсыну), субординация, начальникларны тыңлау, дәүләт башлыгын (императорны)дәүләтне берләштерүче югары көч итеп кабул итү, ә дәүләт – җәмгыятьне берләштерүче көч итеп, император, аның властен һәм вазыйфаны аллалаштыру;
- ✔ Мөнәсәбәтләрдәге конформизм, тынычлык һәм эшсезлеккә өстенлек;
- ✔ Тормышны иң элек тәнгә тәрелгән рух яшәеше итеп аңлау, теге дөньядагы тормышка караганда җирдәгесен өстен күрү, аерым кешенең гомерен Җирдә мөмкин кадәр озаккарак сузу омтылышы (үлән, физик күнекмәләр, дөрес яшәү рәвеше һәм әйләнә-тирә чынбарлыкка дөрес мөнәсәбәт ярдәмендә);
- ✔ теге дөнья көчләрен реаль итеп кабул итү, үлеләрне җанландыру;
- ✔ Ата-аналарга, өлкәннәргә хөрмәт, борынгы әби-бабаларны һәм рухларны

# 2.Кытайның төп милли фәлсәфи тәгълиматлары

***Кытайның төп милли фәлсәфи тәгълиматлары***

| Борынгы милли фәлсәфи тәгълиматлар | Азрак таралган тәгълиматлар | Кытайга буддизм үтеп кергәннән соң Кытай фәлсәфәсенең төп юнәлешләре (безнең эраның IIIгасыры) һәм XIX гасыр ахырына кадәр (Икенче этап) | XX гасырда милли кытай фәлсәфәсен баеткан дөнья фәлсәфи фикер казанышлары. |
|---|---|---|---|
| ✔ даосизм | ✔ моизм | ✔ Чань-буддизм (милли кытай буддизмы, кытай мәдәниятенең һиндстан буддизмына йогынты ясаудан килеп чыккан, Китай тарафыннан үзләштерелгән; | ✔ Христиан дине идеяләре |
| ✔ лонфуцианлык | ✔ натурфилософия | ✔ неодасизм | ✔ Марксизм идеяләре |
| ✔ легизм | ✔ номинализм | ✔ неоконфуцианлык | ✔ Алдынгы европа фәләсфәчеләре идеяләре |
| | | | ✔ Прогматизмның америка фәллсәфәчеләре идеяләре |

# 7нче сорау. Кытай фәлсәфәсендә һәм мифологиясендә кеше һәм әйләнә-тирә дөнья барлыкка килү проблемасы

**Кытай фәлсәфәсендә кеше проблемасы: Кытайда кеше табигать һәм галәм белән тиңләштерелсә дә** һәм җәмгыятьтән аерылмаса да, ул кытай фәлсәфәсендә үзәк урынны алып тора.

**Космик(галәм) энергиянең өч төре, кытай фәлсәфә традициясенә ярашлы, аның куерыгы - ул кеше.**

- ✔ **Цзин** — барлык тереклекне тудыручы энергия, тере организмның «тамыры", «орлыгы"

Бу психофизик *энергиянең ике төре бүленеп чыга:*

«Элекке Күк орлыгы" — кешегә тумыштан бирелгән нәрсәләр, генетик программа, физик мәгълүматлар;

«Киләсе күк орлыгы" — кеше гомере буена туплаган мәгълүмат.

Еш кына цзин сексуаль энергия белән тиңләштерелә.

- ✔ **Ци** — материаль-рухи энергия, ул барлык тереклеккә «төзелеш материалы» булып хезмәт итә (цзиннан аермалы буларак — барлыкка килү энергиясе).

***Ци энергиясе бүленә***:

- матди ци, аның аркасында әйберләр һәм тере организмнар материаль форма ала;
- рухи ци - кеше рухы һәм башка тере җаннар. Рухи ци - кеше яшәешенең нигезе. Уңышлы, физик һәм әхлакый таза кеше «саф», «чиста» цига, чирле, көчсез, уңышсыз — «авыр", «пычрак", «кара" цига ия. Уңышка, физик һәм рухи сәламәтлек, бәхеткә юл — цины артык бар нәрсәдән азат итү, җанны сафландырудан тора.

- ✔ **Шэнь** — кешедә булган бетерә алмаслык рух энергиясе, ул кеше шәхесенең «үзәген» тәшкил итә һәм кеше үлеменнән соң да югалмый (цидан аермалы буларак).

**Үзенчәлекләре**

- ✔ Өч космос энергиясеннән тыш (барлыкка килү энергиясе — цзин; рухи яшәешнең материаль һәм рухи энергиясе — ци; үлемнән соң да калучы даими рух энергиясе — шэнь) кытай фәлсәфәсе ике төр сексуаль энергияне бүлеп чыгара:
- ✔ Барлык тереклек ике капма-каршы башлангычка бүленә - ирләр һәм хатын-кызлар. Бу тере табигатькә дә, (ирләр һәм хатыннарга бүленү, хайваннар арасында да җенес буенча бүленеш), җансыз табигатькә дә (мәсәлән, кытай фәлсәфәсе актив ирләр башлангычына ян Кояш, күк, көн, корылык, җиңеллекне, ә пассив хатын-кызлар башлангычына инь — Ай, Җир, тигезлекләр, төн, дымны).
- ✔ Тере һәм җансыз табигатьнең яшәү нигезендә, әйләнә-тирә чынбарлыкта "Тай-цзи" ята - бердәмлек, көрәш, үзара керешеп китү һәм үзара бер-берсен тулыландыру *ян и инь.*

# 2. Кытай фәлсәфәсендә кешенең үзләштерү үзенчәлеге

Кытай фәлсәфәсендәге кеше үзләштерү үзенчәлегенең көнбатыш фәлсәфәсеннән аермасы

- ✔ Кытай фәлсәфәсе кеше турында анык төшенчә бирми, кеше асылына анык төшенчәләр чыгару юлы аша түгел, ә аның образын тудыру һәм өйрәнү юлы белән кереп билгели (шуңа да сүзне кеше төшенчәсе турында түгел, ә кеше һәм башка күренешләр турында образ-төшенчәләр дип сөйләү дөресрәк булыр);
- ✔ Кеше гомерен туганнан түгел, яралганнан алып саный башлыйлар;
- ✔ Кеше мөнәсәбәтләре системасыннан кеше үлгәннән соң сызып ташламыйлар, ягъни кеше (аның рухы, ниндидер тәнгә ия булган — "шэн") кеше мөнәсәбәтләре системасында исәннәр белән берләттән үлгәннән соң да кала — туклану, хәстәрлеккә мохтаҗ, элеккеге вазыйфасын саклый, аның нәселен дәвам итүчеләр тәртибеннән чыгып бүләкләнергә, вазыйфадан бушатылырга, җәза алырга мөмкин;
- ✔ Кешенең рухи үзәге сыйфатында баш (ми, йөз, күз һ. б.) түгел, ә йөрәкне билгели;
- ✔ Кешене табигатьнең һәм галәмнең бер өлеше итеп кабул итә, кешенең табигатьтән өстен булу идеясе белән килешми, индивидуализм һәм аерым шәхесләрне җәмгыятьтәге калган әгъзаларга каршы куюны өнәми;
- ✔ Җирдәге гомер өзегенең кадерен белергә чакыра, аның озынлыгын максималь озынайтырга тырыша.

Озын гомернең төп шартлары (кытай фәлсәфәсенә ярашлы)

- ✔ Ци психофизик энергияне чиста торышта саклау, ул кирәкмәгән борчылулардан азат булуны, яман һәм мәкерле уй-гамәлләрдән баш тартуны, әйләнә-тирә чынбарлыкка дөрес мөнәсәбәт, әйләнә-тирәдәгеләргә һәм өлкәннәргә хөрмәт, тыйнак оптимизм, торак һәм җиһазның дөрес урнашуы, «пычрак» цилы кешеләр белән аралашудан читләшү, “саф” цилы кешеләр белән аралашуны үз эченә ала;
- ✔ "син чун" — тәнең һәм күңелең өстендә эшләү — үзеңне культуралаштыру;
- ✔ Язмышың өстендә эшләү, җәмгыятькә файда китерү — "мин чун";
- ✔ Җәмгыять тәртипләрен саклау;
- ✔ Дару һәм шифалы үләннәр куллану, дөрес туклану;
- ✔ Кытайда яшәү, кытай мәдәнияте белән берләшү, Кытай рухи энергиясе белән сугарылу.

## *3. Әйләнә-тирә дөнья һәм кешенең барлыкка килүе турында Кытай фәлсәфәсе һәм мифологиясенең аңлатмасы*

Әйләнә-тирә дөнья һәм кешенең барлыкка килүе турында Кытай фәлсәфәсе һәм мифологиясенең аңлатмасы

Үзенчәлекләре

- ✔ Борынгы Китай мәдәнияте әйләнә-тирә дөнья һәм кешенең барлыкка килүе хакында фәлсәфи-мифологик аңлатма бирә, ул үзенә берничә эзлекле этапны ала:
- ✔ "И-Цзин" Борынгы фәлсәфи әсәр дөнья барлыкка килүне биш беренчел элементларга бәйле дип аңлата — җир, агач, металл, ут һәм су, алар өзлексез әйләнештә тора.
- ✔ Борынга Кытай мифологиясе һәм фәлсәфәсе дөнья, табигать һәм кеше, кеше образ-төшенчәсенең, әйләнә-тирәдәге күренешләрне барлыкка килүе турында беренчел аңлатма бирде, Кытайның танылган фәлсәфә мәктәпләре барлыкка килү өчен нигез әзерләделәр — даосизм, конфуцианство, легизм.

Кытай мәдәниятендә әйләнә-тирәдәге дөнья һәм кешенең барлыкка килү этаплары

- ✔ Бөек Хаос, формасы белән бик зур Йомырканы хәтерләткән;
- ✔ Йомырка-Хаоста 18000 ел буена яралган барлык тереклекнең Беренче нәсел башлыгы—Пань-Гу гиганты;
- ✔ Пань-Гу гигантының Йомыркадан чыгуы, ул йомырка формасындагы Хаосны үлемгә китерде;
- ✔ Барлык җиңел һәм корының күккә-өскә (Күк) һәм авыр, дымлының аска (Җир) ашу юлы белән Хаостан Күк һәм Җир яралуы;
- ✔ Пань-Гу гигантының 18000 еллык Күк белән Җир арасында торуы нәтиҗәсендә Күк белән Җир үз урыннарына берегеп калалар;
- ✔ Пань-Гу үлеме, барлык тереклекне аның тәненән ясау: Кояш һәм Айны - күзеннән, яшенне - тавышыннан, җилне- сулышыннан, елгаларны - канынннан, юлларны — кан тамырыннан, таш һәм файдалы казылмаларны — сөякләреннән, тешеннән һ.б.лардан;
- ✔ Кешенең Пань-Гу тәнендә шуышкан паразитлардан барлыкка килүе, яки фантастик беренче нәсел башлыклары Фуси һәм Нюйваның — дракон-кешеләр мәхәббәте нәтиҗәсендә.

# 8нче сорау. Даосизм – Кытайның борынгы фәлсәфи тәгълиматы

**Даосизм** — Кытайның борынгы фәлсәфи тәгълиматы, әйләнә-тирә дөньяның төзелеше һәм яшәешен аңлатырга һәм кеше, табигать һәм галәм иярергә тиеш юлны билгеләргә тырыша. Даосизмга безнең эрага кадәрге VI гасыр ахыры — V гасыр башыларында яшәүче **Лао Цзы** *(Карт Укытучы) нигез сала. Төп чыганаклары* — "Даоцзин" и "Дэцзин« фәлсәфә трактатлары, кушып әйткәндә "Даодэцзин».

- ✔ "Дао" ике мәгънәгә ия: беренчедән, кеше һәм табигать үз үсешендә үтәргә тиешле юл, дөньяның яшәешен тәэмин итүче универсаль дөньяви закон; икенчедән, барлык дөнья барлыкка килгән субстанция, күп сыешлы энергетик бушлыкны гәүдәләндергән башлангыч.
- ✔ "Дэ" — югарыдан индерелгән рәхәтлек; бу энергиягә бәйле «Дао» әйләнә-тирә дөньяга әйләнә.

## Даосизмның төп идеяләре

- ✔ Дөньяда барысы да үзара бәйләнешле, анда башка әйберләр һәм күренешләр белән үзара бәйләнмәгән бер генә әйбер дә, бер генә күренеш тә юк;
- ✔ Дөнья ясалган материя бер; табигатьтә материя әйләнеше бар («барысы да җирдән ярала һәм җиргә китә»), ягъни бүгенге кеше кичә галәмдә булган башка формада — таш, агач, хайваннар өлеше һәм үлемнән соң нәрсәдән кеше торган башка тереклек яки табигать күренешләре формалары өчен «төзелеш материалы» булачак;
- ✔ Дөнья тәртибе, табигать законнары, тарих барышы какшамас һәм кеше ихтыярыннан тормый, димәк, кешенең төп принцибы — тынычлык һәм эшсезлек ("у-вэй");
- ✔ Император шәхесе изге, тик императорның гына Аллаһ һәм югары көчләр белән рухи элемтәсе бар; император шәхесе аша Китайга һәм барлык кешелек дөньясына "Дэ" — терелтүче көч һәм рәхәтлек төшә; кеше никадәр императорга якынрак торса, шулкадәр күбрәк "Дэ" императордан аңа күчәчәк;
- ✔ "Дао«ны танып белү һәм "Дэ«ны даосизм законнарын төгәл үтәгәндә генә алып була, "Дао«— башлангычы белән кушылу - императорны тыңлау һәм аңа якынлык;
- ✔ Бәхет, хакыйкатьне танып белү юлы — теләк һәм дәртләрдән азат булу
- ✔ Бер-береңә юл куярга кирәк.

# 9нче сорау. Борынгы Кытайның социаль-фәлсәфи мәктәпләре – конфуцианлык һәм легизм

## *1. Конфуцианлыкның характеристикасы (сыйфатламасы)*

**Конфуцианлык** — борынгы фәлсәфә мәктәбе, ул кешене иң элек социаль тормышта каташучы буларак карый. Аңа безнең эрага кадәр 551-479 елларда яшәүче Конфуций *(Кун-Фу-Цзы)* нигез сала. Тәгълиматның төп чыганагы - Лунь Юй («Әңгәмәләр һәм фикер йөртү") әсәре.

### Үзенчәлекләр

*Конфунцианлык хәл итә торган төп мәсьәләләр, ничек кешеләр белән идарә итәргә һәм җәмгыятьтә үзеңне тотарга.*

Бу фәлсәфә мәктәбе вәкилләре җәмгыять белән йомшак идарә итәргә кирәк дип исәпли. Мисал: ата кешенең улы өстеннән булаган власте, ә аның төп шарты — буйсынучыларның начальникларга улларының аталарына булган мөнәсәбәте.

Конфуцийның кешеләрнең җәмгыятьтәге алтын кагыйдәсе: үз-үзеңә теләмәгәнне, башкаларга эшләмә.

Конфуций тәгълиматы Кытай җәмгыятен берләштерү өчен зур роль уйный. Автор яшәгән һәм эшләгән вакыттан 2500 ел үтсә дә, ул бүгенге көндә дә көнүзәк булып кала.

### Конфуций тәгълиматының төп принциплары

- Җәмгыятьтә һәм җәмгыять өчен яшәргә;
- Бер-береңә юл куярга;
- Яшь һәм дәрәҗә буенча өлкәннәрне тыңларга;
- Императорга буйсынырга;
- Үз-үзеңне тыя белергә, бар нәрсәдә чама белергә, бер чиктән икенчесенә йөрүдән качу
- Кеше булырга.

### Җитәкче һәм буйсынучылар мәсьәләсе

#### Җитәкче ия булырга тиешле сыйфатлар

- Императорга буйсынырга һәм конфуций принципларына иярергә;
- Гаделлек нигезендә идарә итәргә ("бадао");
- Тиешле белемгә ия булу;
- Илгә тугрылыклы хезмәт итәргә, илсөяр(ватанпәрвәр) булырга;
- Зур амбициягә ия булырга, югары максатлар куярга тиеш;
- Намуслы булырга;
- Дәүләткә һәм әйләнә-тирәдәгеләргә яхшылык кына эшләргә;
- Көчләүгә караганда үгетләүгә һәм шәхси үрнәккә өстенлек бирергә тиеш;
- Буйсынучыларның шәхси һәм гомумән илнең иминлеге турында хәстәрлек күрергә тиеш.

#### Бйсынучылар ия булырга тиешле сыйфатлар

- җитәкчегә карата лояль мөнәсәбәттә булырга тиеш;
- Эшне башкарганда тырышлык күрсәтергә;
- Даими укырга һәм камилләшергә.

# 2. Легизм характеристикасы (сыйфатламышы)

**Легизм (канунчылар мәктәбе, яки Фацзя) –** Борынгы Кытайның башка мөһим социаль тәгълиматы

## Үзенчәлекләре

- ✔ Нигез салучылар - Шан Ян (б.э. кадәр 390 – 338 еллар) һәм Хань Фэй (б.э. кадәр 288 - 233 еллар).
- ✔ Император Цинь-Ши-Хуа (б.э. кадәр III гасыр) чорында легизм рәсми идеологиягә әйләнә.
- ✔ Легизмның төп мәсьәләсе. (конфуцианлык кебек үк): җәмгыять белән ничек идарә итәргә?
- ✔ Легистлар җәмгыять белән законга таянучы дәүләт көчен куллану белән идарә итәргә кирәк дигән фикер белән чыгыш ясыйлар.
- ✔ Шулай итеп, легизм — көчле дәүләт власте фәлсәфәсе.

## Легизмның төп постулатлары

- ✔ Кеше асылыннан ук явыз табигатьле;
- ✔ Кешене хәрәкәт иттерүче көч - эгоистик ихтыяҗлар;
- ✔ Гадәттә, аерым индивидлар ихтыяҗлары (социаль төркемнәр) үзара капма-каршы;
- ✔ Законсызлыкны һәм гомуми дошманлыктан качар өчен җәмгыять мөнәсәбәтләренә дәүләт кысылышы зарури;
- ✔ дәүләт(армия, чиновниклар йөзендә) законга буйсынучы гражданнарны бүләкләргә һәм гаеплеләрне каты җәзага тарттырырга тиеш;
- ✔ Күпчелек кешеләрнең законга буйсынуның төп сәбәбе җәза алудан куркуга бәйле;
- ✔ Законлы һәм законсыз тәртипне аеру һәм җәза куллануның төп коралы закон булырга тиеш;
- ✔ Закон барысы өчен дә бер булырга тиеш, ә җәза, әгәр дә законны бозсалар,
- ✔ гади кешеләргә дә, югары чиновникларга (дәрәҗәсенә карамыйча) карата да кулланырга тиеш;
- ✔ дәүләт аппараты профессионаллардан тупланырга тиеш (ягъни чиновник вазыйфаларын тиешле белеме һәм эшлекле сыйфатлары булган кандидатларга бирелергә, ә нәселдән бирелергә тиеш түгел);
- ✔ дәүләт — җәмгыятьнең төп тәртипкә салучы механизмы булырга тиеш, һәм, димәк, иҗтимагый мөнәсәбәтләргә, гражданнарның шәхси тормышына катышырга хокукы бар.

# 10нчы сорау. Борынгы һинд фәлсәфәсе

## *1. Борынгы һинд фәлсәфәсен чорларга бүлү*

**Борынгы һинд фәлсәфәсенең төп үсеш этаплары** (борынгыда да , бүген дә билгеле булган төрле фәлсәфи фикер чыганакларына ярашлы)

**Ведик чоры** (б.э.кадәр XV – VIгасырлар). *Веды* (сүзгә-сүз - "белемнәр" – дини-фәлсәфи трактатлар, аларны б.э. кадәр XV гасырда Һиндстанга Урта Азия, Идел буе һәм Ираннан килгән арийцлар кабиләләре алып килгән. Борынгы һинд фәлсәфәсен өйрәнүчеләрне күбрәк вед-упанишадының (санскриттан – "укытучы аягы астында утыру") йомгак өлешләре кызыксындыра. Бередә веда эчтәлегенең фәлсәфи аңлатмасы бирелгән.

Ведларга кертелгән өлешләр

- ✔"Изге язмалар", дини гимннар ("самхитлары");
- ✔ Ритуалларны тасвирлау ("брахманнар"), брахманнар (жрецами) тарафыннан язылган һәм дини культларны тәртипкә китрүдә кулланылган;
- ✔Урман дәрвишләре китабы ("араньяклар");
- ✔Ведаларга фәлсәфи аңлатмалар ("упанишадлар").

Бүгенге көнгә килеп житкән Ведлар

- ✔ Ригведа
- ✔ Самаведа
- ✔ Яджурведа
- ✔ Атхарваведа

**Эпик этап (б.э.кадәр VI – II гасырлар), аның киң билгеле ике поэмасы -** *"Махабхарата" һәм* "Рамаяна" эпослары, аларда чорның күп фәлсәфи мәсьәләләре күтәрелә

Бу чорда ведаларга каршы тудырылучы тәгълиматлар

- ✔Буддизм
- ✔Джайнизм
- ✔Чарвана-лакаята

Бу чорда барлыкка килүчек ведик тәгълиматны ("даршаны") үстерүче фәлсәфә мәктәпләре

- ✔йога
- ✔веданта
- ✔вайшешина
- ✔ньяя
- ✔миманса
- ✔санкьхя

**Сутр эрасы** (б.э. кадәр II гасыр – б.э. VII гасыры) – аерым мәсәләләрне карауччы кыска фәлсәфи трактатлар (мәсәлән," нама-сутра" һ.б.), - борынгы һинд фәлсәфәсе чорын тәмамлый.

Киләчәктә (урта гасырда һинд фәлсәфәсендә хакимлек итүче урынны Гаутамы Будда тәгълиматы - буддизм яулый.

XVIII – XX гасырларда һинд фәлсәфәсе европа фәлсәфи фикере казанышлары белән байый (атап әйткәндә, инглиз фәлсәфәсе)

## 2. *Борынгы һинд фәләсәфәсе онтологиясе*

**_Борынгы һинд фәләсәфәсе онтологиясе_**

ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

- *Борынгы һинд фәләсәфәсе онтологиясе* (яшәеш һәм яшәешнең юклыгы турында тәгълимат) Рит законына нигезләнә – космик эволюция, циклылык, тшртип һәм үзарабәйләнешләр.
- Яшәеш һәм яшәеш юклыгы Брахма – Космосның (Тудыручы Аллаһның) сулыш алу һәм чыгаруы белән ассоцияцияләнә. Үз чиратында,Брахма-Космос (Тудыручы - Аллаһ) 100 космик (8640000000 җир) елы яши, аңардан соң үлә һәм абсолют яшәеш юклыгы барлыкка килә, ул шулай ук 100 космик (8640000000 җир) елы дәвам итә – яңадан Брахма туганчыга кадәр.
- Бөтен чиксез тарих – ул Галәм-космос (Маха Манвантара) яшәешенең һәм Абсолют яшәеш юклыкның (Маха Пралйя) бер-берсен 100 космик ел алыштырып, чиратлашып килүе. Һәр туганда Брахма-Космос кабаттан яшәеш барлыкка килә, тик бар тик камилләшкән формада.
- Дөнья үзара бәйләнешле. Теләсә кайсы вакыйга (кеше хәрәкәте, табигать күренеше) Космос яшәешенә йогынты ясый. Эволюция максаты, үсеше – материаль формаларның даими алмашыну нәтиҗәсендә камиль рухка ирешү.

## 3. Борынгы һинд фәлсәфәсе гносеологиясе

**_Борынгы һинд фәләсәфәсе гносеологиясе_**

ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

- Борынгы һинд гносиологиясенең фәсәфәсенең төп үзенчәлеге (танып белү турында тәгълимат) предмет һәм күренешләрнең тышкы (күренеп торган) билгеләрен өйрәнү түгел (европа танып белү тибына хас), ә аңда предметлар һәм күренешләр белән бәйләнешкә керү вакытында аңда барлыкка килгән процессларны өйрәну.
- һинд фәлсәфәсе шушы уңайдан өч төр аңны бүлеп чыгара: “практиклар” – материаль аң, “паруша” – саф аң( Галәм һәм кешеләр барлыкка килгән беренчел энергия) һәм “майя” – төш аны, рәшә
- материаль аң һәм ялган яшәешне генә кабул итүче европа фәлсәфәсеннән аермалы буларак һәр төр аң реаль, һинд фәлсәфәсенә ярашлы һәм өйрәнүгә лаек

## *4. Һинд фәлсәфәсендә җан мәсьәләсе*

Һинд фәлсәфәсе буенча җан ике башлангычтан тора

 Атмон – кеше җанындагы Брахма - Аллаһның бер өлеше.  Атман беренчел, үзгәрешсез, мәңгелек.

 Манос  - гомер барышында барлыкка килүче кеше җаны. Манас даими үсеш кичерә, югары биеклекләргә ирешә яки кеше гамәлләренә, шәхси тәҗрибәсенә, язмышына бәйле начарлана.

## *5. Сансара, карма мокша һәм архимслар турында гомуми төшенчә*

Сансара – мәңгелек һәм җирдәге яшәеш вакытында газаплар чылбыры үтүче җанның үлемсезлеге турында тәгълимат.

Карма – кеше гомере, язмышының алдан билгелүнүе. Карма максаты – җанны камилләштерү һәм югары әхлакый үсешкә – мокшага ирештерү өчен кешене сынаулар аша үткәрү. Бу максатка ирешү өчен җан дистәләгән, йөзләгән җир гомере үтәргә мөмкин.

**Мокша** – югары әхлакый камиллек, аны ирешүгә җан үсеше (карма) туктый. Мокша урнашуы (җанның эволюцион үсеше туктау) – җирдә яшәгән вакытта ирешеп булган һәр җанның югары максаты. Мокшага ирешкән җаннар чиксез гомердән азат була һәм махатмами – Бөек Җаннарга әйләнә.

Ахимса – җирдәге барлык тереклек формаларының берлеге (димәк, кеше, хайваннар һәм әйләнә-тирә табигате берлеге). Ахмисларның мөһим принцибы – әйләнәдәгеләргә зыян салмау (кеше, хайваннарга, тере табигатькә).

# 11 сорау. Буддизм һәм аның төп идеяләре

**Буддизм** – Һиндстанда(б.э.кадәр V гасырда), Кытайда, Көньяк-Көнчыгыш Азиядә һәм башка төбәкләрдә (б.э. III гасырыннан соң) таралган дини-фәлсәфи тәгълимат

## ҮЗЕНЧӘЛӘКЛӘРЕ

✓ бу тәгълиматка нигез салучы - *Гаутама Будда* (Сидхардаха Шакьямуни) (б.э. кадәр 563 – 483 еллар) исәпләнелә, ул Төньяк Һиндстанда князьлар гаиләсендә туа. Будда катлаулы тормыш юлы үтә (тәхет дәвакмчысы, аскет-дәрвиш, акыл иясе), шуннан соң ачышлар ясый башлый (б.э.кадәр 527ел) һәм үзенең рухи казанышларын кешеләргә тапшыра.

✓Буддизмның төп идеясе – "Уртача юл" ике чик арасында: "рәхәтлекләр юлы аша" (күңел ачу, бәйрәм итү, ялкаулык, физик һәм мораль таркалу) һәм "аскетизм юлы аша" (җенси теләкләрне үтерү, авырлыклар, газаплар, физик һәм мораль йончу).

✓ «Уртача юл» – белем юлы, акыл, акыллы чикләнү,зыялылык,күзәтү, мәгрифәт,камилләшү, боларның ахыргы максаты – Нирвана – югары рәхәтлек.

## Будда ачкан дүрт нәзәкатьле (арияле) хакыйкать.

✔жир яшәеше газаплар белән тулы;

✔ газапларның үз сәбәпләре бар - җиңел табыш аласы килү, дан, канәгатьлек алу,яшәү һ.б.

✔Газаплардан котылып була

✔ газаплардан азат итә ала торган юл бар, - җир теләкләреннән баш тарту, агарту, Нирвана (ыгы-зыгылардан китү).

## Буддизм һәр кешегә шәхси камилләшү өчен тәкъдим иткән «Сигезле Азат булу Юлы» этаплары – нәтиҗәсе - Нирвана – Бөек Азат булу

✔Дөрес күрү – буддизм нигезләренә төшенү һәм үзеңнең тормыштагы юлыңны аңлау;

✔ дөрес фикерләү – кеше тормышы аның фикерләреннән тора, фикерләр үзгәргәндә ( дөрестән дөрес түгелгә, күркәмгә) тормыш үзгәрә;

✔ дөрес сөйләү – кешенең сүзләре, аның сөйләме аның рухына, холкына йогынты ясый;

✔ дөрес хәрәкәт – үзең һәм башкалар белән килешеп яшәү, башкаларга явызлык кылмау;

✔ дөрес яшәү рәвеше – һәр адымыңны буддизмның кануннарына нигезләнеп башкару

## Буддизмның биш канун-юнәлешләре

 үтермә;

 урлама;

 гыйффәтле бул;

ялганлама;

 исерткеч һәм тилерткеч әйберләр кулланма

# 12нче сорау. Борынгы Греция фәлсәфәсе: төп сыйфатлары,чорларга бүлү

Борынгы Греция территориясендә һәм Кече Азия, Урта һәм Кара диңгез буйлары һәм Кырымдагы грек полисларында (сәүдә-һөнәри шәһәр-дәүләтләр), Азия һәм Африкадагы эллинистик дәүләтләр, Рим империясында яшәүче грек фәлсәфәчеләре тудырган **Борынгы Греция фәлсәфәсе. Еш кына Борынгы Рим фәлсәфәсе, я аның белән «антик фәлсәфә» исеме астында берләштерелә.**

## Үзенчәлекләре

- бу фәлсәфәнең чәчәк атуына полисларның икътисадый яктан үсеше материаль нигез була ;
- борынгы грек фәлсәфәсе матди җитештерү процессыннан аерылган булган, ә фәлсәфәчеләр физик хезмәт белән авырлык китерелмәгән һәм җәмгыять белән рухи һәм сәяси җитәкчелек итәргә омтылучы аерым бер катламга чыга.
- борынгы грек фәләсәфәсенә космоцентризм хас (Космос алдында курку һәм аңа табыну, материаль дөнья, әйләнә-тирә дөнья барлыкка килү мәсьәләсенә кызыксыну күрсәтәләр);
- соңгы эхтапларда – космоцентризм һәм антропоцентризм кушылмасы (аның нигезендә кеше мәсьәләсе булды);
- Аллаһлар булуы ихтималлыгын кире какмый;
- борынгы грек Аллаһлары табигатьнең бер өлеше ул һәм кешеләргә якын
- кеше әйләнә-тирә дөньядан бүленми, табигатьнең бер кисәге була;
- фәләсфәнең ике юнәлеше салына – идеалистик (“Платон линиясе”) и материалистик (“Демокрит линиясе”),әйтергә кирәк, бу юнәлешләр чиратлашып өстен позициядә була, сократка кадәрге вакытта - материалистик, классик чорда – икесе дә бертөрле йогынты ясый, эллинистик – материалистик, римнықында – идеалистик.

# 2. Борынгы грек фәлсәфәсе этапларына (чорларына) кыскача характеристика

Борынгы грек (антик) фәлсәфәсенең үсеш этаплары

**Сократка кадәрге чор** (б.э.ның VII – Vгасырлары), аның төп мәсьәләләре: табигать күренешләрен, Галәм асылы, әйләнә-тирә дөньяны аңлату, барлык тереклекнең беренче башлангычын эзләү, ә фәлсәфәләү методы – үз карашларын игълан итү, аларны догмага әйләндерү

Әлеге чорны билгеләүче «сократка чаклы» фәлсәфәчеләр

✔ милет мәктәбе – “физиклар” (Фалес, Анаксемандр, Анаксимен;
✔ Гераклит Эфесский;
✔ элей мәктәбе;
✔ атомистлар (Демокрит, Левкипп);
✔ башка төр фәлсәфәчеләр

**Классик (сокраст) чоры** (б.э.кадәр V башы –IV гасырлар ахыры) – борынгы грек фәлсәфәсе чәчәк аткан чор (борынгы грек полислары чәчәк ату белән туры килә)

Төп юнәлешләр

✔Сократ фәлсәфәсе;
✔ “сократ” мәктәбе барлыкка килү;
✔Платон фәлсәфәсе
✔Аристотель фәлсәфәсе

***Табигать асылы һәм классик чордагы Галәм мәсьәләләрен карауда аерымлыклар***

- Сократ чоры фәлсәфәчеләре башлангычны эзләүгә аз игътибар итә;
- Аллаһның, табигатьнең һәм Галәмнең барлыкка килүе идеясе булу ихтималлыгын кабул итә
- тереклекнең килеп чыгышы турында идеалистик юрама тәкъдим итәләр (Платон – реаль дөньяга кадәрге һәм реаль дөнья гәүдәләнеше булган «саф идеяләр» турындагы тәгълиматның авторы)

## Борынгы грек фәлсәфәсенең (антик) үсеш этаплары (дәвамы)

**Эллинистик чор** (б.э. кадәр IV – II гасырлар) – полистагы кризис чоры һәм греклар һәм Александр Македонский һәм аның варислары җитәкчелегендә Азиядә һәм Африкада эре дәүләтләр барлыкка килүе

### Төп юнәлешләре

❖ кинbackикларның җәмгыятькә каршы фәлсәфәсе таралуы;
❖ фәлсәфәнең стоик юнәлеше барлыкка килү;
❖"сократик" фәлсәфә мәктәпләре эшчәнлеге: Платон академиясе, Ликей, Аристотель, кирен мәктәбе (киренаиков) һ.б.;
❖Эпикур фәлсәфәсе һ.б.

### Үзенчәлекләре

❖ антик мораль һәм фәлсәфи кыйммәтләр;
❖ Аллаһ һәм башка гадәттән тыш көчләр алдындагы куркуны киметү; аларга ихтирам
❖ элгәре авторитетларны инкарь итү, дәүләткә һәм аның институтларына карата кимсетеп карау;
❖ физик һәм рухи таянычны үзеңнән эзләү;
❖ чынбарлыктан ваз кичүгә омтылу;
❖ дөньяга материалистик күзлектән карауны өстенлек итү (Эпикур);
❖ аерым кеше бәхете һәм канәгатьләнүен югары байлык итеп кабул итү (физик – киренаиклар, мораль – Эпикур)

Борынгы грек фәлсәфәсенең (антик) үсеш этаплары (д8вамы)

# **Рим чоры** (б.э.кадәр I гасыр- б.э.ның V гасыры)

Танылган фәлсәфәчеләр

- Сенека;
- Марк Аврелий (Рим императоры 161 – 180 еллар);
- Тит Лукреций Кар;
- соңгы стоиклар;
- беренче христианнар

Үзенчәлекләре

- борынгы грек һәм борынгы рим фәлсәфәсенең үзара йогынтысы (борынгы грек фәлсәфәсе рим дәүләтчелеге кысаларында үсешә һәм үзендә аның йогынтысын кичерә, ә шул вакытта борынгы рим фәлсәфәсе борынгы грек фәлсәфәсе идея һәм традицияләрендә үсә);
- борынгы грек һәм борынгы рим фәлсәфәсенең бергә фактик кушылуы – антик фәлсәфә;
- антик фәлсәфәгә яулап алынган халыклар, традицияләре һәм идеяләренең йогынтысы (Көнчыгыш, Төньяк Африка һ.б.);
- фәлсәфә, фәлсәфәчеләр һәм дәүләт институтларының якынлыгы (Сенека рим императора Нейронны тәрбияли, Марк Аврелий үзе император була);
- әйләнә-тирә табигать мәсьәләләренә зур булмаган игътибар;
- кеше, җәмгыять, дәүләт проблемаларына зур игътибар
- эстетиканың чәчәк атуы (фәлсәфә, аның предметы – кеше фикерләре һәм тәртибе
- Стоитик фәлсәфәнең чәчкә атуы, аның яклылар югары байлык һәм яшәү мәгънәсе шәхесне рухи үсеше, белеме,үз-үзенә китүендә, тынычлыгында (атароксия);
- идеализмның материализмнан югарырак булуы
- күбрәк табигать күренешләрен Аллаһ кушуы буенча баруы белән аңлатыла;
- үлем һәм теге дөньядагы тормышка кызыксыну арту;
- фәлсәфәгә христиан диненең һәм беренче христианнар ересенә игътибар үсүе;
- антик һәм христиан фәлсәфәсенең тора-бара кушылуы, аларның урта гасыр технологик фәлсәфәгә әверелүе.

## 13нче сорау. Борынгы Грециянең беренче фәлсәфи (сократка кадәрге) мәктәпләре

## *1. Сократка кадәрге фәлсәфә мәктәпләренә гомум төшенчә*

**Сократка кадәрге мәктәпләр б.э.кадәрге** *VII- Vгасырларда беренче аякка басу процессында булган борынгы грек полисларында барлыкка килә.*

### Борынгы Грециянең танылганрак беренче мәктәпләре

- ✔ Милет мәктәбе;
- ✔ Пифагорчылар мәктәбе;
- ✔ Гераклит Эфесский мәктәбе;
- ✔ Элей мәктәбе;
- ✔ атомистлар.

### Үзенчәлекләре

- ✔ Чагу гәүдәләнгән космоцентризм;
- ✔ Әйләнә-тирә күренешләрен аңлату проблемасына югары йогынты;
- ✔ Барлык тереклекнең беренче башлангычын эзләү,
- ✔ гилозоизм (җансыз табигатьне сынландыру);
- ✔ Фәлсәфә тәгълиматының доктриналы (бәхәссез) характеры.

## *2. Милет мәктәбе («физиклар») - Фалес, Анаксимандр, Анаксимен*

**Милет мәктәбе Борынгы Грециянең б.э.ның** VI гасырында барлыкка килеп, исемен нигез салынган шәһәр исеменнән ала - Милета — Кече Азиядәге эре сәүдә-һөнәри полисы.

### Үзенчәлекләр

- материалистик позициядән чыгыш ясыйлар
- Фәлсәфә белән генә түгел, башка фәннәр белән дә шөгыльләнә — төгәл һәм табигый фәннәр белән;
- Табигать законнарын аңлатырга тырышалар (шуның өчен үзләренә икенче атама - «физиклар") алалар;
- Әйләнә-тирә дөнья барлыкка килгән беренчел субстанцияне эзлиләр.

### Вәкилләре

Фалес (якынча 640 - 560 еллар) - милет мәктәбенә нигез салучы, танылган грек галимнәренең һәм фәлсәфәчеләренең берсе. Зур фәнни һәм фәлсәфи эз калдырган Фалес.

Анаксимандр(б.э.кадәр 610 - 540 еллар), ул Фалес укучысы

Анаксимен (б.э. кадәр 546 - 526 еллар ) – Анаксимандр укучысы

## Фалесның төп карашлары

- ✔Бар нәрсәнең беренче башлангычы су дип исәпләгән ("архэ");
- ✔ Җирне суда яткан тигез диск рәвешендә күзаллаган
- ✔Җансыз табигать, барлык әйберләрнең җаны бар дип исәпли (ягьни гилозоист булган — бар нәрсәне җанландырган;
- ✔Күп Алалар булу ихтималлыгын иккарь итми;
- ✔Галәм үзәге ул Җир дип исәпли
- ✔Ел дәвамлыгын төгәл билгеләгән — 365 көн;
- ✔Байтак математик ачышлар ясый (Фалеса теоремасы һ. б.).

## Анаксимандрның төп карашлары

- ✔Барлык нәрсәнең беренче башлангычы дип "апейронны исәпли –мәңгелек, исәпләп булмый торган,чиксез субстанция, бар нәрсә аңардан башлана, тора һәм аңа әйләнә;
- ✔ материяне саклау законын чыгара (әйберләрнең атомар төзелешен ача дисәң дә була): барлык тереклек, барлык әйберләр микроскопик элементлардан тора; тере организманрның үлеменнән соң, әйберләр таркалып, элементлар ("атомнар") кала һәм яңа комбинацияләр нәтиҗәсендә яңа әйберләр һәм тере организмнар барлыкка килә;
- ✔Беренче булып кешенең эволюция нәтиҗәсендә башка хайваннардан килеп чыгышы турындагы идеяне тәкъдим итә(Ч. Дарвин тәгълиматын алдан ук күргән).

## Анаксименның төп карашлары

- ✔Беренче башлангыч итеп һаваны исәпли;
- ✔Җирдәге барлык әйберләр – һаваның төрле дәрәҗәдәге оешканлыгы нәтиҗәсендә барлыкка килә дип идеяне тәкъдим итә (һава кысылганда башта суга әйләнә, аннары ләмгә, алга таба – туфракка, ташка һ.б.);
- ✔Кеше рухы ("психэ") һәм һава ("пневма") - «космос (галәм) җаны» арасында паралельләр үткәрә;
- ✔Аллаһларны табигать көчләре һәм күк җисемнәре белән тиңли.

# 3. Эфес Гераклиты

*Эфестагы Гераклит (б.э. кадәрге VI гасырның икенче яртысы - V гасырның башы) - күренекле борынгы грек материалист-фәлсәфәчесе, фәлсәфә юнәлешенә нигез салучы (иң элек мантыйк мәктәбенә керә)*

**Төп карашлар**

- ✔Барлык нәрсәнең башлангычы - ут;
- ✔Берлек һәм капма-каршылык законын чыгара — диалектиканың төп законы (Гераклитның фәлсәфи ачышларының иң мөһиме);
- ✔Барлык дөнья даими хәрәкәттә һәм үзгәрештә була дип исәпләгән («бер үк елгага ике тапкыр кереп булмый");
- ✔Табигатьтәге һәр әйбер әйләнештә һәм тарихның цикллы булуын яклый;
- ✔ әйләнә-тирә дөньяның чагыштырмача булуын таный («диңгез суы кеше өчен пычрак, ләкин балыклар өчен чиста", төрле ситуацияләрдә бер үк кеше хәрәкәте яхшы да яман да булырга мөмкин);
- ✔Бөтенесен эченә ала торган, һәр нәрсәгә үтә алучы Аллаһ дип Логосны исәпли — Дөнья Акылы;
- ✔ кеше һәм дөнья җанының материальлеген яклый;
- ✔Әйләнә-тирә чынбарлыкны хисси (материаль) танып белү яклы;
- ✔Барлык процессларның этәргеч көче ул - көрәш: «сугыш (көрәш) барнәрсәгә ата һәм ана».

## *4.Пифагорчылар*

*Пифагорчылар - борынгы фәлсәфәче һәм математик Пифогорның варислары һәм дәвамчылары (б.э.кадәрге VI гасырның икенче яртысы — V гасыр башы).*

Төп карашлары

- Барлык тереклекнең беренчел сәбәбе сан дип исәплиләр (барлык чынбарлыкны, барлыкка килгәннән һәр нәрсәне санга тоташтырып, саннар ярдәмендә исәпләп була);
- Сан аша танып белү өчен чыгыш ясыйлар (танып белү вакытында сан хисси һәм идеалистик аң арасындагы урталыктагы төшенчә дип исәпләгәннәр);
- Берне барлык нәрсәнең иң кече кисәкчәсе дип саныйлар;
- "протокатегория«ләр бүлеп чыгаралар, алар дөньяның диалектик берлеген күрсәтә (җөп — так, якты — караңгы, туры — кыек, уң — сул, ирләр — хатын-кызлар һ.б.).

## *5. Элеатлар*

Элеатлар — элея фәлсәфә мәктәбе вәкилләре, б.э. кадәрге VI—V гасырларда хәзерге Италия территориясендә урнашкан борынгы грек полисы Элеядә яшәп килгәннәр.

Бу мәктәпнең танылган фәлсәфәчеләре

- ✔ Парменид;
- ✔ Элея Зеноны;
- ✔ Самос Мелиссы.

Төп карашлары

- ✔ Танып белү мәсьәләсен өйрәнәләр
- ✔ Хисси танып белүне (фикер, «докса») һәм югары рухи идеальгә кискен бүләләр;
- ✔ Монизм яклы булалар — күп күренешләрнең барысын да бер башлангычтан чыгаралар;
- ✔ Барлык нәрсәләрне идеянең материаль гәүдәләнеше дип исәплиләр (идеализмны алдан хәбәр итүчеләр була).

## *6. Атомистлар*

Атомистлар — материалистик фәлсәфә мәктәбе, аның фәлсәфәчеләре (Демокрит, Левкипп) барлык нәрсәнең «төзелеш материалы", «беренчел кирпече« итеп микроскопик кисәкчекләрне - "атомнар«ны исәплиләр. Демокрит фәлсәфәнең материалистик юнәлешенә нигез салучы дип исәпләнә («Демокрита линиясе» — «идеалистик юнәлешкә — Платон линииясенә» капма-каршы ").

Демокрит тәгълиматының төп кагыйдәсе

- ✔ барлык материаль дөнья атомнардан тора;
- ✔ атом — барлык нәрсәнең иң кече кисәкчеге, «беренчел кирпече»;
- ✔ атом бүленми (бу фән белән бүген генә инкарь ителде);
- ✔ Атомнар төрле зурлыкта (кечкенәдән эреләргә кадәр), төрле формада (түгәрәк, озынча, кыек, «элмәкле" һ.б.) була;
- ✔ атомнар арасында бушлык белән тутырылган пространство бар;
- ✔ Атомнар мәңгелек хәрәкәттә;
- ✔ атомнар әйләнеше бар: әйберләр,тере организмнар яши, таркала, моңардан соң шул ук атомнардан яңа организмнар һәм материаль дөнья предметлары барлыкка килә;
- ✔ Атомнарны хисси танып белү юлы аша «күреп» булмый.

## 14нче сорау. Софистлар һәм Сократ фәлсәфәсе
## *1. Софистиканың гомуми төшенчәсе*

**Софистлар** — б.э. кадәрге V - IV гасырның беренче яртысында яшәп килүче Борынгы Грециянең фәлсәфә мәктәбе. Бу фәлсәфә вәкилләре фәлсәфәче-теоретик булып кына түгел, фәлсәфәче-педагоглар булып чыгыш ясыйлар,алар граждannarны фәлсәфәгә, ораторлык сәнгатенә һәм башка төр белемнәргә өйрәтәләр (грек теленнән "софистлар" — акыл ияләре, акыл бирүче остазлар).

**Софистлар вәкилләре**

- ✔ өлкән софистлар (б.э. кадәрге V гасыр) - Протагор, Горгий, Гиппий, Продик, Антифонт, Критий;
- ✔ кече софистлар — Ликофрон, Алкидамант, Трассимах
- ✔ Сократ рәсми рәвештә бу төркемнәргә керми, әмма софистларның күп идеяләрен уртаклаша һәм софистиканы практик эшчәнлектә куллана.

**Үзенчәлекләре**

- ✔Әйләнә-тирәдәге чынбарлыкка тәнкыйди мөнәсәбәт;
- ✔Барысын да гамәлдә тикшереп карага омтылу, теге яки бу дөрес яки ялган фикерне мантыйк ярдәмендә дәлилләү;
- ✔Иске традицион цивилизация нигезләрен кабул итмәү;
- ✔Иске традиция, гадәт, дәлилләнмәгән белемгә нигезләнгән кагыйдәләрне инкарь итү;
- ✔Дәүләт һәм хокукның шартлылыгын, аларның камил булмавын дәлилләргә омтылу;
- ✔Әхлак нормаларын абсолют барлык итеп түгел, ә тәнкыйть предметы итеп кабул итү;
- ✔Бәяләү һәм фикер йөртүдәге субъектив, объектив яшәешне инкарь итү һәм чынбарлыкның тик кеше фикерендә генә яшәгәнен дәлилләргә тырышу.

Софистларның төп мантыйк ысулы буларак софизм

- ✔ Үзләренең хаклы икәнен әлеге фәлсәфә вәкилләре софизмнар — мантыйк ысуллары, әмәлләр ярдәмендә дәлилләгән. Алар ярдәмендә беренче карашка дөрес тоелган сөземтә ахырда ялган булып чыга һәм әңгәмәдәш үз фикерләрендә бутала.
- ✔ Әлеге сөземтәгә «мөгезле» софизм мисал булып тора:
  «Нәрсәне син югалтмадың, син шуңа иясең; мөгезеңне югалтмадың, димәк, синең мөгезең бар".
- ✔ Әлеге нәтиҗә пародокслар, логик мәгънәле операцияләрне коррект кулланмаганлыктан, софизмның логик авырлыгы нәтиҗәсендә ирешелми. Әйтелгән софизмда беренчесе ялган, моннан нәтиҗә дә инде, тик дөрес дип тәкъдим ителә.

Софистлар эшчәнлегенең әһәмияте (софистларның эшчәнлеге хөкүмәтнең дә, башка фәлсәфә мәктәпләре вәкилләренең хупланмавына карамастан, алар грек фәлсәфәсе һәм мәдәниятенә зур өлеш керттеләр.

- ✔ Әйләнә-тирәдәге чынбарлыкка тәнкыйди карый алдылар;
- ✔ Алар грек полсиларындагы гражданнарга күп фәлсәфи һәм башка белемнәр тараттылар (моның өчен алар киләчәктә грек мәгърифәтчеләре дип йөртеләләр).

# 2. *Протагор фәлсәфәсе*

Протагор (б.э кадәрге V гасыр) - өлкән софистларның танылган вәкиле.

- Үзенең фәлсәфи кредосын Протагор түбәндәге юлларда билгеләгән:«Кеше барлык булган әйберләрнең булганы булган дип, булмаганы булмаган дигән үлчәм ".
Бу әйләнә-тирә чынбарлыкны, яхшыны һәм яманны бәһалау критерие буларак, софистлар кешенең субъектив фикерен тәкъдим итте.
- Протагорның замандашларының берсенә «Ике төрле сөйләм» әсәрен иҗат иткән дип күрсәтелә, ул шулай ук яшәеш һәм танып белүнең чагыштырмалы булуы фикеренә китерелә («Чир чирлеләр өчен явызлык, ә табибларга бәхет"; «Үлем үлгән өчен явызлык, тик каберче һәм табутчыга бәхет) һәм яшь кешене бәхәстә җиңәргә өйрәтә.
- Протогорның Аллаларга карата мөнәсәбәте ул вакытлар өчен оригиналь һәм революцион яңгырый: «Аллар турында мин белә алмыйм, бармы алар, юкмы, шуңа күрә мондый белемгә бик күп нәрсә комачаулый — бу мәсьәлә караңгы һәм кеше гомере дә кыска".

*Протагорның төп фәлсәфә кагыйдәсе*

- Кеше аңыннан башка берни дә юк;
- Бер һәм гомерлеккә шушыдан башка юк;
- бүген кеше өчен нәрсә яхшы, шул чынбарлыктагы яхшылык була да инде;
- Бүген яхшы булган иртәгә яманга әйләнә икән, димәк, ул чынбарлыкта зыянлы һәм яман;
- Барлык әйләнә-тирә кешенең хисси үзләштерүеннән тора (“ Сәламәт кешегә татлы тоелган, сырхауга ачы тоелачак”);
- Әйләнә-тирә дөнья чагыштырмача;
- объектив (хакыйкый) танып белүне аңлап бетеп булмый;
- Фикерләр дөньясы гына яши.

## 3. Сократ фәлсәфәсе

Сократ (б.э. кадәрге 469 - 399 еллар)- софистикага мөнәсәбәте булган ихтирамга лаек фәлсәфәчеләрнең берсе.

Үзенчәлекләре

Сократ ул кадәр әһәмиятле фәлсәфи әсәрләр калдырмаган, әмма тарихка күренекле бәхәсче, акыл иясе, укытучы-фәлсәфәче буларак кереп калаган.

Төп методы, "майевтика«дип исем алган. Аның асылы - хакыйкатькә өйрәтү түгел, мантыйк ысуллары аша, ишарә сораулары ярдәмендә әңгәмәдәшне мөстәкыйль рәвештә хакыйкатьне табарга юнәлтү.

Сократ үзенең фәлсәфә һәм мәгърифәт эшен халык арасында, мәйданнарда, базарларда ачыктан-ачык алып бара (диалог, бәхәс формаларында), аның темалары булып шул чорда һәм бүген дә көнүзәк мәсьәләләре була: яхшылык, явызлык, мәхәббәт, бәхет, намус һ.б.лар.

Фәлсәфәче этик реализм яклы була, аңа ярашлы:
- теләсә кайсы белем ул яхшылык;
- теләсә кайсы яманлык, бозыклык белемсезлектән ясала.

Сократ рәсми хөкүмәт тарафыннан аңлауга ирешә алмый һәм гадәттәгечә, җәмгыятьне таркатучы, яшьләрне юлдан яздыручы һәм Аллаларны санга сукмаучы софист буларак кабул ителә. Моның өчен ул б.э.кадәр 399 елда үлемгә хөкем ителә һәм агулы цикута эчә.

Сократ эшчәнлегенең тарихи әһәмияте

- ✔Белем таратуга, гражданнарны агартуга булышлык итә;
- ✔Кешелекнең мәңгелек сорауларына җавап эзли — яхшылык һәм яманлык, мәхәббәт, намус һ.б.лар.;
- ✔Заман мәгърифәтендә киң кулланылган майевтика методын ача;
- ✔ Ирекле бәхәстә хакыйкатьне дәлилләү юлы аша, элгәре фәлсәфәчеләре кебек декларацияләү аша түгел, хакыйкатьне табуның диалогик методын кертә;
- ✔Бик күп укучылар(аның эшен дәвам итүчеләр) тәрбияләп чыгара, (мәсәлән, Платон), шактый «сократ мәктәпләре» нигезендә тора.

# 4.Сократ мәктәпләре

*"Сократ мәктәпләре" — Сократ идеяләре йогынтысында һәм аның укучылары үстергән фәлсәфи тәгълиматлар.*

Платон академиясе — Платон тарафыннан б.э.кадәр 385 елда төзелгән һәм б.э.ның VI гасырына кадәр яшәүче (мең ел тирәсе) дини-фәлсәфи мәктәп, аның максаты – фәлсәфи мәсьәләләрен тикшерү, Аллаһ һәм музаларны олылау.

Киники — фәлсәфи мәктәп, ул җәмгыятьтән тыш азатлык идеясен дәлилли (асоциаль азатлык). Аның вәкилләре үзләренең фәлсәфи эзләнүләрен үзләрендә тикшерә. Киниклар паразитар, сукбай тормышы алып баралар, гаиләләре булмаган, дәүләтне һәм законга илтифат итмиләр, традицион мәдәният, әхлак, байлыкка каршы нәфрәт кичерәләр, кеше бозыклыгына игътибарны юнәлтәләр. Аларның иң күренеклеләре - Антисфен, Диоген Синопский (Платон тарафыннан «Акылдан язган Сократ» дип аталган).

Элидо – эритрия мәктәбе

Киренская школа основана в IV в. до н. э. Аристиппом из Кирены, учеником Сократа.

Шушы мәктәп вәкилләренең төп карашлары

- ✔Табигатьне өйрәнүгә каршы чыгалар;
- ✔Иң югары рәхәтлек дип ләззәтне исәпләгәннәр;
- ✔Тормыш максаты - ләззәттә, бәхет ләззәт җыелмасы буларак, байлыкны ләззәткә ирешү чарасы буларак кабул итәләр.

Мегар мәктәбенә Сократның  Мегардагы Евклид исемле укучысы нигез сала (б.э. кадәр IV гасыр). Вәкилләре - Евбулид, Диодор Крон.

Үзенчәлекләре

- ✔Мегарчылар югары абстракт рәхәтлек бар дип исәпли, аны төгәл сурәтләп булмый — Аллаһ, аң, яшәү энергиясе. Югары рәхәтлекнең (абсолют явызлык) капма-каршысы булмый.
- ✔Фәлсәфи теоретик эзләнүләрдән тыш мегарчылар актив гамәли эшчәнлек тә алып баралар (асылда, софистика белән шөгыльләнәләр) һәм “бәхәсчеләр” дигән кушамат алалар.
- ✔Мегар мәктәбе вәкилләре (Евбулид) танылу алган апорияләр авторларын әйләнәләр, ягъни парадокслар (софизмнар белән бутамаска), — «Өем» и «Пеләш», алар ярдәмендә санның сыйфатка күчеш диалектикасын аңларга тырышканнар.
- ✔«Өем» апориясе: «Әгәр җиргә орлык ташласаң һәм аңа берәр орлык өстәп торсаң, кайчан бу урында өем барлыкка киләчәк? Орлык тупланмасы бер орлык кушканнан соң өемгә әйләнә аламы?"
- ✔«Пеләш» апориясе: « Әгәр кешенең башыннан берәр чәче төшеп торса, кайчан ул пеләшкә әйләнәчәк? Конкрет чәчне билгеләү мөмкинме, ул төшкәннән соң кеше пеләшкә әйләнәчәк? «Әле пеләш түгел» белән «пеләш инде» арасында чик куюы мөмкинме?

# 15нче сорау. Киниклар һәм стоиклар фәлсәфәсе

## *1. Киник фәлсәфәсенең гомуми төшенчәсе*

**Киниклар** — Борынгы Грециянең сократ чорындагы фәлсәфә мәктәпләренең берсе.

Киникларның фәлсәфәсенә хас сыйфатлар һәм яшәү рәвеше:

- абсолют асоциаль азатлыкка күтәрү (ягъни җәмгыятьтән тыш азатлык);
- ирекле читкә кагылганлык, социаль элемтәләрне өзү, ялгызлык;
- даими яшәү урыны булмау, гизүчәнлек;
- паразитар яшәү рәвеше, сорашучанлык;
- иң яман тормыш шартларына, иске, таушалган киемгә өстенлек бирү. Гигиенага түбәнсетеп карау;
- физик һәм рухи ярлылыкны мактау;
- чиксез аскетлык;
- йомыклык;
- башка фәлсәфи тәгълиматларны икарь итү һәм тәнкыйтьләү,аеруча идеолистикларны;
- авторитетларны кабул итмәү;
- үз карашыңны һәм тормыш рәвешеңне яклаганда сугышчан булу һәм агрессиялелек;
- бәхәскә тискәре карыйлар, әңгәмәдәшне басарга тырышу;
- патриотизм юклыгы, теләсә кайсы җәмгыятьтә үз законнары буенча яшәргә әзер тору;
- игътибарны җәмгыятьнең бозыклыгына, кешенең яман сыйфатларына юнәлтү;

# 2. Синап Диогены теоретик һәм практик буларак киник фәлсәфә

**Диоген Синопский** (яшәү еллары төгәл билгеле түгел, б.э. кадәр IV гасыр, Александр Македонский замандашы) — киник фәлсәфәсенең чагу һәм билгеле теоретигы һәм практигы. Бу фәлсәфә мәктәбенә исемне дә ул биргән дип исәпләнелә( чөнки Диогенның тагын бер кушаматы — "кинос", «эт", ул грекча "киник«сүзенә аваздаш). Чынбарлыкта исә —"Киносарг« сүзеннән — Афинадагы калкулык һәм Антисфен укучылары белән шөгыльләнгән гимназия.

Диоген фундаменталь фәлсәфи хезмәтләр калдырган, тик тарихка үзенең анекдотлы, җәнҗаллы холкы һәм яшәү рәвеше белән, шулай ук әйткән сүзләре һәм идеяләре белән кереп калган:

- мичкәдә яшәгән;
- патша Александр Македонскийга әйткән: «Кит һәм миңа кояшны каплама!";
- лозунг чыгара: «Общинасыз, йортсыз,ватансыз" (ул аның һәм дәвамчыларның тормыш һәм фәлсәфә кредосына әйләнә);
- «дөнья гражданины" (космополит) төшенчәсен чыгара;
- өйләнеп яшәүне кире кага;
- традицион тормыш рәвеше яклылардан каты көлә;
- табигать законнарыннан тыш, бернинди дә законнарны танымый;
- сорашучанлык белән яшәп, тышкы дөньядан бәйсез булуы белән горурлана;
- борынгы кыргый кешеләрнең һәм хайваннарның тормышын идеальләштерә.

# 3. Стоиклар фәлсәфәсенә гомуми характеристика

Стоиклар фәлсәфә мәктәбе, анының барлыкка килүе һәм үсеше киниклар идеясе таралуына җавап була ("Стоя" — Афинадагы порт исеме, ул биредә туа). **Зенон Китайский аңа нигез сала** (Зенон Элейский белән бутамаска, "апорий" — парадокслар авторы).

Стоик фәлсәфә үз үсешендә берничә этап үтә.

• яшь стоя (б.э. кадәр III — II гасырлар), вәкилләр — Зенон, Клеанф, Хрисипп һәм башкалар;
• урта стоя (б.э. кадәр II — I гасырлар) - Панеттий, Посидоний;
• соңгы стоя (б.э. кадәр I гасыр — ю.э. III **гасыр**) — Сенека, Эпиктет, Марк Аврелий.

Стоиклар фәлсәфә мәктәбенең төп идеясе (киниклар фәлсәфәсенең төп идеясе белән охшаш) — тышкы дуөнҗя йогынтысыннан азат булу. Әмма тышкы дөнья йогынтысыннан азат булуны традицион мәдәният кыйммәтләреннән, асоциаль яшәү рәвешеннән( сораучанлык, сукбайлык,һ.б.) баш тарту дип билгеләгән киниклардан аермалы буларак, стоиклар бу максатка ирешүне башка юлны таба — даими камилләшү, традиөион мәдәният казанышларын кабул итү, акыл. Шулай итеп, стоиклар идеалы булып, тышкы дөнья йогынтысыннан, тормышның мәшәкатьләреннән мәгърифәтлелек, белем, гаделлеге һәм ваемсызлыгы, эчке бәйсезлеге аркасында котылган акыл иясе чыгыш ясый.

Стоик фәлсәфәсенең үзенчәлекле сыйфатларына түбәндәгеләр керә:

• табигать һәм Дөнья Галәм Акылы (Логос белән) килешеп яшәүгә чакыру;
• саф күңеллелек югары байлык, ә бозыклык — бердәнбер явызлык;
•саф күңеллелекне яхшылык һәм явызлык буларак билгеләү һәм яхшылыка артыннан бару;
• саф күңеллелеккә җанның даими торышы һәм әхлакый ориентир буларак өндәү;
• рәсми законнарны һәм дәүләт властен алар гадел булганда гына кабул итү;
• дәүләт тормышына катнашмау (үзен үзе чыгару), законнарны, традицион фәлсәфә һәм мәдәниятне инкарҗ итү, әгәр дә алар явызлыкка хезмәт итә;
• үз-үзенә салучыларны аклау, әгәр дә алар гаделсезлеккә, явызлыкка һәм бозыклыкка каршы эшләнелсә;
• байлык, сәламәтлек, матурлык белән соклану, дөнҗя мәдәниятның иң яхшы казанышларын үзләштерү;
• уйларда һәм гамәлләрендәге югары эстетизм;
• хәерчелекне, чирләрне, сукбайлыкны, сораучанлыкны, кеше бозыклыкларын гаепләү;
• бәхеткә омтылу кешенең иң югары максаты итеп тану.

# 4. Сенека и Марк Аврелий фәлсәфәсе

Стоик фәлсәфәнең иң танылган вәкилләре - Сенека и Марк Аврелий

**Сенека** (б.э. кадәр 5 ел — б.э.ның 65 елы) — күренекле рим фәлсәфәчесе, Нерон императорының тәрбиячесе, аның идарә итү чорында ул дәүләт эшләренә көчле һәм уңай йогынты ясый. Нерон яман сәясшт алып бара башлаганчы, Сенека дәүләт эшләреннән китә һәм үзенә кул салып үлә

Төп карашлары:
• саф күңеллелек, гаделлек идеяләрен тарата;
• җәмгыять тормышында катнашмаска һәм үзендә генә, рухи халәттә тотарга чакыра;
• тынычлык һәм күзәтүне хуплый;
• дәүләткә сизелми торган, әмма индивидка шатлыклы булган тормыш яклы була;
• кешенең һәм гомумән кешелекнең чиксез үсешенә ышана, мәдәни һәм техник прогрессны күзаллый алган;
• дәүләт белән идарә итүдә фәлсәфәчеләр һәм акыл ияләренең әһәмиятен арттырып җибәрә, гади һәм надан кешеләрне, «кәтү»не күрә алмый;
• әхлакый идеал һәм кеше бәхетен югары рәхәтлек дип санаган;
• фәлсәфәдә теоретик система түгел, ә дәүләт белән идарә итү, җәмгыять процесслары, тормышта кешеләрнең бәхеткә ирешү буенча гамәли җитәкчелек.

**Марк Аврелий Антонин** (б.э.ның 121 — 180 еллары) — күренекле рим стоик-фәлсәфәчәсе, 161 — 180 елларда — рим императоры. «Үз-үземә» фәлсәфи әсәрне язган.

Төп идеяләр:
• Аллага карата тирәнтен шәхси хөрмәт мөнәсәбәте;
• Алланы югары дөнья башлангычы итеп тану;
• Алланы бөтен дөньяны берләштерүче һәм аның барлык өлешләренә үтеп керә алучы матди-рухи көч буларак аңлау;
• әйләнә-тирәдәге барлык вакыйгаларны Илаһи Теләк белән аңлату;
• һәр дәүләт башлангычы, шәхси уңыш, бәхетнең уңышының төп сәбәбе Илаһи көчләр белән хезмәттәшлегендә дип күрү;
• кеше акылына буйсынмаучы тышкы дөньяны һәм кеше хакимлегендәге генә булган эчке дөньяны бүлеп карау;
• аерым кеше бәхетенең төп сәбәбе — аның эчке дөньясын тышкы дөнья белән яраштыруга китерү;
• җан һәм акылны бүлү;
• тышкы хәлләргә каршы тормауга чакыру, язмышка буйсыну;
• кеше гомеренең чикле булуы турында фикерләү, мөмкин кадәр тормышның кадерен, кыйммәтен белергә өндәү;
• әйләнә-тирә чынбарлыкка карата пессимистик караш өстенлеге.

# 16нче сорау. Платон фәлсәфәсе

## *1. Платон шәхесе һәм иҗатына гомуми характеристика*

**Платон** (б.э. кадәр 427 – 347 еллар) – иң күренекле Борынгы Греция фәлсәфәчесе, Сократ укучысы, үз фәлсәфә мәктәбенә— Академиягә нигез салучы,фәлсәфәнең идеалистик юнәлешенә нигез салучы.

Үзенчәлекләр:

✔Платон — үзе артыннан тулы зур фәлсәфә әсәрләре калдыручы беренче борынгы грек фәлсәфәчесе. Аның язмалары арасында иң күренекле әсәрләре - "Сократ Апологиясе ", "Парменид", "Горгий", "Федон", «Дәүләт", "Законнар".

✔Күпчелек Платон әсәрләре диалог формасында язылган.

✔ Платон идеализмга нигез салучы.

Аның идеалистик тәгълиматының төп положениеләре:

• матди әйберләр үзгәреп тора, даими түгел һәм вакыт белән үзенең яшәешен туктата . Идеалистик тәгълиматының төп положениеләре түбәндәгечә :

• «әйләнә-тирә дөнья» («әйберләр дөньясы») шулау ук вакытлы гына һәм үзгәрешле һәм чынбарлыкта аерым субстанция буларак бар булмый;

•реаль нибары саф («тәнсез») идеяләр (эйдослар) гына яши;

• саф (тәнсез) идеяләр хак, мәңгелек һәм даими;

•теләсә кайсы әйбер беренчел идеянең (эйдосның) материаль чагылышы була (мәсәлән, атлар туалар да үләләр, тик алар атлар идеясенең чагылышы гына, ул мәңгелек һәм үзгәрешсез һ. б.);

• бар дөнья саф идеяләр (эйдослар) чагылышы.

## 2. Платонның триада турындагы тәгълиматы

Платонның триада турындагы тәгълиматына ярашлы барлык хакыйкый әйберләр өч субстанциядән тора

### "Бердәм"

Үзенчәлекләр:
- теләсә кайсы яшәешнең нигезе була;
- бернинди билегләре юк (башлангычы да, ахыры да, өлеше дә, тулылыгы да, формасы да, эчтәлеге дәһ.б.);
- һични түгел;
- теләсә кайсы яшәештән, фикерләүдән, хис-тойгыдан югарырак;
- бар нәрсәнең – барлык идея, әйбер, күренеш, үзенчәлекләр (кеше күзлегеннән яхшы яки яман булган һәрнәрсәнең) башлангычы.

### "Акыл"

Үзенчәлекләр:
- «бердәмнән» барлыкка килә;
- «бердәм» беләν аерылган;
- «бердәмгә» капма-каршы куелган;
- барлык әйберләрнең асылы булып тора;
- Җирдәге һәр тереклекнең гомуми нәтиҗәсе була.

«Җан»:

### " Рух "

Үзенчәлекләр:
- хәрәкәтчән субстанция, ул «бердәм – һични»не һәм «акыл-бар тереклек» не берләштерше һәм бәйли, шул ук вакытта бөтен әйберләрне һәм күренешләрне үзара бәйли;
- Платонга ярашлы җан дөньяви һәм аерым кеше баны булырга да мөмкин; гилозоик (җанлы) якынаю юлы булганда әйберләр һәм җансыз табигатҗ тә җанлы булырга мөмкин;
- кеше җаны (әйберләр) дөнҗя җанының бер өлеше;
- җан үлемсез;
- кеше үлгәндә тик тәне генә үлә, җан, үзенең җирдәге гамәлләре өчен теге дөньяда җавап тотып, яңа тән кабыгы ала;
- җанның даимилеге һәм тән формалары алмашы — Галәмнең (Космос) табигый законы.

# 3.Платон фәлсәфәсендә дәүләт мәсьәләсе

**Дәүләт мәсьәләсе** ( Платон фәлсәфәсендә мөһим роль уйный, бу элгәреләргә хас түгел иде —Фалес, Гераклитның "сократка кадәргеләргә" һ.б., алар дөньяның башлангычын эзләү һәм әйләнә-тирә табигать күренешләрен аңлату белән шөгыльләнәләр, әммә җәмгыятьне түгел).

Платон буенча яшәп килүче дәүләтләр төрләре:

• монархия — бер кешенең гадел власте;
• тирания — бер кешенең гадел булмаган власте;
• аристократия — справедливая власть меньшинства;
• олигархия — гадел булмаган азчылык власте;
• демократия — күпчелекнең гадел власте;
• тимократия — күпчелекнең гадел булмаган власте, хәрби башлыклар, армия власте.

Поскольку тирания, олигархия и тимократия являются несправедливыми формами государства, а демократия — власть большинства — редко бывает справедливой и, как правило, вы рождается в тиранию, олигархию или тимократию, двумя стабильными и оптимальными формами государства могут быть только аристократия и монархия.

Платон тәкъдим иткән дәүләт төзелеше планы

• дүәләтнең (полисның) барлык халкы өч катламга бүленә — фәлсәфәчеләр, хәрбиләр, эшчеләр;
• эшчеләр (крестьяннар һәм һөнәрчеләр) физик хезмәт белән шөгыльләнә, материаль байлыклар тудыра, чикләнгән күләмдә хосусый милеккә ия була ала;
• сугышчылар физик күнекмәләр белән шөгыльләнәләр, дәүләттә тәртип тоталар, кирәксә — хәрби хәрәкәтләрдә катнашалар;
• фәлсәфәчеләр (акыл ияләре) — фәлсәфи теорияләр эшләп чыгаралар, дөньяны танып беләләр, өйрәтәләр, дәүләт белән идарә итәләр;
• фәлсәфәчеләр һәм хәрбиләр хосусый милекле булырга тиеш түгел;
• дәүләттә яшәүчеләр бергә буш вакытларын үткәрә, бергә ашыйлар, бергә ял итәләр;
• никах юк, хатыннар һәм балалар уртак;
•коллар хезмәтен куллану хуплана, кагыйдә буларак, кулга алынган варварларны.

## *4. Платон фәлсәфәсенең әһәмияте*

Платон фәлсәфәсенең тарихи әһәмияте

• беренчегә фәлсәфәче тарафыннан тулы фундаменталь әсәрләр җыентыгы калдырыла;
• идеализмга башлангыч салына ("Платон линиясе" дип аталган — материалистик «Демокрит линиясенә» капма-каршылык);
• беренчегә табигать кенә түгел, җәмгыять мәсьәләләре дә – дәүләт, закон, һ.б. тикшерелә
• аңлы фикерләүгә нигез салына, фәлсәфи категорияләрне бүлү омтылыш ясала (яшәеше — үсеш, мәңгелек — вакытлы, тынычлыкта тору — хәрәкәт итүче, бүленми торган — бүленә торган һ.б.);
• фәлсәфи мәктәп төзелә (Академия), 1000 елга якын яшәп килә, биредә Платонның күренекле варислары үсеп чыга (Аристотель һ.б.).

## *5. Платон академиясе*

**Платон академиясе** — Платон тарафыннан 387 елда Афина янында төзелгән дини-фәлсәфи мәктәп, 1000 ел тирәсе яши (б. э. 529 елга кадәр).

- Академиянең күренекле тәрбияләнүчеләре булып түбәндәгеләр булды: Аристотель (Платонда укый, үз фәлсәфә мәктәбе төзи — Ликей), Ксенокрит, Кратет, Аркесилай, Клитомах Карфагенский, Ларисыдан Филон (Цицеронның укытучысы).
- Академия 529 елда византия императоры Юстиниан тарафыннан мәҗүсилек һәм «зыянлы» идеяләр таратучы буларак, ябыла. Әмма үз тарихында платонизм һәм неоплатонизмның әйдәүче европа фәлсәфәсенә әйләнүенә ирешә.

# 17нче сорау. Аристотель фәлсәфәсе

## *1. Гомум положенияләр*

**Аристотель** (б.э. кадәрге 384 — 322 еллар) —классик чорның борынгы грек фәлсәфәчесе, Платон укучысы, Александр Македонскийның тәрбиячесе. Иң танылган әсәрләренә керә:
"Органон", "Физика", "Механика", "Метафизика", «Җан турында", «Хайваннар тарихы", "Никомахов этикасы", "Риторика", "Политика", "Афина политаясы", «Шигърият".

### Аристотель эшчәнлегенең төп этаплары

•б.э. кадәрге 367 – 347еллар (20 ел) – 17 яшеннән алып Платон академиясендә эшли һәм аның укучысы була (Платон үлгәнчегә кадәр);
• б.э. кадәрге 347 - 335 еллар (12 ел) – Пелледә яши һәм эшли - Македония дәүләтенең башкаласында Филипп патша чакыруы буенча; Александра Македонскийны тәрбияли;
• 335 - 322 еллар – үз фәлсәфә мәктәбен төзи - Ликей (перипатетик мәктәп) һәм үлгәнчегә кадәр шунда эшли.

### Аристотель бүлеп чыгарган фәлсәфә төрләре

• *теоретик, яшәеш, яшәешнең төрле өлкәләре, барлык тереклекнең барлыкка килү, төрле күренешләр барлыкка килү мәсҗәләләрен өйрәнә* («беренчел фәлсәфә» исемен ала);
• *практик –кеше эшчәнлеге, дәүләт төзедеше турында*;
• *поэтик.*
Фәлсәфәнең дүртенче өлеше буларак Аристотель мантыйкны билгели дип исәпләнелә.

### Аристотель фәлсәфәсенең тарихи әһәмияте

• «саф идеяләрне» тәнкыйтьләп, Платон фәлсәфәсенә төзәтмәләр кертә;
• дөнья һәм кешенең барлыкка килүенә материаль аңлатма бирә;
• 10 фәлсәфи категория бүлеп чыгара;
• яшәешкә категорияләр аша билгеләмә бирә;
• материя асылын билгели;
• 6 төр дәүләт бүлеп чыгара һәм идеаль тип – политиягә билгеләмә бирә;
• мантыйк үсешенә өлеш кертә (дедуктив метод төшенчәсен аңлата — аерымнан гомумигә, силлогизм системасын нигезли.

## 2.Аристотельның Платонның "саф идеяләр" (эйдослар) турындагы тәгълиматын тәнкыйтьләве. Яшәеш асылын аңлату ысуыл буларак, Аристотель категорияләре

**Аристотельнең Платонның "саф идеяләр" (эйдослар) турындагы тәгълиматын тәнкыйтьләү**

**Үзенчәлекләр**

✔**Яшәеш мәсьәләсен караганда, Аристотель Платон фәлсәфәсен тәнкыйтьләп чыгыш ясый, аңа ярашлы әйләнә-тирә дөнья "әйберләр дөньясына» һәм "саф идеяләр дөньясына" бүленә, әйберләр дөньясы гомумән һәм аерым алганда,»саф идея»нең материаль чагылышы гына була.**

✔Платон ялгышы, Аристотель буенча, идеяләр дөньясын реаль дөньядан тартып алган һәм саф идеяләрне әйләнә-тирә чынбарлыкка бәйсез карый, ә ул үзе дә бай характаристикага ия- озынлык, тынычлык, хәрәкәт һ.б.

✔Аристотельгә ярашлы,чынбарлык белн бәйләнмәгән саф идеяләр юк, аның чагылышы булып барлык әйберләр һәм материаль дөнья предметлары һәм әйберләре була.

✔Мондый әйберләр *индивидуум*(тәрҗемәдә бүленешсез) дип атала ,ягъни конкрет урында конкрет ат кына бар, ә ат гәүдәләнешен чагылдырган ат идеясе түгел, конкрет урында торган конкрет урындык, ә урындык идеясе түгел.

✔Индивидуумнар башлангыч нигез була, ә индивидуумнарның төрләре һәм кавеме икенчел

Яшәеш саф идея (эйдослар) һәм аның материаль чагылышы (әйберләр) түгел икән сорау туа: нәрсә ул яшәеш? Бу сорауга тавапны Аристотель яшәеш турындагы әйтем, ягъни категорияләр аша бирергә тырыша.

✔Аристотель буенча яшәеш – ул күләм, урын, вакыт, мөнәсәбәт, хәл-торыш, хәрәкәт, газап үзенчәлекләренә ия асыл. Кеше яшәешнең үзенчәлекләрен генә үзләштерә ала, ә аның асылын түгел.

**Аристотельгә ярашлы категорияләр - ул әйләнә-тирә чынбарлыкны югары чагылдыру һәм гомумилштерү, аңардан башка яшәеш үзе мәгънәсез**

**Аристотель бүлеп чыгарган 10 категория, алар яшәеш турындагы сорауларга җавап бирә, шул ук вакытта бер категория яшәеш нәрсә икәнен әйтә, ә калганнары аны характерлый.**

✔**Асыл( субстанция)**

✔күләм

✔сыйфат

✔мөнәсәбәт

✔урын

✔вакыт

✔дәрәҗә

✔Хәл-торыш

✔хәрәкәт

✔газап

## 3. Аристотель фәлсәфәсендә метрия, җан һәм кеше мәсьәләләре

### Материя мәсьәләсе

**Аристотель буенча материя - ул форма белән чикләнгән потенция.**

**Үзенчәлекләр**

- **Җирдәге һәр потенция һәм формга ия**
- Бер генз сыйфатын үзгәртү дә предмет асылының асылын үзгәртүгә китерә
- Чынбарлык – ул материядән формага һәм форманың материягә эзлекле күчеше
- Потенция – ул пассив башлангыч, форма-актив
- Барлык асылның югары формасы – дөньядан тыш яшәеше булган Алла

### Җан мәсьәләсе

**Аристотель буенча җан аң иясе һәм шул ук вакытта организм функцияләрен алып бара**

**Аристотель күрсәткән җанның өч дәрәҗәсе**

- **Үсемлек җаны, ул туклану, үсеш һәм үрчү функөияләре өчен җавап бирә**
- Хайвани җан, шул ук фукцияләргә һәм шуңа кушып тою һәм теләү фукцияләренә җавап бирүче
- Акыл җаны, барлык функцияләрне җыеп фикерләү һәм уйлау функцияләрен дә алып бара

### Кеше мәсьәләсе

**Үзенчәлекләр**

- **Аристотель кеше мәсьәләсенә материалистик яктан якын килә. Ул кеше үзенең биологик асылы буенча хайваннарның бер төре булып тора дип исәпли, тик алардан акылы һәм фикерли белүе белән аерыла.**
- Аристотельгә ярашлы, кеше тумыштан үзенә охшашлар белән бергә яшәү тартымлыгы бар һәм нәкү шушы сыйфат күп санлы кеше тупланган җәмгыять барлыкка килүгә китерә, материал байлыклар җитештерүче һәм аларны бер территориядә яшәүчеләр һәм тел уртаклыгы, туганлык һәм мәдени бәйләнешләр белән берләшкән халык арасында бүлү белән шөгыльләнгән.
- Җәмгыятьне тәртипкә салучы механизм булып дәүләт чыгыш ясый.

## *4. Аристотель фәлсәфәсендә дәүләт мәсьәләсе*

**Аристотель фәлсәфәсендә дәүләт мәсьәләләре**

**Аристотель бүлеп чыгарган алты төр дәүләт**

- ✔**Монархия**
- ✔Тирания
- ✔Аристократия
- ✔Чикле олигархия
- ✔Охлократия (халык төркеме власте, чикле демократия )
- ✔Полития (уртача олигархия һәм уртача демократия катнашмасы)

**Үзенчәлекләр**

- ✔**Платон кебек үк Аристотель дәүләтне «начар» (тирания, чикле олигархия и охлократия) һәм “яхшы” (монархия, аристократия и полития) дәүләт формаларына бүлә**
- ✔Иң яхшы дәүләт формасы итеп ул политияне күрсәтә: уртача олигархия һәм уртача демократия җыелмасы, « урта сыйныф» дәүләте (Аристотель идеалы)

# 18нче сорау. **Эпикур фәлсәфәсе**

**Эпикур(б.э. кадәрге 341-270 еллар) – борынгы грек материалист-фәлсәфәчесе**

**Эпикурның табигать һәм космос турындагы тәгълиматы (физика)**

**Төп положениеләр**

- **Бер нәрсә дә юктан килеп чыкмый һәм бер нәрсә дә юк була алмый, чөнки аңа керердәй һәм үзгәртә алырдай Галмәнән башка бернәрсә дә юк**
- Галәм мәңгелек һәм чиксез
- Барлык әйберләр атомнар һәм бушлыктан тора
- Атомнар һәм бушлык мәңгелек
- Атомнар даими хәрәкәттә
- “саф идеяләр дөньясы ” юк
- Галмәдә күпләгән материал дөньялар бар

**Эпикурның танып белү турындагы тәгълиматы (каноника)**

**Төп идеяләр**

- **Әйләнә-тирә дөньяны танып белеп була**
- Танып белүнең төп төре хисси танып белү
- Нинди дә булса идея яки күренешләрне «акыл белән күзәтү» мөмкин түгел, әгәр дщ алдыннан хисси танып белү һәм тойгылар булмаса
- Тойгы-хисләр танып белүче субъектның тормыштагы предметларның аркасында барлыкка килә

**Эпикурның кеше һәм аның тәртибе турындагы тәгълиматы (эстетика)**

**Төп положениеләр**

- **Үзенең дөньяга килүе белән үз-үзенә бурычлы (ата-аналарына)**
- Кеше биологик эволюция нәтиҗәсе ул
- Аллалар, мөгаен бардыр, тик алар кешеләр тормышына һәм җир эшләренә берничек тә кысыла алмыйлар.
- Кеше язмышы аның үзеннән һәм хәл-вакыйгалардан бәйле, әмма алларга бәйле түгел
- Җан материянең үзенчәлекле төре ул
- Җан, тән кебек үк үлә
- Кеше җирдәге тормышында бәхеткә омтылырга тиеш
- Кеше бәхете ләззәт алудан тора
- Ләззәт сүзе астында газаплар юклыгы, сәламәтлек, яраткан эш белән шөгыльләнүне аңлыйлар
- Акыллы чикләү (теләк, ихтыяҗ), тыныч булу һәм рәхәтлек, акыллылык тормыш нормасына әверелергә тиеш

# 19нчы сорау. **Урта гасырның теологик фәлсәфәсе**

## *1.Урта гасыр теологик фәлсәфәнә гомуми төшенчә һәм төп сыйфатлары*

**Урта гасырлар теологик фәлсәфә – Европада V-XVI гасырларда таралучы әйдәүче фәлсәфә юнәлеше, ул Алланы югары башлангыч сыйфатында, ә әйләнә-тирә дөнья -аның иҗаты дип кабул итте**

### Үзенчәлекләр

- **Әле б.э.ның I-V гасырларда яшь христианлык, дин кануннарына каршы чыгу һәм антик фәлсәфә нигезендә Рим империясендә үк ярала . Үзенең иң югары үсешен б.э.ның V-XIII гасырларында ирешә.**
- Үз үзенә йомылу, традиөионлыгы, үткәннәргә юнәлтелгән булуы,реаль дөньядан аерылган булуы, сугышчанлыгы, үгет-нәсыйхәтлегә белән аерылып тора.

### Иң күренекле вәкилләре

- **Тертуллиан Карфагенский (160-220)**
- Хозур Августин (Блаженный) (354-430)
- Боэций (480-524)
- Бөек Альберт (Великий) (1193-1280)
- Фома Аквинский (1225-1274)
- Ансельм Кентерберийский (1033-1109)
- Пьер Абеляр (1079-1142)
- Уильям Оккам (1285-1349)
- Отрекурдан Николай (XIVгасыр)

### Төп сыйфатлары

- **Теоцентризм (барлык нәрсәнең асылы сәбәбе, югары чынбарлык, фәлсәфәнең төп өйрәнү предметы дип Алланы исәплиләр)**
- Космосны, табигатьне, әйләнә-тирә күренешләрне өйрәнүгә игътибар аз бирелә, чөнки алар алла иҗаты итеп кабул ителә
- Догаматлар хөкем итә(дәлилләүне таләп итмәгән хакыйкатьләр) иҗат туранда( барысы да Алладан) һәм ачышлар ( Алланың үзе үзе турында – Библиядә)
- Материализм һәм идеализм арасындагы каршылыкларны шомарту
- Кеше табигатьтән бүленеп чыга һәм табигать өстендә торучы Алла иҗаты итеп кабул ителә
- Кешене киләчәктә (аллага ярашлы яшәгән хәлдә) мәрхүмнәр арасынна кабаттан терелтү идеясе дә тәкъдим ителә
- Дөнҗяны Алланы танып белү аша танып белеп була дип исәплиләр, ул Аллага ышану аша гамәлгә ашырыла

## *2. Иҗат һәм ачышлар идеяләре (догматлар). Урта гасыр теологик фәлсәфәдә яхшылык һәм явызлык мәсьәләсе*

**Урта гасыр теологик фәлсәфә**

**Төп нигезле догматлар**

**Иҗат итү догматына ярашлы**

- **Алла әйләнә-тирә дөньяны юктан яраткан (барлыкка китергән)**
- Дөньяны барлыкка китерү Илаһи ихтыяр нәтиҗәсе ул
- Дөнья чиксез куәтле алла ярдәшмендә тудырылган
- Табигать үзен үзе тудыра алмый
- Галәмдәге бердәнбер иҗади башлангыч ул Алла
- Алла мәңгелек, даими һәм бар нәрсәгә керә ала
- Чын яшәеш ул тик Алла
- Алла һәм аның иҗаты арасында төгәл чик юк

**Ачыш догматына ярашлы**

- Дөньяны Алланы аңлаганнан соң гына танып була
- Алланы танып белү мөмкин түгел
- Аллана танып булмаса да, ул үзен Библия ачышлары аша танып белергә рәхсәт итә
- Алланы һәм барлык асылны танып белүнең бердәнбер ысулы – Библия аңлатмалары
- Алланы гадәттән тыш юл белән, кешенең үзенчәлекле сәләте - ышану аша гына танып була

**Иҗат итү идеясеннән чыгып яхшылык һәм явызлык мәсьәләсен хәл итү**

- **Әйләнә-тирә дөнья Алла белән ярatылгын (барлыкка китерелгән)**
- Алла яхшылык һәм гаделлек җыелмасы һәм таратучы ул
- Димәк, әйләнә-тирә дөнья баштан ук яхшылык белән тулы
- Явызлыкны дөньяга иблис (шайтан) алып килә – Аллага каршы күтәрелүче бозык фәрештә
- Дөньяда иэ элек явызлык булмаганлыктан, ул еш кына кара максталыры белән яхшылык астына яшеренә
- Дөньяда дами рәвештә яхышылк һәм явызлык күрәше бара, тик дөнья Алла иҗаты булганга һәм Алла яхшы булганга,яхшылык һәровакытта да явызлыкны җиңәчәк.

Урта гасыр теологик фәлсәфәсенең яхшылык һәм явызлык мәсьәләсе оптимистик характерлы

## *3. Урта гасыр теологик фәлсәфәсендә асыл һәм барлыкны бүлеп карау*

**Урта гасыр теологик фәлсәфә**

**Урта гасыр теологик фәлсәфә ( антиктан аермалы буларак) материя һәм идеяне, материализм һәм идеализмны капма-каршы куймый диярлек. Әмма шул ук вакытта борынгы грек фәлсәфәсендә бердәм асыл - яшәешне исәпләгәнне, теологик фәлсәфә дә уртаклаша**

Экзистенциягә (яшәеш, барлык) – бөтенләй әйбер бармы-юкмы икәнен күрсәтә

**Эссенциягә (асыл), әйберне характерлаучы**

- ✔**Нәрсә ул әйбер?**
- ✔Нинди әйбер ?
- ✔Нәрсә өчен ул бар?

**Урта гасырның теологик фәлсәфәсенең төп положениеләре**

- ✔**Асыл һәм барлыкны өзелмәс берлектә караган, бердәм асыл –яшәеш ул дигән антик фәлсәфәчеләрдән аермалы буларак, теологик фәлсәфәгә ярашлы асыл яшәештән башка да була ала.**
- ✔Башка төрле әйткәндә тәнсез асыл Алла аңыннан укый һәм аның ихтыяры белән һәм аңа гына хас булган иҗат итү сәләте аркасында гына материаль яшәеш була ала
- ✔Барлык хисси тойгылар, тәҗрибә белән(бар булган һәм танып белерлек) адлана алына, асыл исә – тик акыл белән.
- ✔Аллада гына асыл һәм барлык туры килә

# 4.Схоластика, номинализм, реализмның гомуми төшенчәсе.

**<u>Схоластика</u>** — урта гасыр теологик фәлсәфәнең хөкем итүче төре, аның аермалы сыйфатлары – реаль чынбарлыктан аерым булуы, йомыклыгы, консерватизм, чикле догматизм, тулы һәм берсүзсез дини идеяләргә буйсыну, схемалылык, үгет-нәсыйхәтлелек,укытучанлык.

***Хас сыйфатлар***

«***<u>Схоластика"</u>*** атамасы латин теләндәгн *schola* (мәктәп) сүзеннән барлыкка килә, чөнки бу төр фәлсәфә берничә йөз ел мәктәпләрдә һәм Европа университетларында укытыла. Шулай итеп, схоластика үзе белән иҗади эзләнү белән шөгыльләнүче фәнне генә түгел, ә мөгаен дини тәгълимат һәм чиркәү догматларын фәлсәфи нигезләргә максат куйган катып калган мәктәп-университет фән төрен гәүдәләндерә (моның өчен ул "Фәлсәфә — дин тәгълиматы хезмәтчесе» кушаматына ия була).
Схоластика өчен Библияне каты норматив текст, абсолют хакыйкать буларак үзләштерү хас.

***Схоластика белемне ике төргә бүлә:***

***• гадәттән тыш , ачышларда бирелүче (ягъни Библиягә тегe яки бу фикерне кертер алдыннан Алла ни уйлаган, шул);***
***• табигый, кеше акылы белән эзләп табыла торган (ягъни кеше Библиядән аңлауга ирешә алганнар, ул Алла идеяләрен ничек аңлаган).***

Шул уңайдан схоластлар күпләгән бәхәсләр алып бара, йөзләгән фәлсәфи томнар яза, аларда Библия юлларында яшеренгән Алла идеяләрен дөрес аңларга тырышалар. Бәхәс предметы булып Алла идеясенең асылы түгел, ә төшенчәләрнең, билгеләмәләрнең дөреслеге һәм төгәллеге, икенче төрле әйткәндә дини тәгүлиматның тышкы, формаль-логик ягы.

Урта гасыр теологик фәлсәфәсендә (схоластикада) ике капма-каршы юнәлешләр бүленеп чыгая - **номинализм һәм реализм.**

**Реализм** - телогик фәлсәфә юнәлеше, аның яклылар әйберләрне үзләрен бар дип түгел, ә аларның гомуми төшенчәләрен – универсальләр (мәгүнәсе буенча реализм Платонның «саф идеяләр» турындагы тәгүлиматына якын).
Реализмның күренекле вәкилләре Ансельм Кентерберийский, Шамподан Гильом.

**Номинализм** (от лат. *nomen* — исемнәр) — теологик фәлсәфә юнәлеше, аның яклылар конкрет әйберләнең үзләрен генә реаль булган дип таныйлар, ә шул ук вакытта гомум төшенчәләрне (универсалияләр) әйбреләр исемнәре дип кабул итәләр. (Мәгънә ягыннан номинализм «саф идеяләрне" инкарь иткән һәм материаль әйберләрне билгеләүче "индивидуум"нарны реаль дип исәплгән Аристотель тәгълиматына якын) Номиналистларга ярашлы, универсалияләр әйберләргә чаклы түгел, алардан соң бар була, ә әйберләр хисси тәҗрибә белән танып беленә.
Номиналистларга Росцелин, Пьер Абеляр, Дунс Скот керә.

## *5. Урта гасыр теологик фәлсәфә әһәмияте*

**Урта гасыр теологик фәлсәфәнең** киләчәк фәлсәфә үсеше өчен әһәмияте түбәндәгеләрдә:

• антик фәлсәфә һәм Яңарыш чоры, яңа вакыт фәлсәфәсе арасында бәйләүче буын булды;
•антик фәлсәфә идеяләрен саклады һәм үстерде, чөнки ул антик фәлсәфәнең христиан тәгълиматы нигезендә барлыкка килде;
• фәлсәфәне яңа өлкәләргә таркатуга булышлык итә (тулысынча антик фәләсфә белән кушылган онтология — яшәеш турындагы тәгълиматтан тыш, гносеология — танып белү турындагы мөстәкыйль тәгълимат бүленеп чыга);
• иделаизмның объектив һәм субъективка бүленеүенә булышлык итә;
• киләчәктә эмпиристик (Бэкон, Гоббс, Локк) һәм рациональ (Декарт) фәлсәфә юнәлешләре барлыкка килүгә нигез сала. Номиналистлар эшчәнлегенең нәтиҗәсе буларак алар тәҗрибәгә таяну (эмпиризм) һәм бик нык үзаң мәсьәләсенә кызыксынуга (Я-концепция, рационализм)таяна;
• тарихи процессны аңлауга кызыксыну уята;
• яхшылыкның яманлыкны җиңүе һәм кабаттан терелү ышанычында чагылган оптимизм идеясен тәкъдим итә.

# 20нче сорау. Хозур Августин (Блаженный) фәлсәфәсе

**Аврелий Августин (Блаженный)** (354 — 430) — христиан теологы, Гиппон шәһәре епископы. (Төньяк Африка, Рим империясе), шул чордагы христиан диненең төп юнәлеше булган католицизмга нигез сала.

Яшь схоластикага нигез салучыларның җберсе була. Хозур Августинның (Блаженный) төп әсәре — «Аллаһ йорты турында" — йөзәр еллар эчендә дини-фәлсәфи трактат була, аңа урта гасыр теологлары схоластиканы өйрәнгәндә һәм укытканда таяналар.

## Төп положениеләр

- тарих барышы, җәмгыятҗ тормышы — ул ике капма-каршы патшалыклар —Җир (гонаһлы) һәм Илаһи көрәше;
- Җир патшалыгы дәүләт учреждениеләрендә, власть, армия, бюрократия, закон, императорда гәүдәләнә;
- Илаһи патшалык дин әһелләре — христиан Чиркәвенә берләштерелгән, бәрәкәт бүлеп бирелгән һәм Аллага якын булган

- Җир патшалыгы гөнаһларга һәм мәҗүсилеккә баткан һәм иртәме соңмы Илаһи патшалыктан җиңеләчәк ;
- моңа бәйле күпчелк кешеләр гөнаһлы һәм алладан ерак, дөньяви (дәүләт) власте кирәк һәм алга таба да яшиячәк, тик дини властька буйсына;
- корольләр һәм императорлар үз ихтыярын христиан чиркәвенә генә белдерергә һәм буйсынырга тиешләр, ә тагы да турыдан –туры Рим Атакаена;
- Чиркәү — дөнҗяны берләштершә алырлык бердәнбер көч;
- хәерчелек, башкаларга бәйлелек (ростовщиклар, җир хуҗалары һ.б.), Аллага яраклы түгел, тик әлегә ул күренешләр яшәп килә, аның белән килешергә һәм түзәргә, яхшыга ышанырга кирәк;
- югары рәхәтлек— кеше бәхете, ул үз-үзеңә тирәнәю, хакыйкатьне төшенү итеп аңланыла;
- үлгәннән соң хыянәтсез, тәкъва яшәүчеләр Алладан бүләккә тег дөнҗядагы тормыш алалар.

Хозур Августин (Блаженный) фәлсәфәсе

*Алла турында фикерләве*

• Алла бар;
• Алла барлыгының төп дәлиле аның барлык нәрсәдә булуында, зур кодрәт һәм камиллеге;
• барлык нәрсә — материя, җан, пространство һәм вакыт — Алла иҗаты;
• Алла дөньяны гына яратмаган, әле дә иҗат итүен дәвам итә, киләчәктә дә иҗат итәчәк;
• белем (хисләр, фикерләр, тойгылар, тәҗрибә) реаль һәм үз-үзенә җитәрлек, әмма югары, хакыйкый, кире какмаслык белм бары тик Алланы танып белү аша гына ирешелә.

*Хозур Августин (Блаженный) фәлсәфәсе әһәмияте*

• тарих мәсьәләсенә зур игътибар бирелә (ул чор өчен сирәк күренеш);
• Чиркәү (еш кына дәүләт хакимлегендәге һәм Рим империясе тарафыннан әзерлекләнгән) шулай ук дәүләт власте белән ук власть итеп игълан ителә (ә дәүләт элементы түгел);
• Чиркәүнең дәүләт өстеннән хакимлеге нигезләнә, ә Рим Атакае — монархлардңан — төп идея, аны тәкүдим иткән һәм тормышка ашырылуы өчен Чиркәү Августин Блаженныйны хөрмәт итә һәм алла кебек күрә, аеруча урта гасырларда;
•тәкъдим ителгән социаль конформизм идеясе (фәкыйрьлек һәм чит власть белән килешү),бу шулай ук Чиркәүгә дә, дәүләткә дә отышлы;
• кеше, аның матурлыгы, көче, камиллеге данлана (ул чор өчен сиркә була һәм барысын да ошый);
• бер үк вакытта кешегә җенси теләкне бетергә, рухны үстерергә һәм данларга, Алланы танып бюелергә һәм буйсынырга тәкүдим ителә.

# 21нче сорау. Фома Аквинскийның фәлсәфәсе

**Фомы Аквинский фәлсәфәсе**

**Фома Аквинский** (1225 — 1274) — доминикана монахы

Урта агсыр теологик фәлсәфәнең күренекле фәлсәфәчесе, схоластиканы системага китерүче, *томизм* авторы — католиклар Чиркәвенең хөкем итүче юнәлеше.
Фомы Аквинскийның төп әсәрләре: «Теология суммасы ", «Философия суммасы" («Мәҗүсиләргә каршы"), Библиягә, Аристотель әсәрләренә аңлатмалар.
**2.**Фома Аквинский Алла барлыгының онтологик дәлилләүне җитәрлек түгел дип исәпли (ягъни Хозур Августин (Блаженный) исәпләгән Алла барлыгы аның иҗат иткәннәреннән чыгарылган «бәхәссез"дәлиле— әйләнә-тирә).

**Фома Аквинскийның Алла барлыгы турындагы биш үз дәлиле**

- хәрәкәт: нәрсә хәрәкәт итә, шул кем тарафыннандыр хәрәкәт иттерелә (нәрсә беләндер) — димәк, барысын да беренчел хәрәкәт иттерүче — Алла;
- сәбәп: нәрсә бар, аның үз сәбәсе була— димәк, беренчел сәбәп ул — Алла;
- очраклылык һәм зарурилык: очраклы зарурига бәйле — димәк, беренчел зарурилык ул Алла;
- сыйфат дәрәҗәләре: нәрсә бар, төрле дәрәҗәдәге сыйфатка ия (яхшырак, яманрак, зуррак, кимрәк һ.б.) — димәк, иң югары камиллек — Алла яшәргә тиеш;
- максат: әйләнә-тирә дөньяда нинди дә булса максатка ия, максатка юнәлә, мәгънәсе бар - димәк, барысын да максатка юнәлтүче ниндидер акыллы башлангыч бар, ул барысына да мәгүнә бирә – ул Алла.

Фома Аквинский Алла барлыгының онтологик дәлилләвен җитәрлек түгел дип исәпли (ягъни Хозур Августин исәпләгән Алла барлыгы аның иҗат иткәннәреннән чыгарылган «бәхәссез» дәлиле – әйләнә-тирә)

# Фома Аквинский фәлсәфәсе

Яшәеш мәсьәләсен тикшереп, Фома Аквинский

Шулардан чыгып, Фомага ярашлы:
•бар нәрсә материя формаларыннан тора(идеяләр)
• һәр әйбернең асылы —форма һәм материя берлеге;
• форма (идея) билгеләүче башлангыч була, ә материя төрле формалар савыты;
• форма (идея) бер үк вакытта әйбер барлыкка килүмаксаты да;
• теләсә кайсы әйбер идеясе (форма) өч кисәктән тора: Илаһи акылда, әйбернең үзендә, кешенең үзләштерүендә(хәтерендә) яши.

✔Эмпиризмның рационализм өстеннән хакимлеге (Англия үз вакыты өчен танып белү мәсьәләләрендә эмпиризм җиңгән сирәк ил булды — фәлсәфи юнәлеш, кайда танып белүдә әйдәүче рольне тәҗрибәгә һәм хисси үзләштерүгә бирелә, ә рационализм кебек акылга түгел);

✔социаль-сәяси мәсьәләлргә зур кызыксыну (Англия фәлсәфәчеләре яшәеш һәм танып белү асылын, кешенең дөньядагы ролен аңлатырга гына тырышмаган, бер ук вакытта җәмгыять һәм дәүләт барлыкка килү сәбәбен эзлиләр, реаль булган дәүләтләрне оптималь оетыру проектларын чыгаралар). Англия фәлсәфәсе XVII гасыр

# Яңа вакыт инглиз фәлсәфәсе (XVII — XVIII гасырлар)

*XVII — XVIII гасыр инглиз фәлсәфәсенең характерына зур йогынты ясаган сәяси вакыйгалар*

- ✔XVIIгасыр уртасы Оливер Кромвель революциясе (корольне тәхеттән төшерү һәм җәзалап үтерелә, республиканың аз яшәве, индепендентлар хәрәкәте);
- ✔1688 елгы «данлыклы революция (инкыйлаб)";
- ✔протестантизмның католицизмны җиңүе, англикан Чиркәвенең эчке автономиягә ирешүе, аның Рим Атакаеннан бәйсезлеге;
- ✔Парламент ролен ныгыту;
- ✔Яңа буржуаз иҗтимагый-икътисадый мөнәсәбәтләр үсеше;

*Яңа вакытның инглиз фәлсәфәсе вәкилләре*

- ✔Фрэнсис Бэкон — эмперистик (тәҗрибәле) юнәлешкә нигез салучы дип исәпләнә;
- ✔Томас Гоббс (дәүләт мәсьәләлренә зур игътибар бирә, "Левиафан «китабы авторы, «иҗтимагый килешү» идеясен тәкъдим итә);
- ✔Джон Локк (дәүләт мәсьәләләрен өйрәнә, Т. Гоббс традициясен дәвам итә);

## 2. Ф. Бэкон фәлсәфәсендә танып белү мәсьәләсе

**Ф. Бэкон фәлсәфәсендә танып белү мәсҗәләсе** (Фрэнсис Бэкон (1561-1626) – инглиз фәлсәфәчесе һәм сәяси эшлеклесе (1620-1621 елларда – Бөекбританиянең лорд-канцлеры, корольдән соң икенче вазыйфалы зат), фәлсәфәнең эмпиристик (тәҗрибәле) бнәлешенә нигез салучы)

***Ф. Бэкон фәлсәфәсе әһәмияте***

✔Фәлсәфәнең эмпиристик (тәҗрибәле) юнәлешенә нигез салына;

✔гносеология (танып белү турындагы фән) фәлсәфәнең икенчел өлкәсеннән онтология (яшәеш турында фән)дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә һәм теләсә кайсы фәлсәфә системасының ике төп бүлегенең берсенә әйләнә;

✔Фәлсәфәнең яңа максаты билгеләнә – кешегә аның эшчәнлегендә гамәли нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итү (шуның белән Бэкон киләчәк америка прогматизмына читләтеп булса да нигез сала);

✔Фәнне класификацияләүгә беренче омтылыш ясала;

✔Англиянең, шул ук вакытты тулысынча Европаның антисхоластик, буржуаз фәлсәфәсенә этәргеч бирелә;

# Ф.Бэкон фәлсәфәсендә танып белү мәсьәләсе

**_Төп положениеләр_**

✔Фрэнсис Бэконның төп фәлсәфи идеясе-эмпиризмның асылы — танып белү нигезендә фәкать тәҗрибә ятуда;
✔Тәҗрибә күбрәк булган саен, (теоретик та, шулай ук практик та) кешелек туплаган (һәм аерым кеше), шулкадәр алар хак белемгә якынрак;
✔Хак белем, Бэкон буенча, үзмаксат була алмый;
✔Белем һәм тәҗрибәнең төп бурычлары — кешегә үз эшчәнлегендә гамәли нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм, яңа ачышлар барлыкка килүгә булышлык итү, икътисад үсешенә, кешенең табигатькә өстенлегенә. Моңа бәйле Бэкон тарафыннан аның фәлсәфи кредосын кыскача билгеләгән афоризм әйтә: «Белем — көч";

**_Танып белүнең төп методы буларак индукция_**

**_Үзенчәлекләр_**

✔ *индукция астында* фәлсәфәче күпләгән аерым күренешләрне гомумиләштерү һәм гомумиләштерү нигезендә гомуми нәтиҗәләр алуны аңлаган (мәсәлән, әгәр дә күп кенә металлар эресә, димәк, барлык металлар да бу үзенчәлеккә ия, ягъни эриләр).
✔Индукция методын Бэкон Декарт тәкъдим иткән дедукция методына каршы куя, аңа ярашлы, хак белем чын мәгълүматка таянып логик ысуллар ярдәмендә алып була;
✔ Бэконның индукциясенең Декарт дедукциясеннән өстенлеге— мөмкинлекләрне киңәйтүдә, танып белү процессын интенсификацияләүдә;
✔Индукция кимчелеге — аның дөрес булмавында, мөмкин булу характердалыгы (әгәр дә җерничә әйбер яки күренеш уртак билгеләргә ия икән, бу шушы сыйныфтан булган барлык әйберләр һәм күренешләр дә шушы билгеләргә ия дигән сүз түгел; һәр аерым очракта индукцияне дәлилләү өчен экспетемент ясау кирәклеге барлыкка килә);
✔Индукциянең төп кимчелеген узу юлы (аның тулы булмавын, мөмкин булу характердалыгы), Бэкон буенча, — кешелекнең барлык белем өлкәләрендә күбрәк тәҗрибә туплауда;

# Проблема познания в философии Ф. Бэкона

*Танып белү эшчәнлеге барлыкка килергә ярдәм итүче конкрет юллар*

✔**«Үрмәкүч юлы"** — «саф акылдан« белем алу, ягъни рациональ юл белән. Әлеге юл конкрет фактларны, гамәли тәбрибәне санга сукмый яисә аларның ролен киметә. Рационалистлар реаль чынбарлыктан аерылган, догмалы һәм, Бэкон буенча, «үзләренең акылыннан үрмәкеч оясы үрәләр»;

✔**«Кырмыска юлы"** — мондый белем алу ысулы, игътибарга тәҗрибә генә кабул ителгәндә, ягъни догматики эмпиризм (тормыштан аерылган рационализмның капма-каршысы). Бу ысул шулай ук камил түгел. «Саф эмпириклар" игүтибарны гамәли тәҗрибәгә, берсенән-берсе аерылган фактлар туплауга, дәлилләүләргә юнәлтә. Шулай итеп, алар белемнеэ тышкы катинасын ала, проблемаларны тыштан, «читтән» күрә, әмма өйрәнеләсе әйбер һәм күренешләрнең эчке асылын аңлый, проблеманы эчтән күрә алмыйлар;

✔**«Бал корты юлы",** Бэкон буенча, — идеаль танып белү ысулы. Аны файдаланып, тикшерүче-фәлсәфәче «үрмәкүч юлы» һәм «кырмыска юлы»ның барлык яхшы якларын ала һәм шул ук вакытта аларның кимчелекләреннән азат була. «Бал корты юлы» буенча барып, фактлар җыелмасын тупларга, аларны гомумиләштерергә кирәк (проблемага «тыштан» карарга») һәм, акыл мөмкинлекләрен файдаланып, проблеманың «эченә» кереп карарга, аның асылын аңларга. Шулай итеп, Бэкон буенча, танып белүнең иң яхшы юлы дип индукциягә нигезләнгән эмпиризмны санарга була (фактлар туплау һәм гомумилштерү, тәҗрибә туплау) әйберләрнең һәм күренешләрнең эчке асылын аңлау рациональ ысулларын кулланып;

# Ф. Бэкон фәлсәфәсендә танып белү мәсьәләсе

*«Өрәк» («потлар»), кешегә каршы төшкән (кешелеклеккә хак белемнәр алу өчен)*

***Тумыштан килгән кеше ялгышлары***, алар танып белү табигатен үз табигатең белән кушудан гыйбарәт

*Алынган ялгышлар*

✔***Ыру шәүләсе*** – танып белүнең тулысынча кеше мәдәнияте (ыру) аша сынуы — ягъни кеше гомумкешелек мәдәнияте кысаларында булганда танып белүне гамәлгә ашыра, һәм бу нәтиҗәгә эз сала, белемнең хак булуын киметә;

✔***Мәгарә шәүләсе*** - **конкрет кеше шәхесенең (танып белүче субъектының) танып белүгә йогынтысы.** Нәтиҗәдә, кеше шәхесе (аның юк-барга ышануы, хаталары — «мәгарә") ахыр чиктәге танып белү нәтиҗәсендә чагыла;

✔***Базар шәүләсе*** – сөйләм, аңдау аппаратын дөрес, төгәл кулланмау: сүз, аңлатма, гыйбарәләр;

✔***Театр шәүләсе*** – **фәлсәфәдә яшәп килүче танып белү проөессына йогынты ясау. гадәттә танып белү вакытында иске фәлсәфә яңа ысул кулланырга комачаулый**, танып белүне һәрвакыт тиешле юнәлешкә җибәрми (мисал: урта гасырларда схоластиканың танып белүгә йогынтысы);

## 3. Классификация наук Ф. Бэкона

| Свойства человеческого ума | Служит основанием | Классификация наук Ф.Бэкона |
|---|---|---|
| Хәтер | ↔ | Тарихи фәннәр |
| Хыял | ↔ | Шигърият |
| Акыл | ↔ | Фәлсәфә |

**Бэкон буенча фәлсәфә предметы:**

- Табигать
- Алла
- Кеше

**Кешенең танып белү ысуллары:**

- Турыдан-туры хисси үзләштерү ярдәмендә тәҗрибә белән
- Табигать аша
- Рефлексия ярдәмендә (фикернең үз-үзенә юнәлдерелүе, фикерне фикерләү аша өйрәнү)

# *4. Т. Гоббс фәлсәфәсе*

***Томас Гоббс( 1588-1679) – Ф.Бэкон укучысы һәм фәлсәфи традиөияләренең дәвамчысы***

Фәлсәфи фикерләр:

Теологик, схоластик фәлсәфәне катгый кире кага.

Кеше эшчәнлегендә гамәли нәтиҗәләргә ирешүдә, фәнни-техник прогресска булышлык итүдә ул фәлсәфәнең максаты дип билгели.

Эмпиризм (тәҗрибәле танып белү) һәм рационализм (познанием с помощью разума) арасындагы бәхәстә эмпиризм ягында була; Декартның рационалистик фәлсәфәсен тәнкыйтьли.

Инанган материалист була.

Җәмгыять һәм дәүләт мәсьәләләрен мөһим фәлсәфи проблемалар дип саный.

Дәүләт теориясе эшкәртеп чыгара.

Беренче булып дәүләт барлыкка килү нигезендә иҗтимагый (бердәм) килешү ята дигән идея тәкъдим итә.

# 5. Т. Гоббсның танып белү һәм дәүләт турындагы тәгълиматы

**Гоббсның фәлсәфи тикшеренүләр предметы**

**Гносеология** (танып белү турындагы тәгълимат): Т.Гоббс танып белү методы сыйфатында индукция һәм дедукциянең бер үк вакытта куллану өчен чыгыш ясый. Кеше танып белүгә тою аша ирешә дип исәпли. Тойгылы танып белү – сизү органнарының (күз, колак h.б.) әйләнә-тирә дөнҗядан сигналлар алуы һәм аларның эшкәртелүе. Мондый сигналларны Т. Гоббс *«билгеләр» дип атый.*.

**Җәмгыять һәм дәүләт мәсьәләсе,** Гоббс буенча,- фәлсәфәдә ул төп, чөнки аның максаты – кешегә үз эшчәнлегендә гамәли нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итү, ә кеше җәмгыятҗтә һәм конкрет дәүләттә.

Билгеләр классификациясе

- ✔Сигналлар-хайваннар тарафыннан хәрәкәт яки теләкләрен белгертү өчен чыгарылган авазлар (кошлар «җырлавы», ерткычлар ырылдавы h.б.лар);
- ✔Тамгалар- кеше тарафыннан аралашу өчен уйлап чыгарылган төрле билгеләр;
- ✔Табигый тамгалар- табигать «сигналлары» ( күк күкрәү, яшен, болытлар h.б.лар)
- ✔Ирекле коммуникатив тамгалар- төрле тел сүзләре;
- ✔Билге урынындагы «тамгалар» – махсус кодлаштырылган сөйләм, күпләргә аңлашылмагын ( фәнни тел, жаргон , дин теле h.б.);
- ✔Билгеләрнең билгесе – исемнәрнең исеме – универсалияләр (гомуми төшенчәләр).

Җәмгыять һәм дәүләт турында теория

- ✔Кеше табигате баштан ук явыз;
- ✔Кеше белән хәрәкәт иттеруче көч - шәхси табыш һәм эгоизм, ихтыяҗ, страсти, аффектлар;
- ✔Саналган сыйфатлар һәр кешене барысына да хокуклы булуны тоюга китерә;
- ✔Кешенең теләсә нәрсәгә хокуклы булырга һәм башкалар ихтыяҗларына битараф булуы аны»барысына да каршы»га китерә,аларда җиңүче юк, ул кешеләрнең үзара бергәләп яшәү мөмкинлеген һәм икътисадый прорессны мөмкин түгел ясый;
- ✔ Бергә исән калу максатында кешеләр иҗтимагый килешү төзи, анда алар үзләренең дәгъва итү һәм «барысының да барысына да хокуклы булу»ны чиклиләр;
- ✔ җәмгыятҗ тормышы-дәүләт тормышын тәртипкә салу, «Барысына каршы сугыш»ны туктату, чикле эгоизмны басу өчен иҗтимагый институт( механизм) барлыкка килә;
- ✔Авыр функцияләрне нәтиҗәле башкару өчен дәүләт чиксез көчле булырга тиеш;
- ✔Дәүләт- нык, күптөрле, гаять көчле албасты- «Левиафан», ул «үз юлында һәммә нәрсәне йота һәм себереп үтә,каршы торалмаслык көч, әмма ул җәмгыять эшчәнлеген алып бару, тәртип һәм гаделлек тоту өчен кирәк.

# *6. Дж. Локк фәлсәфәсе. Tabula rasa. Власть бүленеше.*

**Джон Локк** ( 1632-1704) Бэкон һәм Гоббсның күп кенә фәлсәфи идеяләрен үстерә, берничә үз теориясен тәкъдим итә, Яңа вакыт инглиз фәлсәфәсенең эмпиристик һәм материалистик традицияләрен дәвам итә.

**Дж.Локк фәлсәфәсенең төп положениеләре**

- дөнья материалистик;
- Танып белү нигезендә бары тик тәҗрибә ята ( «моңа кадәр тойгыларда булмаган нәрсә кеше акылында юк»;
- Аң- гомер юарышында тәҗрибә белән тулган буш бина, ( моңа бәйле Локкның аң турында «чиста такта» дигән( кайда тәҗрибә языдып бара) гыйбарәсе бар;
- Тәҗрибә чыганагы булып тышкы дөнья тора;
- Фәлсәфә максаты- кешегә үз эшчәнлегендә уңышка ирешергә булышу;
- Кеше идеалы- тыныч, законнан чыкмаучы, әдәпле кеше,ул үзенең белем дәрәҗәсен арттыра һәм һөнәрендә яхшы уңышларга ирешеә;
- Дәүләт идеалы- власть бүленеше законнар чыгару, башкару (шул исәптән судныкы) һәм федеральга (тышкы сәясәт)нигезләнгәе дәүләт. Локк шушы идеяне тәкъдим иткән беренче кеше була, һәм монда аның зур казанышы.

# 30нчы сорау. Лейбниц фәлсәфәсе. Монадалар турында тәгълимат.

**Лейбниц фәлсәфи тикшеренүләренең төп юнәлешләре** *( Готфрид Лейбниц)*, Яңа вакытның күренекле вәкиле, немец фәлсәфенә элгәре вәкил.

**Субстанция мәсьәләсе**

**Декарт һәм Спинозаның субстанция турындагы теориясен яңабаштан аңлау**

- ✔ Декарт һәм Спинозаның субстанцияләр турындагы идеяләрне тикшергәч, Лейбниц аларның камил булмавы турында нәтиҗәгә килә.
- ✔ Беренчедән, Декарт дуализмын кабул итми, барлык субстанцияләр бүленеше мәгънәсендә (үз булмышы өчен үзеннән башка бернәрсәгә дә мохтаҗ булмаган асыллар), бер яктан, Алла яраткан, тик аңа бәйсез субстанцияләр, икенче яктан- бар булган – матдига (озайтылган һәм рух (фикерләүче).
- ✔ Икенчедән, Лейбниц фикеренчә, Спиноза субстанцияләрне бергә берләштереп (Табигать-Алла), Декартане дуализмын уза алмый, чөнки үз барын да модусларга бүлә ( бердәнбер әйберләр субстанция чагылышы) ике класска- озайтылган һәм фикерләүче; ягъни Декартта нәрсә ике төр субстанция булган төшенчәләр, Спинозада бер субстанциянең аналогик модуслар төренә әйләнә (чагылыш).

**Монадалар турындагы теория ( субстанцияләренң күплеге)**

**Төп положениеләр**

- ✔ Бар дөнья дуалистик булмаган, ә бербөтен табигатьле бик күп субстанцияләрдән тора (Декарт һәм Спинозадагы кебек ике төрле);
- ✔ Әлеге субстанцияләр **монадалар дип атала** (грекчадан- «бердәнбер», «бер»);
- ✔ Монада гадиа, бүленми озынлыгы юк, матди- әйбер түгел;
- ✔ Монада дүрт сыйфатка ия: омтылыш,теләк, үзләштерү, күзаллау;
- ✔ Үзенең асылы белән монада- ул бердәм, өзлексез үз торышын үзгәретеп торучы эшчәнлек;
- ✔ Үзенең яшәеше өзлексез булу сәбәпле, монада үзен төшенеп җитә;
- ✔ Монадалар абсолют йомык һәм бер-берсенә бәйсез (Лейбниц фикеренчә, « нәрсә булса да керә алвырдай һәм аннан чыга алырдай тәрәзәләре юк»).

**Монада класс** (класс югарырак булган саен, аның акылы һәм иреклек дәрәҗәсе югарырак).

- ✔ «ач монадлар» - терек булмаган табигать нигезендә ята ( ташлар, җир, файдалы казылмалар);
- ✔ Хайваннар монады- хис-тойгыга ия, тик үсешмәгән үзаң белән;
- ✔ Кеше монадалары( җан) – аң, хәтер, акылның уникалҗ фикерләү сәләтенә ия;
- ✔ Югары монада-Алла.

**Готфрид Лейбниц( 1646-1716)** – немец математик -галим, юрист, фәлсәфәче – соңгы классик фәлсәфәче дип санала. Рационализм юнәлешенә карый..

**Гносеология мәсьәләләре.**

Эмпиризм һәм рационализмны килештерергә тырышу.

- ✔Барлык белемне ике төргә бүлә- «акыл хакыйкате» һәм «факт хакыйкате»;
- ✔«акыл хакыйкате» акылның үзеннән бүлеп чыгарыла, логика ярдәмендә дәлилләнә ала, гомуми кирәк характерда була;
- ✔«факт хакыйкате» - эмперистик (тәҗрибә) юлы белән алынган белем (мәсәлән, магнит тартымы, суның кайнау температурасы, төрле металларның эрү температурасы); кагыйдә буларак, әлеге белемнәр фактны билгеләп кенә үтә, әмма аның сәбәпләре турында әйтми;
- ✔Тәҗрибәле (эмпиристик, «факт хакыйкате» ) ихтималлык белеме булуга карамастан, аны белем буларак кире кагып булмый;
- ✔Шулай итеп, танып белү ике белем төренең берсен – раөиональ яки тәҗрибә ярдәмендә белем алу аша гына башкарылмый, ә ике төрен үзләштерү кирәк.

# 31нче сорау. XVIII гасыр Француз мәгърифәтчелеге фәлсәфәсе. Гомуми характеристика

XVIII гасыр француз фәлсәфәсен Мәгърифәтчелек фәлсәфәсе дип атарга кабул ителгән. Мондый атама бу чор фәлсәфә аның вәкилләренең Алла, әйләнә-тирә дөнья һәм кеше турындагы күнегелгән күзаллауны җимерүгә бәйле ала, алар үзләренең фәлсәфи тикшеренүләрендә новаторлык күрсәтәләр, туып килүче буржуазия идеяләрен ачыктан-ачык пропаганда ясыйлар, һәм, ахырда, 1789 — 1794 елгы Бөек француз революциясен идеологик яктан әзерлиләр.

**Төп юнәлешләр**

## Деизм

**Сыйфатламасы**

- Шәхси Алла идеясен кире кагалар;
- Алла һәм Табигатьне тиңләштерү белән килешмиләр (пантеизм белән);
- Аллада барлык булганның башлангычын күрәләр (тик моннан ары түгел);
- Алланың табигать һәм кешеләр эшенешә тыгыла алуын, тарих барышына, үзе тудырганнан соң әйләнә-тирәгә йогынты ясый алуын кире кагалар.

**Вәкилләр**

- Вольтер
- Монтескье
- Руссо
- Кондильяк

## Атеистик-материалистик юнәлеш

**Атеистик-материалистик юнәлеш: бу юнәлеш яклылар Алла барлыгы идеясен үзен кире кагалар**, дөнья һәм кеше барлыкка килүне материалистик һәм табигый-фәнни позициядән чыгып аңлаталар, танып белү мәсьәләләрендә эмпиризмга өстенлек бирәләр.

**Вәкилләр**

- Мелье
- Ламетри
- Дидро
- Гельвеций
- Гольбах.

## Утопик-социалистик юнәлеш

**Француз Мәгърифәтчелек фәлсәфәсенең утопик-социалистик (коммунистик) юнәлеше XVIII гасыр уртасында формалаша башлый.** 1789 — 1794 елгы **Бөек француз революциясе вакытында һәм ул тәмамланганнан соң таралыш ала.**

**Вәкилләр**

- Мабли
- Морелли
- Бабеф
- Оуэн
- Сен-Симон.

32нче сорау. XVIII гасыр француз Мәгърифәтчелегенең деистик фәлсәфә юнәлеше.

*1. Фәлсәфә юнәлеше буларак деизм*

. **Деизм** - фәлсәфәдәге юнәлеш, аның яклылар Ала барлыгын беренчел сәбәп итеп кенә булу ихтималлыгын хуплыйлар, бар булганны тудыручы буларак, әмма Аны китләчәктә әйләнә—тирәгә, кешегә, тарихка йогынты ясаучы буларак кире кагалар, Алланы зат рәвешендә кабул итүне дә (кеше сыйфатларын бирүне), табигать белән тиңләшүгә дә каршы чыгалар(пантеизм).

Күренекле француз фәлсәфәчеләре

- Вольтер
- Монтескье
- Руссо
- Кондильяк

## 2. Вольтер фәлсәфәсе. «Мәгърифәтле абсолютизм»

**Вольтер** (чын фамилиясе —**Аруэ) Франсуа** (1694 —- 1778) — фәлсәфәче, язучы, публицист, француз Мәгърифәтлегенә нигез салучыларның берсе.

Фәлсәфи карашлар

- ✔Дингә каршы чыгыш ясый, аеруча католицизмга каршы (дингә кагылышлы аның түбәндәге сүзләре бар: «Кабәхәтне сытыгыз!");
- ✔ Алланы әйләнә-тирәне барлыкка китерүче итеп исәпли, бар нәрсәне бәйләүче башлангыч дип карый, тик бернинди дә теория, бернинди дә практика аның барлыгын да, Аның юклыгын да дәлилли алмый дип ышана;
- ✔җәмгыятьтәге тәртипне саклау, кешеләрне буйсындыру (Аллаһ җәзасы куркынычы астында) һәм әхлак кысаларында тоту өчен Алла барлыгын әхлакый-эстетик фикер ягыннан кабул итү кирәклеген таный;
- ✔Танып белү мөнәсәбәтендә эмпиризм һәм рационализмны тәңгәл китерү, өстенлекне беренчесенә биреп;
- ✔Гади халыкка кешелекле мөнәсәбәт һәм аның хокукларын ихтирам итү өчен чыгыш ясый, тик дәүләт идеалы итеп мәгърифәтле хаким җитәкчелегендәге абсолют монархияне исәпли, (ягъни «мәгърифәтле абсолютизм" идеясен тәкъдим итә"**),** шулай ук берничә **«мәгърифәтле**» монархлар белән язышкан ( алар арасында Екатерина II дә була) һәм дәүләт төзелеше буенча гамәли киңәшләр бирә.

# 3. Монтескье фәлсәфәсе. «Җәмәгатьчелек килешүе», власть бүленеше

**Шарль Луи Монтескье** (1689 - 1755) - француз фәлсәфәчесе, язучы, юрист, галим (күп кенә өлкәләр буенча)

**Фәлсәфи карашлар**

- ✓ деизм позициясеннән чыгыш ясый — Аллада булдыручы күрә, тик ул аның кеше эшләренә һәм табигать процессларына кысылуын инкарь итә;
- ✓Аллада тәртип саклау һәм әхлак тәрбияләү чарасын күрә;
- ✓ җанның үлемсезлеге идеясен кире кага, властька һәм җәмгыятьтәге йогынтыга дәгъва итүләре, дингә ышанучыларны ялгышлыкка керткәннәре (күп кенә мәсьәләләр буенча) һәм кеше инициативаларын баскан өчен христианлык һәм католик Чиркәүне тәнкыйтьли;
- ✓Тарих кешеләр тарафыннан салына, ә Илаһи билгеләнеш көче белән түгел дип исәпләгән;
- ✓Җәмгыять төзелешендә климат һәм географиянең йогынтысын күрә (көньяк илләрендәге кызу климат гадәттә, деспотизмга тартыла, төньяклар суык климатлы — демократиягә, урта климатлы урта европада деспотизмнан демократиягә һәм киресенчә даими күчәләр;
- ✓ дәүләт барлыкка килгәнче «табигый хәл» булган дип исәпли, монда кешеләр бер - берсе белән хисаплашмыйча үзләренең инстиктларын күрсәтә алалар һәм ихтыяҗларын канәгатьләндерәләр, әмма мондый яшәү мөмкин булмый башлагач, кешеләр «җәмәгатьчелек килешүе» нигезендә дәүләт төзи, ул бер берсенең хокук һәм җаваплылыкларын тануны карый һәм халык алдындагы власть барлыкка килә;
- ✓ **"власть бүленеше"** идеясен тәкъдим итү— ягъни дәүләт властенең нәтиҗәлерәк эшләве һәм деспотизмны юкка чыгару өчен, влатьны закон чыгару, башкару һәм судка бүлү
- ✓Закон өстенлеге өчен чыгыш ясый

**Монтескье идеяләре, аларга нигезләнеп хәзерге заман демократик дәүләтләр төзелә**

- ✔ Закон өстенлеге идеясе
- ✔ властның закон чыгару, башкарма һәм судка бүленеше идеясе

## 4. Руссоның революцион-демократик фәлсәфәсе. Җәберләнгән күпчелекнең баш күтәрүгә хокукы.

**Жан Жак Руссо** (1712 — 1778) төп игътибарны социаль-сәяси фәлсәфәгә булә, революцион демократия позициясеннән чыгыш ясый

***Руссо фәлсәфәсенең төп положенияләре***

- ✔Аллада дөнья ихтыяры һәм дөнья акылы
- ✔Материяне ясап булмый һәм һәрвакыт обүектив бар дип исәпли;
- ✔Кеше үлә торган тән һәм үлемсез җаннан тора дип саный;
- ✔Кеше дөньяны танып белү көчендә түгел (аерым алганда, әйбер һәм күренеш асыллары);
- ✔Тулаем алганда дингә, христианлыкка каршы чыга, әмма динне бетерү аркасында әхлак һәм мораль чикләүләр түбәнәюеннән курку өчен дингә алмашка – «гражданнар динен» төзергә тәкъдим итә, «бөек җан культы (Алла)", «дөнья ихтыяры культы" һ.б.лар;
- ✔эмпиристик (тәҗрибәле) танып белү яклы була;
- ✔ җәмгыятьтәге каршылыкларның төп сәбәбе ул хосусый милек;
- ✔Халыкның баш күтәрүгә булган хокукын нигезли (җәберләү, хокук һәм милектән мәхрүм ителгән күпчелек паразитар азчылыкны һәм хакимне тәхеттән төшерү хокукына ия һәм үз күзаллаулары буенча җәмгыять төзи ала);
- ✔Гадел, идеаль җәмгыятьтә барысы да тигез хокукка ия булырга тиеш, ә хосусый милек барлык гражданнар арасында яшәү өчен кирәк булган күләмдә (ләкин баер өчен түгел) тигез бүленергә тиеш;
- ✔власть парламент аша түгел, ә гражданнар белән — турыдан-туыр җыелыш, җыеннар аша тормышка ашырылырга тиеш
- ✔Киләчәктә дәүләттә бала тәрбияләүнең принципиаль яңа системасы кулланырга тиеш: балалар әйләнә-тирә дөньядан махсус уку йортларында аерып урнаштырылырга тиеш, анда аларны яңа җәмгыять кешеләре - шәхси ирекле, үзараихтирам идеяләрендә, дингә һәм деспотизмга карата түзә алдмаслык итеп, һөнәргә ия һәм әйдәүче фәннәрне аңлаучы итеп тәрбияләячәкләр.

## *5. Кондильяк сенсуализмы (танып белүдәге хисси тәҗрибәнең өстенлеген нигезләү)*

**Этьенн Кондильяк** (1715 - 1780) җәмгыятьтәге мәсьәләләргә азрак игътибар итә һәм төп көчен танып белү мәсьәләләрен (гносеологияне) тикшерүгә юнәлтә

**Кондильякның төп фәлсәфи идеяләре**

- ✔ **дөньяны танып була;**
- ✔ **кеше тышкы дөньяны шулкадәр танып белә алачак, күпмегә аңа үзенең мөмкинлекләре (акылы, сиземләү органнары) моны эшләргә мөмкинлек бирәчәк.;**
- ✔ **әйләнә-тирә дөнья барлык белемнең чыганагы булып тора.**
- ✔ **танып белү нигезендә хисси үзләштерү ята (сиземләү органнарының әйләнә-тирә чынбарлыкны кеше акылында чагылдыруы);**
- ✔ **хисси үзләштерү катнашлыгыннан тыш мөстәкыйль рәвештә танып белү юк**

33нче сорау. XVIII гасыр француз Мәгърифәтчелеге фәлсәфәсенең атеистик-материалистик юнәлеше.

*1.Атеизм һәм материализмның гомуми төшенчәләре. Атеистик-материалистик фәлсәфә*

Атеистик-материалистик фәлсәфә XVIII насыр Франциядә Бөек француз революциясенә кадәр һәм аның вакытында таралу ала

**Атеизм** — фәлсәфә юнәлеше, аның вәкилләре тулысынча Алла барлыгын, динене инкарь итә.

**Материализм** — фәлсәфәдәге юнәлеш, әйләнә-тирә дөньяның мөстәкыйль идеаль (рухи) башлангыч белән тууын һәм бар булуын кабул итми һәм әйләнә-тирә дөньяны, аның күренешләрен, кешене табигый фәннәр күзлегеннән аңлаталар.

Күренекле вәкилләре

- ✔ Мелье
- ✔ Ламетри
- ✔ Дидро
- ✔ Гельвеций
- ✔ Гольбах

***Атеистик-материалистик юнәлеш француз фәлсәфәчеләре эшчәнлегенең фәлсәфә һәм гомумән җәмгыять өчен әһәмияте түбәндәгедә:***

- Ике әйдәүче фәлсәфә юнәлеше булуын төгәл билгеләделәр — материализм и идеализм ("Демокрит линиясе» һәм "Платон линиясе ")
- Фәлсәфәне бик күп дини ышанулардан азат итә
- субстанөиягә төгәлрәк билгеләмә - материя бирелә
- Аң турында материя үзенчәлеге буларак үз-үзен чагылдыру идеясен тәкъдим итәләр (әлеге вакытта да таралыш алган);
- Тәҗрибәгә кадәргене, сиземнән тыш (“саф”) белемне тәнкыйтьлиләр;
- обосновали и распространили теорию материалистического сенсуализма (в основе познания лежат чувственные ощущения)
- выдвинули идею о том, что все единичные вещи являются различными комбинациями микрочастиц;
- обратили внимание на движение не как на сверхъестественное явление, а как на свойство материи;
- обосновали идеи социальной справедливости
- идеологически подготовили Великую французскую революцию

## 2. Мелье фәлсәфәсе

**Жан Мелье** (1664 — 1729) — һөнәре буенча рухани,яшәү барышында Алланы һәм динне инкарь итүгә килгән (атеизмга), фәлсәфәче-материалист

**Фәлсәфәнең төп положениеләре**

- ✔Гадәттән тыш бернәрсә дә мөмкин түгел ди (шул исәптән Алла да);
- ✔Материялардән аеры идеяләр булуына, җанның үлемсезлегенә ышанмый;
- ✔Бар әйләнә-тирә дөнья махсус субстанциядән – материядән тора дип исәплөгән;
- ✔ барлык әйберләрнең башлангычы материядә, ул мәңгелек, аны тудырып булмый, чынлап та бар, үзгәрә һәм үзенә салынган үзенчәлек- хәрәкәт аркасында даими үсешә;
- ✔ материя кечкенә кисәкчәләрдән тора, аларның комбинацияләре нәтиҗәсендә әйберләр барлыкка килә;
- ✔ танып белү — материянең үз материя чагылышы;
- ✔ күпчелек белемнең чыганагы булып хис-тойгылар тора;
- ✔социаль антагонизмнарның сәбәбе итеп кайсыбер кешеләрнең «яман ихтыярыннан» физик хезмәттән котылырга теләгәннән туган хосусый милекне күрә;
- ✔ абсолютизмны бәреп төшерү, яшәп килүче дәүләт һәм хосусый милекне юк итү өчен чыгыш ясый;
- ✔Җәмгыять сыйфатында киләчәктә тугандаш общиналар берлеген күрә, аның әгъзалары тигез, бергә яши, бергә җитештерү хезмәте белән шөгыльләнә, алган керемне бүлешәләр һәм шатланып яшиләр.

## *3. Ламетри фәлсәфәсе*

**Жюльен Ламетри (1709-1751)**

**Фәлсәфәнең төп положениеләре**

- **идеализм һәм теологияне тулысынча инкарь итә**
- **Әйләнә-тирә дөнҗяны бердәм субстанциянең– тудырып булмый торган, мәңгелек, чиксез материянең төрле чагылыш җыелмасы дип санаган**
- **җан, аң, тойгы, Ламетри буенча, табигый барлыкка килә, материянең үзенчәлеге була;**
- **Материя бәйсез булганнан, Алланың мәңгелек ихтыяҗ юк;**
- **Дөньяны тулысынча танып белү яклы чыгыш ясый, өстәвенә танып белүдә төп рольне тойгы органнарына калдыра;**
- ***утилитарист була – кеше яшәешенең мәгънәсе* – шәхси бәхет**
- **хосусый милекне кеше иркенең гаранты дип санаган.**
- **Дәүләт идеалы итеп «мәгърифәтле абсолютизм»ны саный**

## *4.Философия Дидро*

**Дени Дидро** (1713 — 1784) – иң күренекле француз матриалист-фәлсәфәчесе. Дидро Мәгърифәтчелеккә зур өлеш кертә, «Фән, сәнгать һәм һөнәрләр энциклопедиясе»н төзүне тәкъдим итә. "Энциклопедия«дини хорафаттан азат һәм әйдәүче фән, сәнгать һәм җитештерү өлкәсендәге белем нигезләре була, буржуаз караш нигезләрен сала башлый. Аны төзүдә чорның әйдәүче фәлсәфәчеләре — Дидро замандашлары: Вольтер, Монтескье, Кондильяк, Гольбах һәм башкалар катнаша. "Энциклопедияне" төзүгә 20 елдан артык вакыт үтә.

**Фәлсәфи карашлар**

- ✔Материяне бердәнбер субстанция итеп таный, аның чагылышы итеп бар бердәнбер әйберләрне исәпли
- ✔Хәрәкәтне материянең төрлелеге белән аңлата (материянең төрле сансыз күләмдәге өлешләре хәрәкәткә китерә);
- ✔Гапләмнең рухи башлангычын кире кага, аңны материя үзенчәлеге дип исәпли
- ✔Җәмгыять һәм дәүләт нигезендә «җәмгыять килешүе»ен күрә, моңардан чыгып, властьның һәм феодалларның илаһилыгын кире кага
- ✔ дәүләт идеалы итеп «мәгърифәтле монархия«не исәпли, ә икътисад — акыл белән бүленгән, күпчелек ихтыяҗы булган хосусый милек

## 34 сорау. Француз фәлсәфәсенең социалистик-утопик (коммунистик) юнәлеше

*1.Утопик-социалистик фәлсәфә һәм аның XVIII—XIX гасыр башы Франциядәге әйдәүче вәкилләре*

**Социалистик-утопик (коммунистик) юнәлеш** XVIII гасырның икенче яртысында —XIX гасыр башында Франция фәлсәфәсендә киң таралыш ала. Бу юнәлеш вәкилләре яшәп килгән иҗтимагый-икътисадый һәм сәяси стройны катгый рәвештә тәнкыйтьли, иҗтимагый милеккә нигезләнгән яңа җәмгыять һәм дәүләт төзү проектларын тәкъдим итә, биредә социал-утопистлар тарафыннан гомум тигезлек буларак аңланылган гаделлек идеясе тантана итә. Социалистик-утопик (коммуни-стик) идеяләр Франциянең 1789 - 1794 елгы Бөек француз сугышына чаклы һәм аның вакытында гади халык катламнары арасында хуплау таба.

Күренекле вәкилләр

1.Мабли
2.Бабеф
3.Сен-Симон
4.Фурье

## 2. Мабли фәлсәфәсе (борынгы(кыргый) коммунизмның өстенлекләре)

**Габриэль Мабли** (1709 — 1785) - фәлсәфәче, тарихчы, язучы (Кондильякның туганы), Франция фәлсәфәсенең социалистик-утопик юнәлешнкә нигез салучыларның берсе

Фәлсәфәсенең төп положениеләре

- Мәгърифәтчелек фәлсәфәсен тулысынча каты тәнкыйтьли (үз чорын «буш сүзләр һәм парадокслар» вакыты дип билгели);
- материализмны да, деизмны да кире кага;
- атеистлар, материалистлар, деистлар (ә алар исәбенә шактый күп фәлсәфәчеләр кергән — Маблиның замандашлары һәм ватандашлары) әйләнә-тирә дөньяны һәм кешене өйрәнүгә бик схематик, механик рәвештә карыйлар, халыкның җанын үтерәләр, әдәпкә бернинди игътибар итмиләр дип исәпли;
- фәлсәфәнең төп билгеләнеше дип әдәп һәм әхлакны таратуны билгели; бу максатка ук көчле, дәүләт ярдәмен тойган, киң таралашы алаган дин дә буйсындырылырга тиеш;
- Декарт дуализ идеясе яклы була, аңа ярашлы кеше матди (тән) һәм рухм башлангычны берләштерә, — моннан, Мабли буенча, кешеләрнең тәртибе һәм гамәлләренә зур йогынты була, көчле теләк, үз-үзенә мәхәббәт, күңелсезлекләрне урап узарга омтылу, рәхәт алуга тартылу;
- кеше табигате үзе аны башка кешеләр белән – җәмгыять белән яшәргә этәрә дип санаган;
- борынгы община строенда, кайда барысы да гомум булган, ә кеше эшчәнлеге үзен һәм ырудашларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән булган (ә баю өчен түгел, «кешелекнең алтын чоры» дип исәпләгән;
- борынгы коммунизмның, « кешелекнең алтын чоры» үлүенең сәбәбе, һәм җәмгыятьтәге башка күңелсезлекләрнең сәбәбе хосусый милек барлыкка килү һәм кешеләрнең сыйныфларга бүленешендә дә дип санаган;
- җәмгыять идеалы итеп борынгы община кммунизмында күрә, сыйныфларга бүленеше булмаган, властьның халыктан аерылмаган, тигезлек, гаделлек, кешеләр туганлыгы тантана иткән, хосусый милексез җәмгыятькә кайтырга чакыра,;
- шул ук вакытта үзенең идеаллары тормышка ашырып булмый дип саный, хосусый милек мәңгелек һәм бетереп булмый, сыйныфларга бүленеш һәрвакыт булачак, ә халык көрәшкә күтәрелә алмаячак, күтәрелсә дә, кеше табигатенә бәйле, көчле дәрт, җиңел табыш һ.б.коммунизм кысаларында гына кала алмаячак.

## *3. Бабеф фәлсәфәсе (хәрби күтәрелеш аша, сәяси һәм икътисадый тигезлеккә нигезләнгән коммунистик җәмгыять казанышлары,)*

**Франсуа Бабеф** (псевдонимы(тәхүллүсе) -**Гракх Бабеф)** (1760 - 1797) беренче коммунист-теоретик һәм практигы дип исәпләнелә.

↓

Основные положения философии

↓

•барлык фәлсәфи теорияләрне кире кага, аның фикеренчә, яртылаш характер йөртә һәм халыкка бәхет китерү максатына буйсындырылмаганнар;

• яшәп килүче җәмгыять һәм дәүләтне каты тәнкыйтьли;

• төп социаль явызлык дип хосусый милек барлыкка килүен һәм җәмгыятьнең капма-каршы сыйныфларга байлар һәм ярлыларга бүленүендә күрә;

•сыйныфка бүленеш булмаган, хосусый митлексез, җир кем анда эшли, икътисадый һәм сәяси тигезлеге булган, бердәм хезмәт һәм җитештерелгәннәрне дәүләтнең барлык җәмгыять кешеләре арасында тигез бүленгәнлек булган җәмгыять төзеп була дип санаган;

•коммунистик җәмгыять төзүне бары тик ярлыларның байларга каршы революөия ясау юлы белән генә ирешеп була дип санаган. Бабеф беренче фәлсәфәче-коммунист була, ул үз идеяләрен гамәлдә кулланып карый. Аның тарафыннан кораллы баш күтәрүгә әзерлек алып барыла, манифестлар төзелә һәм булачак революцион хөкүмәтнең программасы уйланыла. Бу оешма «Тигезлек хакына заговор» дигән атама ала. 1797 елда заговор ачыла, ә Бабеф һәм аның башка көрәштәшләре җәзалап үтерелә.

# 4. Икътисадый детерминизм һәм Сен-Симонның “җитештерү җәмгыяте” фәлсәфәсе

**Клод Сен-Симон** (1760 - 1825) Франциияд әге утопик социализм традициясен дәвам итә

Фәлсәфәнең төп положениеләре

• дөньяны диалектик тануга якын килә (капма-каршылыкның берлеге һәм көрәше);

• социаль физиология теориясен чыгара, биредә җәмгыятьне тулы бер бөтен организм итеп карый;

•җәмгыять нигезләнүче өлкә итеп икътисадны карый (икътисад, җитештерү мөунәсәбәтләре барысын да билгели — сәясәтне, социаль мөнәсәбәтләрне, дөньяга караш) — икътисадый **детерминизм**;

• җәмгыятьтә икътисад һәм җитештерү мөнәсәбәтләре үсешкән саен җәмгыять түбән формадан югарыга, бер баскычтан икенчесенә күчә дигән идея чыгара, (бу киләчәктәге К.Марксның иҗтимагый-икътисадый формацияләр теориясе яралгылары була);

• фәлсәфә максаты дип яхшы, акыллы җәмгыятьт төзү дип күрә;

• Сен-Симон буенча иң яхшы җәмгыять ул шул, кайсы үз әгъзаларына мөмкин кадәр күбрәк ихтыяҗларын канәгатьләндерә алган җәмгыять;

• Сен-Симон иң яхшысы сыйфатында «**җитештерү җәмгыятен**« **күрә, ул иерархия принцибы буенча төзелеп, социаль баскыч кешенең сәләтләреннән чыгып билгеләнә** («сәләтләр иерархиясе"), нәсел буенча мираска калдыру тыелачак (барысының да мөмкинлекләрен тигезләү өчен, эшсезлек һәм бәйрәм ясауларны туктату, һәрберсенә яңабаштан башлау мөмкинлеге бирү һәм җәмгыятьтә сәләте мөмкинлек биргән дәрәҗәгә ирешү), барысына да мотлак эшләү бурычы куела, ә икътисадка план буенча үсешергә (артык җитештерү яки дефи-цитны булдырмау һәм барлык җәмгыять әгъзаларының ихтыяҗларын канәгатьләндерү);

• бу җәмгыять белән индустриаль сыйныфы вәкилләре җитәкчелек итәчәк (ягъни буржуазия), тик хосусый милек иясе сыйфатында түгел, ә халык хуҗалыгы организмының төрле буыны белән идарә итүче буларак.

Шулай ук Сен-Симон исәпләгән:

• пролетариат һәм буржуазия бер сыйныфка — индустри-альгә килеп берләшәчәк;

• киләчәккә оптимистик караган — кешелек идеаль җәмгыять төзүгә дучар ителгән;

• яңа җәмгыять революцион юл белән түгел, ә эволюцион юл белән — даими үсешкән икътисад җәмгыятьнең сыйнфый-антогонистиктан ассоциативка әйләнүенә китерә;

• яшәп килгән динне яңа дин белән алыштыру турындагы теория тәкъдим итә, аның мәгънәсен шушы лозунг ача: «**Кеше кешегә - туган**".

**5. Франсуа Фурье** (1772 - 1837) шулай ук күренекле социалист-утопистларга керә. Аның фәлсәфәсенең түбәндәге төп п***оложениләрен бүлеп чыгарып була:***

• буржуаз мораль ялган;

• атеизм хәвефле, чөнки кешене киләчәккә булган өметтән аера;

• кеше, тарих, җәмгыять табигать законнары буенча үсә;

• буржуаз җәмгыять өч төп каршылыкка ия — шәхси ихтыяҗлар арасында(магнатлар, буржуа) һәм иҗтимагый (калган халык), социаль-икътисадый (балансланмаган, артыклык яки җитештерү кризисы бирүче), мораль (буржуаз никах һ.б.);

• идеаль җәмгыять — "**гармония җәмгыяте**", ул гомум хезмәт бурычына, бүленеш кагыйдәләренә, икътисадның югары дәрәҗәсенә, мәхәббәт һәм әхлак иркенә, Аллага ихтирамга нигезләнә.

## 5. Фурье фәлсәфәсе («Гармония җәмгыяте»)

Франсуа Фурье (1772 - 1837)

Фәлсәфәсенең төп положениеләре

- буржуаз әхлак ялган;
- атеизм хәвефлен, чөнки ул кешене киләчәккә өметтән мәхрүм итә;
- кеше, тарих, җәмгыять табигатҗ законнары буенча үсә;
- буржуаз җәмгыять өч төп каршылыкка ия – шәхси ихтыяҗлар арасында (магнатлар, буржуа) һәм иҗтимагый (башка халык), социаль-икътисадый ( балансланмаган, я артык яки җитештерү кризисына китерүчек), әхлакый (буржуаз никах һ.б.)
- идеаль җәмгыять – «гармония җәмгыяте», ул гомуми хезмәт бурычына нигезләнәчәк, дөрес бүлгәләнгән, икүтисадның югары дәрәҗәсе, мәхәббәт һәм әхлак ирке, Аллага ихтирам.

35 сорау. Дөнья фәлсәфәсе буларак, XIX гасыр немец фәлсәфәсе, аның төп юнәлешләре һәм идеяләре

## *1. XIX гасыр немец фәлсәфәсенең төп юнәлешләре һәм аның мәгънәсе*

XIX гасыр немец фәлсәфәсе

Немец фәлсәфәсенең төп юнәлешләре

- немец классик фәлсәфәсе(XIX гасырның беренче яртысы);
- материализм (XIX гасыр уртасы һәм икенче яртысы);
- иррационализм (XIX гасырның икенче яртысы һәм ахыры), «тормыш фәлсәфәсе".

Мәгънәсе

- кешелекне гасырлар буенаборчыган проблемаларны тирәнтен тикшерү, һәм фәлсәфәнең киләчәген билгеләүче нәтиҗәләргә килү;
- совместить в себе почти все известные в тот период фило-софские направления — от субъективного идеализма до вуль-гарного материализма и иррационализма;
- открыть десятки имен выдающихся философов, которые вошли в "золотой фонд" мировой философии (Кант, Фихте, Гегель, Маркс, Энгельс, Шопенгауэр, Ницше и др.).

## 2. Немец классик фәлсәфәсе

**Немец классик фәлсәфә** XVIII гасыр ахырында –XIX гасырның беренче яртысында таралу ала

Объектив идеализм

Төп вәкилләре

### Иммануил Кант (1724 - 1804)

Төп идеяләр

- Ньютон законына нигезләнеп,табигый көчләр тәэсирендә Кояш системасы барлыкка килүе турында аңлатма бирә— пространстводагы бушандырылган материя кисәкчәләренең әйләнеп торган томанлыгыннан;
- кешенең танып белү сәләтенең чиге булуы һәм әйберләрнең һәм күренешләрнең эчке асылын танып булмау турындагы теорияне тәкъдим итә («эчендәге әйберләрне»);
- **категорияләр турында тәгълимат** чыгара— фәлсәфә эш иткән төп, гомум төшенчәләр
- мораль законны формуласын чыгара («катгый император");
- киләчәктәге «мәңгелек дөнья» турындагы идеяне тәкъдим итә, ул сугышларның икътисадый яктан уңышсызлыгына һәм аның хокукый тыелуына нигезләнә.

### Георг Гегель (1770 – 1831)

Төп идеяләр

- яшәеш һәм фикерләүне тиңләштерә,
- аңга бәйсез һәм бар нәрсәгә, материаль дөньяга башлангыч булган абсолют идея турында тәгълимат барлыкка китерә,
- Көнбатыш илләрендә танылу алган **объектив идеализм концепциясен** нигезли.

### Фридрих Шеллинг (1775 - 1854)

Төп идеяләр

Табигатьне объектив идеализм күзлегеннән тирәнтен нигезли, идея тәкъдим итә, аңа ярашлы, иреклек һәм хокукый строй баштан ук табигатькә салынган.

субъектив идеализм (Фихте)

**Иоганн Фихте** (1762 – .1814), **субъектив идеализм концепциясен** эшкәртүгә зур өлеш кертә, аңа ярашлы кеше өчен бердәнбер һәм төп чынбарлык ул үзе, аның аңы ( «Мин-концепция« дип аталган)

материализм (Фейербах)

**Людвиг Фейербах** (1804 – 1872) немец классик фәлсәфәсендә материалистик юнәлеш вәкиле була. Фейербах идеализмны тәнкыйтьләп чыгып дөньяның тулы һәм эзмә-эзлекле материалистик картинасын тәкъдим итә. Үз фәлсәфәсендә Фейербах тулы атеист буларак чыгыш ясый, Алла юклыгын дәлилли, аның ясалмалылыгы, кешеләр тарафыннан уйлап чыгарылганлыгы, Аллага кешенең тормышка ашыра алмаган идеалларын күчерүе турында әйтә.

Немец классик фәлсәфәсенең әһәмияте

- фәлсәфә игүтибарын традиөион мәсьәләләрдән (яшәеш, фикерләү, танып белү һ.б.) кеше асылын тикшеренүгә борып җибәрә;
- аерым игътибарны үсеш мәсьәләсенә бүлә;
- фәлсәфәнең логик-теоретик аппаратын күпкә баетты;
- тарихка тулы процесс буларак карый.

## *3. XIX гасыр немец материализмының төп юнәлешләре*

Людвиг Фейербах фәлсәфәсе (1804 — 1872). Людвиг Фейербахның атеистик һәм материалистик фәлсәфәсе немец фәлсәфәсенә дә, материализмга да кертелә. Бу гадел дә, чөнки Фейербах фәлсәфәсе немец классик фәлсәфәсен тәмамлады һәм немец материализмына нигез салды, алар арасындагы бүленеш булды

Марксизм

- Марксизм фәлсәфәсе
- Политэкономия (икътисадый тәгълимат)
- Фәнни коммунизм (социаль-сәяси теория)

**Марксизм төзүчеләр**

- Карл Маркс (1818-1883)
- Фридрих Энгельс (1820-1895)

# Төп идеяләр

- Дөньяның эзмә-эзлекле материалистик картинасын тәкъдим итә;
- Материаль һәм иҗтимагый яшәеш өчен икътисадның ролен күрсәтә;
- Фәлсәфи мәсьәләләрне диалетика күзлегеннән аңлата;
- Тарихны максатчан һзм закончалыклы процесс буларак карый;
- Кеше, җәмгыять, дәүләт барлыкка килү турында тулы картинаны бирә;
- Атеистик позициядән (караштан) чыгыш ясый.

Вульгар материализм

# Төп вәкилләр

Фохт

Бюхнер

Молешотт

# Фәлсәфә үзенчәлекләре

Вульгар материалистлар кеше мәсьәләсенә табигый фәннәр позициясеннән карыйлар;

Табигать законнарын механик рәвештә кеше җәмгыятенә күчерәләр; идеальлекне кире кагалар;

Аж эшчщнлеген физиологик процесс буларак карый.

## 4. Иррационализм, «тормыш фәлсәфәсе»

**Иррационализм** –яшәешнең һәм тарихның объектив законнарын, диалектиканы кире кагучы, әйләнә-тирә дөньяны һәм тарихны хаос буларак кабул итүче фәлсәфә юнәлеше. **Артур Шопенгауэр –** нигез салучы.

↕

Иррационализмга якын **«тормыш фәлсәфәсе»**, ул читкә юнәлгән төшенчә-яшәеш, идея, чимал һәм башкаларны түгел, ә кешенең дөньядагы яшәешен, кеше өчен чынбарлык булган бердәнбер яшәешне игътибар үзәгенә куя. Аңа нигез салучыларның берсе - **Фридрих Ницше**

Нигезенә салына →

Фәлсәфәнең заманча юнәлешләре – *прагматизм һәм экзистенциализм*

# 36нчы сорау. Иммануил Кант фәлсәфәсе

## *1. Кант фәлсәфәсенең чорларга бүленеше.*

Кант фәлсәфәсенең чорларга бүленеше (1724-1804) - немец ( прусс) фәлсәфәчесе, Кенигсберг университеты профессоры, немец классик идеализмына нигез салучы.

Тәнкыйди чорга чаклы
Мөһим мәсьәләләр: яшәеш, табигать, табигать белеме мәсьәләләре. Әлеге мәсьәләләрне тикшергәндә Кант новаторлыгы - ул үсеш мәсьәләсенә игътибар итүче беренче фәлсәфәчеләрнең берсе булды.

Шул чор дөньяга караш эзен йөрткән идеяләр:
-Механик законнар баштан ук материягә салынмаган, ә үзенең тышкы сәбәбе бар
-Әлеге тышкы сәбәп – ул Алла.

Тәнкыйди чор вакытында килеп чыккан фундаменталь фәлсәфи әсәрләр, аларга бәйле үз исемен ала:
-«Саф акыл тәнкыйде»
- «Гамәли акыл тәнкыйде»
-«Фикерләү сәләте тәнкыйде»

**Кантның фәлсәфи нәтиҗәләре,аның чоры өчен революцион булган:**

- **Кояш системасы бушандырылган материя кисәкчәләреннән торган зур болыттан аның әйләнүе барышында барлыкка килгән, бу хәрәкәт итү һәм үзара йогынты ясау нәтиҗәсендә мөмкин булган;**
- **Табигатьнең вакыт эчендә үз тарихы бар,ул мәңгелек һәм үзгәрми торган түгел;**
- **Табигать даими үзгәрештә һәм үсештә;**
- **Хәрәкәт һәм тынычлык чагыштырмача;**
- **Җирдәге һәр тереклек , шул исәптән кеше дә, табигый биологик эволюция нштиҗәсе.**

## 2. «Саф акыл тәнкыйде»

Әсәрнең төп идеясе –агностицизм – әйләнә-тирә чынбарлыкны танып булмау. Кантка кадәр күпчелек фәлсәфәчеләр танып белүдә туган кыенлыкларның төп сәбәбе сыйфатында танып белү объектын күргәннәр – меңәр еллар ачылмаган серләре булган яшәеш, әйләнә-тирә дөнья. Кант исә кыенлыклар сәбәбе әйләнә-тирә чынбарлык - объект түгел, ә танып белү эшчәнлегенең субъеты – кеше, дөресрәк, аның аңы дигән гипотеза тәкъдим итә. Кеше акылының танып белү мөмкинлекләре (сәләтләре) чикле (ягъни акыл барын да булдыра алмый). Кеше акылы үзенең танып белү чаралары хәзинәсе белән үз кысаларыннан (мөмкинлекләреннщн) чыгарга тырышса, ул хәл иткесез каршылыкларга (антиномияләргщ) очрый. Акыл ярдәмендә ике капма-каршы антиномияне –логик дәлилләргә мөмкин – әмма акыл аптыраашта кала. Кант буенча, антиномияләр булуы – акылның танып белү сәләтләренең чикләре булуының дәлиле.

| Антиномнар | |
|---|---|
| Пространствоның чиклелеге | Дөнья вакыт башлангычына ия һәм пространствода чикләнгән |
| | Дөньяның вакыт башлангычы юк һәм ул чиксез |
| Гади һәм катлаулы | Дөньяда бернинди гади нәрсә юк |
| | Тик гади элементлардан торган гына түгел, гадидән торганнар да бар |
| Азатлык һәм сәбәплелек | Табигать законнары буенча сәбәплелек кенә түгел, азатлык та бар |
| | Азатлык юк |
| Алла барлыгы | Алла бар- һичшиксез нинди дә булса асыл кирәк, бар булганның сәбәбе |
| | Алла юк. Бернинди дә абстракт асыл юк – бар булганның сәбәбе юк. |

## Танып белү эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак белем классификациясе

- ✔ Апостерио белем – кеше тәҗрибә нәтиҗәсендә алган белем. Бу белем бары тик чамаланган гына була, әмма дөрес түгел, чөнки бу төр белемнән алынган һәр фикер тәҗрибәдә сынап карарга кирәк, һәм мондый белем һәрвакыт хак диган сүз юк. Мәсәлән, кеше тәҗрибә буенча металларның эрегәнен белә, тик теоретик рәвештә эрүгә дучар булмаган металлар булуы да ихтимал, димәк, тәҗрибәле (эмпиристик, апостериор) белем дә дөрес булмыйча гомумилеккә дәгъва итә алмый.
- ✔ Априор белем – тәҗрибәгә кадәр, ягъни акылда башта ук яши һәм бернинди дә тәҗрибәви дәлилләүне таләп итми. Мәсәлән, «Барлык җисем озайлы», «Кеше гомере вакыт берәмлегендә ага», «Барлык җисемнәрнең массасы бар». Бу полоҗениеләрнең һәрберсе тәҗрибәви тикшерү белән дә, ансыз да абсолют дөрес. Мәсәлән, үлчәме булмаган җисем очрату мөмкин түгел. Нибары априор (тәҗрибәгә кадәрле) белем абсолют дөрес һәм ышанычлы, гомум һәм кирәклелек сыйфатларына ия.
- ✔ «Үз эчендәге әйбер» – ул акыл белән беркайчан да танып булмаячак әйбернең эчке асылы.

**Танып белү процессының схемасы**

- ✔Тышкы дөнья иң элек кешенең тою органнарына йогынты ясый (аффицировкалау);
- ✔ кешенең тойгы органнары тышкы дөньяның аффицировкаланылган образларын тойгылар аша кабул итә;
- ✔ кеше аңы тойгы органнары тарафыннан алынган вакланган образларны, хис-тойгыларны системага китерә, нәтиҗәдә кеше акылында әйләнә-тирә дөньяның тулы картинасы барлыкка килә;
- ✔ акылда тойгылар нәтиҗәсендә барлдыкка килгән әйләнә-тирә дөньяның тулы картинасы, ул нибары акыл һәм тойгылар татыган тышкы дөнья образы гына, ул реаль дөнья белән бернинди уртаклыгы да юк;
- ✔ реаль дөнья, аның образларын акыл һәм тойгы кабул итә, «үз эчендәге әйбер» була – акыл белән гомумән аңлатып булмый торган субстанция;
- ✔ кеше акылы бары тик әйләнәдәге бик күп предмет һәм күренешләрне – “үз эчендәге әйберләрне” генә таный ала, тик аларның эчке халәтен түгел.

**Танып белү барышында акыл юлыккан үтеп булмастай чикләр**

- ✔Үзенеке (акыл өчен эчке булган) булган чикләр, аның артыннан хәл иткесез каршылыклар туа – антиномияләр;
- ✔ тышкы чикләр – үз эчендәге әйберләрнең эчке асылы.

Саф акыл структурасы, сигналлар кабул итүче – танылмаган «үз эчендәге әйберләр” образы– әйләнә-тирә дөнҗя

Сизеп белү формалары – пространство һәм вакыт. Сизеп белү аркасында аң хис-тойгыларны пространство һәм вакытка куеп башта системалаштыра.

Акыл формалары – категорияләр –гомум төшенчәләр, алар ярдәмендә пространство һәм вакытның «система координат»ына урнаштырылган беренчел хис-тойгыларны алга таба аңлау һәм системалаштыру. Кантка ярашлы, алар ярдәмендә акыл үз эшчәнлеген башкара: беренчел хис-тойгылар хаосын тәртипкә сала, моңа ярашлы фикерләү эшчәнлеге дә тәртипкә салыну мөмкинлеге барлыкка килә. Кант мондый унике категорияне бүлеп чыгара һәм һәрберсендә икешәр булган аларны дүрт сыйныфка бүлә, шул ук вакытта һәр сыйныфның беренче категорияләре – сыйныф характеристикасының капма-каршысы, өченчеләре – аларның кушылмасы(синтезы).

Акыл формасы – ахыргы югары идеяләр,мәсәлән: Алла идеясе; җан идеясе; дөнҗя асылы һәм башка идеяләр. Кант буенча фәлсәфә, югары идеяләр турындагы фән

Сан категорияләре:
-берлек
-күплек
-бөтенлек

Сыйфат категорияләре:
-чынбарлык
-инкарь итү
-чикләү

Мөнәсәбәтләр категорияләре:
-субстанциональлек һәм акциденция
-сәбәп һәм нәтиҗә
-үзара йогынты ясашу

Модальлек категорияләре:
-мөмкинлек һәм мөмкинлек булмау
-яшәү һәм яшәмәү
-кирәклек һәм очраклылык

## *3. Кантның «Гамәли акыл тәнкыйде»*

«Гамәли акыл тәнкыйде»
(«гамәли акыл» астында Кант әхлаклылыкны аңлый)

Төп мәсьәлә «Гамәли акыл тәнкыйдене»
-Әхлак нинди булырга тиеш?
-Кешенең нинди тәртибе әхлакый(әхлаклы) була ала?

Нәтиҗәләр:
-Саф әхлаклылык – барысы белән кабул ителгән иҗтимагый аң, аны аерым индивид үзенеке итеп кабул итә.
- Саф әхлаклылык  һәм реаль тормыш арасында (гамәл, ният, кеше ихтыяҗлары) көчле каршылык бар
-Әхлак, кеше тәртибе барлык тышкы шартлардан бәйсез булырга тиеш һәм әхлак законнарына гына буйсынырга тиеш

**Әхлакый закон**, ул югары һәм шартсыз характерлы, Кант аны катгый императив дип атый: «Синең гамәлеңнең максимумы гомуми закончалыкның принцибы була алырдай итеп эшлә»

**Катгый императивны заманча аңлату**
-Кеше гамәле башкаларга үрнәк булдырдай тәртипле булырга тиеш
-Кеше башка кешегә максат буларак кына карарга тиеш, ә чара буларак түгел

## 4. *«Фикер йөртү сәләте тәнкыйде»*

«Фикер йөртү сәләте тәнкыйде»
Төп идея – гомуми максатчанлык идеясе

- Эстетикадагы максатчанлык
- Табигатьтәге максатчанлык (табигатьтә бар нәрсәнең үз мәгънәсе бар)
- Руз максатчанлыгы (Алла барлыгы)

## 5. *И. Кантның социаль-сәяси карашлары*

**И. Кантның социаль-сәяси карашлары**

- Фәлсәфәче кеше баштан ук явыз табигатьле була дип исәпләгән
- Кешене әхлакый тәрбия һәм әхлак законнарына катгый буйсыну коткарачак ди уйлаган
- Демократия һәм хокукый тәртипне тарату тарафдары булган
- Сугышларны иң зур хата дип гаепләгән һәм кешелекнең җинаяте дип санаган
- Киләчәктә һичшиксез «югары тынычлык» урнашыр - сугышлар я хокук белән тыелачак, яки икътисадый файдасыз булачак дип дип исәпләгән

## *6. Кант фәлсәфәсенең тарихи әһәмияте*

Кант фәлсәфәсенең тарихи әһәмияте

- ✔ Кояш системасының барлыкка килүенә фәнни нигезле аңлатма бирә
- ✔ Кеше акылының танып белү сәләтенең чикле булуы идеясен тәкъдим итә
- ✔ 12 категория чыгара – фикерләү каркасы торган төшенчәләр
- ✔ Катгый императив – әхлакый закон формулировкасын чыгарган
- ✔ Демократия һәм аерым җәмгыять өчен дә, шулай ук халыкара мөнәсәбәтләр өчен дә хокукый тәртип идеясен тәкъдим итә
- ✔ Сугышны тәнкыйть итә, киләчәктә икътисадый файдасызлыкка һәм аларны хокукый тыюга нигезләнгән «мәңгелек тынычлык»ны күрәзәли

# 37нче сорау. Гегель фәлсәфәсе

## *1. Гегель иҗатына гомуми характеристика*

**1.Георг Вильгельм Фридрих Гегель** (1770 — 1831) — Гейдельберг, ә аннары  Берлин университетлары профессоры, Германиядә дә, Европада да заманының иң абруйлы фәлсәфәчеләренең берсе булган, немец классик идеализмының чагу вәкиле.

Гегельнең фәлсәфәгә керткән өлеше

• объектив идеализм теориясе (аның үзәк төшенчәсе абсолют идея  — Дөнья рухы);

• диалектика гомуми фәлсәфә методы буларак.

***Гегельнең** мөһим хезмәтләренә керә*:

• "Рух феноменологиясе";

• "Мантыйк фәне";

• "Хокук фәлсәфәсе".

Гегельнең социаль-сәяси карашлары:

• дәүләт — Алланың дөньядагы яшәү формасы (үз көче һәм “мөмкинлекләре” буенча алла гәүдәләнеше);

• хокук – булган яшәеш азатлыгының гәүдәләнеше;

• гомуми ихтыяҗлар шәхсигә караганда югарырак, һәм аерым кеше, аның ихтыяҗлары гомуми иминлек өчен корбанга бирелергә мөмкин;

• байлык һәм фәкыйрьлек  табигый һәм котылгысыз, бу югарыдан бюирелгән чынбарлык, аның белән килешергә туры килә;

• җәмгыятьтәге каршылыклар, конфликтлар – ул явызлык, ә игелекләр прогресс этәргече;

• дәүләтләр арасындагы каршылык һәм конфликтлар, сугышлар — гомумдөнья-тарих масштабында прогресс этәргече;

•"мәңгелек дөнья" черү һәм әхлакый таркалуга китерә; даими сугышлар, киресенчә, милләт рухын тазарта.

•Один из важнейших философских выводов Гегеля о бытии и

Яшәеш(материя) һәм идея (аң, акыл) арасында каршылыклар юк. Акыл, аң, идея яшәешкә ия, ә яшәеш  аңга. Барлык акылга ия чынбарлыкта бар, ә бар чынбарлык акылга ия.

## 2. Гегель онтологиясе

**Гегель онтологиясе (яшәеш турында тәгълимат) ( төп идея – яшәеш һәм фикерләүне тиңләштерү)**

**Абсолют идея**

• бердәнбер булучы чын чынбарлык

• әйләнә-тирә дөнья, аның предметлары һәм күренешләренең беренчел сәбәбе;

• аңлы һәм иҗат итә алаган Дөнья рухы.

**Абсолют рухның читләшу төрләре**

• әйләнә-тирә дөнья;

• табигать;

• кеше;

• кеше фикерлүве һәм эшчәнлеге аша читләшүдән соң, тарих барышы кабат үз-үзенә кире кайта: ягъни Абсолют рухның схема буенча: Дөнья (Абсолют) рух — читләшү — әйләнә-тирә мохит һәм кеше — фи керләү һәм кеше эшчәнлеге — үз-үзеңне фикерләү һәм кеше эшчәнлеге аша рухны тормышка ашыра —Абсолют рухның үз-үзенә кайтуы

**Читләшу**

• материянең һавадан иҗат итүе;

• объект (әйләнә-тирә дөнья) һәм субъект (кеше) арасында катлаулы мөнәсәбәтләр— кеше эшчщнлеге аша Дөнья рухы үзен предметлаштыра;

• кешенең әйләнә-тирә дөньяны хаталы кабул итүе, дөрес аңламавы

**Гегель онтологиясендә кеше**

• Ул — **абсолют идея иясе.**

• Һәр кеше аңы — Дөнья рухы кисәге.

• Нәкъ кешедә абстракт һәм йөзсез дөнья рухы ихтыяр, шәхес, характер, үзенчәлелек ала.

**Кеше ярдәмендә Дөнья рухын күрсәтү**

• үзен сүз, сөйләм, тел, жест формасында күрсәтә;

• максатчан һәм закончалы хәрәкәт итә — кешенең гамәлләре, хәрәкәктләре, тарих барышы;

• үзен кешенең танып белү эшчәнлеге аша таный;

• иҗат итә — кеше белән тудырылган материаль һәм рухи мәдәният нәтиҗәсе формасында.

# 3. Гегель диалектикасы

**Диалектика,** Гегель буенча, — Дөнья рухы һәм ул иҗат иткән әйләнә-тирә дөньяның яшәеш һәм төп үсеш законы

**Диалектика** мәгънәсе

• барысы да – Дөнья рухы, "ахыргы рух" — кеше, әйләнә-тирә предметлар һәм күренешләр, процесслар – үзендә капма- каршы башлангычлары бар (мәсәлән, көн һәм төн, җылы һәм суык, яшьлек һәм картлык, байлык һәм ярлылык, кара һәм ак, сугыш һәм тынычлык һ.б.лар)

• бу башлангычлар ( бербөтен яшәеш һәм Дөнья рухы яклары) бер-берсенә карата каршылыкта торалар, тик бер үк вакытта үзләренең асыллары белән бер һәм бер-берсе белән мөнәсәбәткә керәләр;

•капма-каршылыкларның берлеге һәм көрәше —бөтен дөньяның үсеш һәм яшәеш нигезе (ягъни гомуми барлык һәм үсеш нигезе).

**Үсеш механизмы** (абстракттан конкретка)

• билгеле **тезис бар** (караш, яшәү формасы);

• әлеге тезиска һәрвакыт **антитезис табыла** — аныэ капма-каршысы;

• ике капма-каршы техислар үзара бәйләнеше нәтиҗәсендә **синтез барлыкка килә**— яңа караш, ул үз чиратында үзе тезиска әйләнә, тик югарырак үсеш дәрәҗәсендә;

• әлеге процесс кабат-кабаттан була, һәм булган саен синтез нәтиҗәсендә тагы да югарырак дәрәҗәдәге тезис барлыкка китерә.

## 4. Рух фәлсәфәсе

**Субъектив рух** — җан, аерым кешенең аңы ("үзең өчен рух"дип аталган).

**Объектив дух** - рухныэ киләсе баскычы, "җәмгыятьнең тулаем алгандагы рухы". Объектив яңа рухның чагылышы булып хокук тора — югарыдан бирелгән, баштан ук идея буларак яшәгән (чөнки азатлык кешенең үзенә салынган) кешеләр арасындагы үзарамөнәсәбәтләр тәртибе. Хокук — тормышка ашырылган азатлык идеясе. Объектив рухның хокук белән беррәттән башка чагылышы булып әхлак, гражданнар җәмгыяте, дәүләт була.

**Абсолют рух** — рухның югары чагылышы, мәңге чын хакыйкать.

**Абсолют рухның чагылышлары**

**Сәнгать** —кеше тарафыннан турыдан-туры абсолют идеяләрне чагылдыру. Кешеләр арасында, Гегельгә ярашлы, абсолют идеяне"күрергә" һәм чагылдыдырга тик талантлы һәм гениаль кешеләр генә булдыра ала, моңа бәйле алар сәнгатьне иҗат итүчеләр була.

**Дин** — сәнгатьнең антитезисы. Әгәр сәнгать — абсолют идея, гениаль кешеләр тарафыннан "күрелгән", ә дин — кешегә Алла тарафыннан ачылган абсолют идея.

**Фәлсәфә** — сәнгать һәм дин кушылмасы, абсолют идеяны аңлау һәм үсешенең югары баскычы. Бу Алла тарафыннан бирелгән һәм шул ук вакытта гениалҗ кешеләр — фәлсәфәчеләр белән аңланылган белем . Фәлсәфә — барлык хакыйкатьнең, танып белүнең тулысынча ачылуы. Үз-үзеңнең абсолют рухың ("фикер белән әйләндерелгән дөнья" —Гегель буенча) абсолют идеи башы белән аның ахыры тоташуы, югары белем.

**Гегель буенча фәлсәфә предметы,**

- табигать фәлсәфәсе;
- антропология;
- психология;
- мантыйк;
- дәүләт фәлсәфәсе;
- гражданнар җәмгыяте фәлсәфәсе;
- хокук фәлсәфәсе;
- тарих фәлсәфәсе;
- гомуми законнар һәм принциплар хакыйкате буларак диалектика.

**История,** Гегельча, процесс самореализации Абсолют рухның үзеннән-үзе тормышка ашырылу процессы. Чөнки Абсолют рух үз эченә азатлык идеясен ала, барлык тарих ул кешенең күбрәк азатлык яулый баруы.

**Көнчыгыш эрасы** (Борынгы Мисыр, Кытай һ.б. Илләр чоры) — җәмгыятьтә тик берәү генә үзен бар дип белә һәм азатлык, барлык тормыш байлыклары белән файдалана ала — ул фараон, китай императоры һ.б.лар, ә калганнар аның коллары һәм хезмәтчеләре була.

**Антик-урта гасыр эрасы -** бу бер төркем кешеләрнең үзләрен тану чоры итеп билгеләнә (дәүләт башлыгы, аның тирәдәгеләр, хәрбиләр, аристократлар, феодаллар), тик төп масса басылган һәм ирекле түгел, “баштагыларга” бәйле һәм аңа хезмәт итә.

**Герман эрасы** —Гегель заманы (чоры) барысы да ирекле һәм барысы да үзләрен таный.

# 38нче сорау. Субъектив идеализм фәлсәфәсе
## *1. Субъектив идеализмның гомуми төшенчәсе*

Субъектив идеализм фәлсәфәсе

Төп идеяләр

- беренчедән, бердәнбер чынбарлык ул идея була;
- икенчедән, идея бары тик кеше акылында гына яши, ягъни кеше аңы мөһим чынбарлык була, аңардан тыш берни дә юк.

**Күренекле вәкилләре**

- **Брекли**
- **Юм**
- **Фихте**

## 2. Джордж Беркли фәлсәфәсе

Джордж Беркли (1685 — 1753) — яңа вакыт инглиз фәлсәфәчесе, субъектив идеалист.

**Төп идеяләр**

• материя төшенчәсе үзе ялган;

• аерым әйберләр, аерым хис-тойгылар бар, тик бекрләм материя юк.

• материализм — фәлсәфәдә тупикка илтүче юнәлеш, материалистлараерым әйберләрнең беренчеллеген дәлилли алмый( алар материя дип атаган) идеягә мөнәсәбәтле;

• киресенчә, идеянең беренчеллеген дәлилләү бик җиңел— теләсә кайсы әйберне әзерләү алдыннан аның идеясе була, кеше аңындагы уе, Алла – иҗат итүче буларак әйләнә-тирәне булдырыр алдыннан булган фикерләве;

• бердәнбер күзгә күренеп торган чынбарлык ул кеше аңы;

• кеше һәм аның аңы үлүе белән бар нәрсә дә юкка чыга;

• идеяләр — ул мөстәкыйль субстрат, ә нәрсәнең булса да чагылышы түгел, әйләнә-тирә дөнья идеяләргә яраклаша;

• идеянең беренчел булуына иң югары дәлил – ул Алла барлыгы; Алла мәңге яши һәм юкка чыга алмый.  Шул ук вакытта аның иҗат җимешләре әйләнә-тирәдәге мохит даими түгел, ул уалучан һәм тулысынча аңарга бәйле

## 3. Дэвид Юм фәлсәфәсе

**Дэвид Юм**(1711 — 1776) – инглиз фәлсәфәчесе, субъектив идеалист.

**Төп идеяләр**

- яшәеш һәм рух мәсьәләсе ахырынача хәл ителерлек түгел;
- кеше аңы идеяләргә тартым;
- кеше үзе концентрацияләнгән идея (бөтен кеше гомере аның идеаль көче арту процессы ул — тәҗрибә, белем, хисләр);
- үзенең идеаль асылыннан башка (мәсәлән, тәрбиясез, тәңрибәсез, кыйммәтләр системасыз) кеше дөньяны бөтенләй тулысынча кабул итә алдмас иде;
- кеше ике идеаль башлангычтан тора: "тышкы тәҗрибә йогынтысы" — алынган белемнәр һәм кабул ителгән белем һәм тәҗрибә,  "эчке тәҗрибә тәэссоратлары" — аффектлар, көчле теләкләр;
- аффектлар, кеше тормышында һәм тарих барышында зур әһәмият уйный.

# 4. Иоганн Готлиб Фихте фәлсәфәсе. Фихтенең « Мин-концепция»се

**Иоганн Готлиб Фихте** (1762 — 1814) — немец классик фәлсәфәсе вәкиле, профессор (соңгы яшәү елларында —Берлин университеты ректоры.

**Фәлсәфәнең төп төрләре**

**"Мин-концепция"** Аны тщкъдим итүгә сәбәп — Кант фәлсәфәсендәге каршылыклар, ә Фихте аның укучысы һәм тарафдары була. Фихте төп каршылыкны кантның танып белүче субүектның (кешенең) һәм танып була алмый торган әйләнә-тирәнең(“үзендәге әйберләр”) бүленешендә күрә. Бу бүленеш, Фихте буенча, акылның танып белү мөмкинлекләре чикле булу идеясе, антиномияләр кебек үк, фәлсәфәне ахыргача аның төп бурычын – яшәеш һәм фикерләүне берләштерүне башкару өметеннән мәхрүм итә

**Азатлык мәсьәләсе.** Фихте буенча, **азатлык** — гомум зарурлыкка ирекле буйсыну. *Бар кешелек тарихы* — азатлык тарату процессы, аның тантанасының юлы. Гомум азатлык нигезе — барысына да хосусый милек бүлеп бирү.

**"Мин -кеше" һәм "Мин түгел" арасындагы үзара бәйләнеш —"Абсолют Мин" эчендәге дөнья белән уратылган— субъектив рух**

**Төп положениеләр**

**«Мин» нең әйләнә-тирә дөнья белән үзара мөнәсәбәте (**«тезис - антитезис - синтез» схемасы буенча диалектик сурәтләнә)

- «үзендәге әйберләр” идеясен үзен инкарь итә — акыл белән танып булмый торган реаль чынбарлыкны;
- бердәнбер чынбарлык итеп эчке, субъектив, кеше “Мин”ен игълан итә, аңарда бөтен дөнья керә (ягъни яшәешне фикерләү эченә кую юлы белән яшәеш белә фикерләүне берләштерә,әйткәндәй субъективны, субъектны объектка күчерә);
- әйләнә-тирә дөнья тормышы тик субъектив “Мин” эчендә генә була дип исәпли;
- фикерләүдән тыш,“Мин”нән тыш мөстәкыйль әйләнә-тирә чынбарлык юк;
- «Мин» үзе — кеше акылы гына түгел, ул хәрәкәт, барлыкка китерүче көч, әйләнә-тирә дөнья савыты, чынбарлык өсте, югары субстанция диярлек (Декарт һәм Спиноза фәлсәфәсендә югары субстанция аналогиясе буенча — Алла белән).

- Абсолют Мин үз-үзен фараз итә ("Мин Минне фараз итә);
- "Мин" “Мин түгел”не фараз итә (барлыкка китерә) — тышкы әйләнә-тирә чынбарлыкны (антитезис);
- "Мин" (актив иҗат, башлангыч, субъект, кеше шәхесенең аңы) “Мин түгел” белән элемтәгә керә (пассив башлангыч белән — әйләнә-тирә дөнья) Абсолют Мин эчендә (савыт, югары субстанция).

- гамәли ( "Мин"нән — "Мин түгел"гә; "Мин" — иҗат итә, “Мин түгел”не билгели, үзара бәйләнешнең төп төре);
- теоретик ("Мин тъгел"дән "Мин"гә — икенче сирәгрәк үзара бәйләнеш төре, эмпиристик, тәҗрибә тапшыру, “Мин түгел”дән мәгълүмат — әйләнә-тирә дөнья- "Мин"гә (конкрет аң). Фихтенең икекнче фәлсәфә соравы — **азатлык мәсьәләсе.** Фихте буенча, **азатлык** — гомум зарурлыкка ирекле буйсыну. *Барлык кешелек тарихы* — азатлык тарату процессы, аның тантанасына юл. Гомуми азатлык нигезе - барысын да хосусый милек белән тәэмин итү.

39нчы сорау. Шеллинг фәлсәфәсе

*1. Шеллинг фәлсәфәсенең бүленеше*

**Фридрих Вильгельм Йозеф Шеллинг** (1775 — 1854) немец классик фәлсәфәсенең объектив идеализмының күренекле вәкиле була, Гегельның дусты, аннары аның оппоненты.

Шеллинг фәлсәфәсенең төп максаты — **«абсолютны» аңларга һәм аңлатырга.** Аның өч төп этабы:

Шеллинг фәләсәфәсенең чорларга бүленеше:
- -натурфилософия
- -гамәли фәлсәфә
- -иррационализм

## 2. Шеллинг натурфилософиясе

Шеллинг натурфилософиясе

Алдагы концепцияләр табигатьне аңлатулар хак түгел, чөнки беренче очракта табигать кеше аңыннан чыгарыла, ә калган очракларда (Спиноза субстанция теориясе һ.б.лар)табигатьне чикләнгән рәвештә аңлату;

**Табигать ул "абсолют"** — бар нәрсәнең беренчел сәбәбе һәм башлангычы, бар нәрсәне колачлап ала;

Табигатҗ ул субъектив һәм объективның берлеге, мәңгелек акыл;

материя һәми рух бердәм һәм табигать үзенчәлекләре булып тора, абсолют акылның төрле торышы;

Табигатьне хәрәкәт иттерүче көч ул аның полярлыгы - эчке каршылыклар һәм аларның үзарабәйләнеше булуы;

**Табигать җанлылыкка ия булган тулы бер организм, (тере һәм тере булмаган табигать, материя,басу, электр, яктылык бербөтен)**;

# 3. Шеллингның гамәли ( социаль-сәяси) фәлсәфәсе

**Шеллингның гамәли фәлсәфәсе (социаль-сәяси характердагы мәсьәләләрне, тарих барышын хәл итә)**

Кешелекнең тулаем төп мәсьәләсе һәм фәлсәфәнең төп предметы,Шеллинг буенча, азатлык мәсьәләсе була. Азатлыкка омтылу кешенең үз табигатенә салынган һәм аның тарихи процессының төп максаты була.

Шеллингның гамәли фәлсәфәсенең башка мөһим мәсьәләсе (азатлык мәсьәләсе белән бергә) читләшү мәсьәләсе. Читләшү — кеше эшчәнлегенең реаль чынбарлык һәм азатлык идеясе белән бәйләнешкә керүе нәтиҗәсендә башлангыч максатларга капма-каршы нәтиҗәгә килү.

Нәтиҗәләр:

- тарих барышы очраклы, тарихта үзиреклелек хөкем итә;
- тарихның очраклы вакыйгалары да, максатчан эшчәнлек тә катгый зарурлыкка буйсына, болар алдында кеше көчсез, ул берни дә эшли алмый;
- теория (кеше уй-ниятләре) һәм тарих (реаль чынбарлык) еш кына капма-каршы һәм бернинди уртаклыклары юк;
- тарихта азатлык һәм гаделлек өчен көрәш тагы да көчлерәк коллыкка һәм гаделсезлекккә китергән очраклар еш кына.

# 40нчы сорау. Людвиг Фейербах фәлсәфәсе
## *1. Л. Фейербах материализмын нигезләү*

**Людвиг Фейербах фәлсәфәсе** (1804 — 1872) *немец классик фәлсәфәсенең йомгаклау этабы, күренекле вәкилләре* - Кант, Гегель, Шеллинг һәм Фихте, һәм немец һәм дөнҗя фәлсәфәсендә *материалистик чор башлангычы итеп исәпләнелә*. Фейербах фәлсәфәсенең төп юнәлеше— немец классик идеализмын тәнкыйтҗләү һәм материализмны нигезләү.

Материализм: материализм фәлсәфәсе юнәлеше буларак Фейербахка кадәр күптән барлыкка килә (Борынгы Греция – Демокрит һәм Эпикур; Яңа вакыт Англия – Бэкон, Локк; Франция – мәгърифәтче-материалистлар), әмма әйтелгән материалистик фәлсәфә мәктәпләре булган, башлыча, үз чорының эчке милли күренеше һәм эзлексезлек һәм каршылыклылык белән аерылып тора, теологиянең көчле йогынтысында булалар, материалистик идеяләр һәм Алла барлыгы арасында килешкәнлек (компромисс) эзлиләр (мондый компромиссның бер формасы деизм була). Людвиг Фейербах фәлсәфәсе материализмның тирәнтен эзлекле беренче очрагы була.

### Төп үзенчәлекләре:

- Дин белән тулысынча аерылу (атеизм) һәм күп гасырлык дини йогынтыдан азат булу;
- Алла һәм динне материалистик күзлектән, кеше табигатеннән чыгып аңлатырга тырышу;
- материалистик, фәннең яңа казанышларын исәпкә алып, әйләнә-тирә дөнья һәм кеше мәсьәләләрен аңлату;
- социаль-сәяси мәсьәләләргә зур кызыксыну;
- әйләнә-тирә дөньяны танып белүгә ышаныч.

## *2. Фейербахның Гегель фәлсәфәсен тәнкыйтьләве*

Идеалистик фәлсәфәне тәнкыйтьләү, аеруча Гегельне

↓

- яшәеш һәм фикерләү тантана идеясен инкарь итү;
- Абсолют идея барлыгын инкарь итү – мөстәкыйль субстанция һәм материаль дөнья беренчел сәбәбен;
- Абсолют идеянең материаль дөньяга читләшә(әйләнә) алмавын дәлилләү – әйләнә-тирә дөнья күзгә күренеп тора һәм аны тотып карап була, ә абсолю идея – тик акыл фарызы, Гегель уйдырмасы;
- Фәлсәфә һәм дин берлеген инкарь итү;
- Диалектиканы инкарь итү;
- Фейербах Гегель фәлсәфәсен ясалма, хорафатка дучар, үткәнгә юнәлтелгән, фәннең яңа казанышларына туры килми дип саный.

## *3. Фейербах антропологиясе*

Антропологик материализм теориясе

↓

• бердәнбер булган чынбарлык ул табигать һәм кеше;
• кеше табигатьнең бер өлеше;
• кеше материаль һәм рух берлеге;
• кеше фәлсәфәнең төп кызыксынуы булырга тиеш;
• идея үзеннән-үзе яши алмый, ул кеше аңы җимеше;
• Алла аерым һәм мөстәкыйль чынбарлык буларак яшәми; Алла — кеше хыялы җимеше;
• табигать (материя) мәңгелек һәм чиксез,бер кем тарафыннан барлыкка китерелмәгән һәм беркем тарафыннан юк ителми;
• безне уратып алган бар нәрсә (предметлар, күренешләр), —материянең төрле чагылышы.

## *4. Фейербах фәлсәфәсендә Алла мәсьәләсе*

Л. Фейербахның атестик-антропологик теориясенең төп положениеләре

- ✔ Мөстәкыйль чынбарлык буларак Алла юк;
- ✔ Алла – кеше аңы тудырган нәрсәсе;
- ✔ Дин – тирән эшкәртелгән мифологик-фантастик идеология һәм чынбарлык белән бернинди дә уртаклыгы юк;
- ✔ Диннең таралышы кешеләрнең наданлыгы, аның авыр тормыш шартлары аркасында мөмкин була;
- ✔ Дин тамырлары –кешенең тышкы дөнья алдындагы көчсезлек хисендә, аның аңа бәйле булуында һәм сакланмаганлыгында;
- ✔ Алла турындагы уй – чамадан тыш көчле акыллы асыл – кешеләрне юата, аның куркуын һәм аффектларын киметү;
- ✔ Алла – кеше тарафыннан төзелгән кешенең идеаль образы, кеше үзен ничек күрергә тели, ул шул була;
- ✔ Алла чыныннан барлыкка китерүче түгел, ул – кеше уйдырмасы, аның акылы, шул ук вакытта чын иҗатчы буларак (ә тудырылган түгел) – кеше.

## *5. Фейербах гносеологиясе*

И. Канта гносеологиясе: кеше акылының танып белү сәләте чиклелеге, әйберләр һәм әйләнә-тирә дөнья күренешләренең эчке асылы танып булмавы (агностицизм) турындагы теория

Фейербах гносеологиясе
Үзенчәлекләре:

- ✔ Әйләнә-тирә дөньяны танып белеп була, ә акылның танып белү мөмкинлекләре чиксез. Әмма акылның танып белү мөмкинлекләренең чиксезлеге шунда ук тумый, ә кеше эволюциясе, тәҗрибә туплау, фәнни-техник прогресс үсешүе нәтиҗәсендә тора-бара үсешә.
- ✔ Әлеге идея асылы (акылның тора-бара танып белү сәләте үсеше турында һәм аның чиксезлеге турында) фәлсәфәче болай дигән: «Без танып белмәгәнне, безнең нәселебез танып беләчәк».
- ✔ Основу познания составляют субъективные чувственные ощущения, в основе которых лежит объективная реальность и которые осознаются разумом.
- ✔ Шулай итеп, Фейербах гносеологиясе эмпиристик һәм рациональ алымнарны кушу һәм тигезләү барышында материалистик принципларга нигезләнә.

## *6. Социаль-сәяси фәлсәфә*

Фейербахның социаль-сәяси карашлары

- кеше — ихтыяр, акыл, хис-тойгы, теләкләр бирелгәнуникаль (кабатланмас) биологик җан иясе;
- кешенең үз «Мин»ен тулысынча тормышка ашыру бары тик «Син» белән генә (ягъни башка кешеләр белән генә) үзара бәйләнештә мөмкин — кеше бары тик җәмгыятьтә генә яши ала;
- җәмгыятьтәге кешеләрнең элемтә нигезе, җәмгыять үзәге дин булырга тиеш;
- әлеге дин уйлап чыгарылган зат – Аллага нигезләнгән булырга тиеш түгел, ә башка принципларга;
- традицион динне читкә ташларга кирәк (христианлык, мөселманлык һ.б.) һәм аны кешеләрнең бер-берсен ярату дине белән алы һәм кеше табигатенә ныграк җавап биререлек гаилә эчендәге мәхәббәт дине белән алыштырырга кирәк ;
- кешенең яшәү мәгънәсе бәхеткә ирешү булырга тиеш.

# 41нче сорау. Вульгар материалистлар фәлсәфәсе

**Вульгар** (француз теленнән — гади, примитив, гадәти) **материализм** — XIX гасырда киң таралу алган фәлсәфә юнәлеше.

Төп идеяләр:
- рухны (идеяне) чынбарлык буларак тулысынча инкарь итәләр;
- бердәнбер чынбарлык итеп материяне саныйлар;
- аң артыннан идеальлелек сыйфатын кире кагалар, аңны химик процесс буларак аңлатырга тырышалар;
- атеистлар булалар;
- үзләренең тикшеренүләрендә табигый фәннәр казанышларына таяналар (энергия саклану законы, материя саклану законы, социаль дарвинизм һ.б.лар);
- географик детерминизм идеяләренә таяналар (кешегә география, климат йогынтысы һәм башка яшәеш процесслары);
- диалектиканы кире кагалар;
- һәрнәрсәгә бер мәгънәле аңлатмалар бирергә омтылалар, ике төрле аңлауны һәм каршылыкларны калдырмыйлар («кара — ак« принцибы буенча);
- традицион материализм положениеләрен шактый гадиләштерәләр.

## Вәкилләр

Людвиг Бюхнер (1824 – 1899) – фәлсәфәче, вульгар материалист, төп һөнәре буенча табиб-табигать фәннәре белгече. Төп хезмәтләре: «Табигать һәм фән», «Хайваннарның психологик тормышы», «Дарвинизм һәм социализм»

Төп идеяләре:

- Идеалистик фәлсәфи концепцияләрнең нигезсез булуын дәлилләгән;
- их яхшы һәм дөрес фәлсәфи тәгълимат итеп Людвиг Фейербах фәлсәфәсен исәпли;
- Соңгы «социал-дарвинизм» тарафдары була –тормыш законнарын һәм хайваннарның үзара мөнәсәбәтен механик рәвештә кешеләр һәм җәмгыять тормышына күчерә.

Яков Молешотт (1822 – 1983) фикерләү физиологик процесс дигән теорияне тәкъдим итә.

Карл Фохт (1817 – 1895) – фәлсәфәче, вульгар материалист, һөнәре буенча табиб-табигать фәннәре белгече

Төп идеяләре:
- кеше барлыкка килү турындагы библия (инҗил) тәгълиматын тәнкыйтьли;
- кешене маймылның якын туганы дип саный;
- социализм идеясенә дошманлык мөнәсәбәтендә була, чөнки, аның фикеренчә, ул кеше табигатенә туры килми; фикерләү һәм аңны физик-химик процесс итеп күрә – «бавыр үт чыгарган төсле, ми фикер бүлеп чыгара.

# 42нче сорау. Марксизм фәлсәфәсе
## *1. Марксистик фәлсәфәгә гомуми төшенчә*

**Марксистик фәлсәфәсе** ике немец галимы - **Карл Маркс** (1818 — 1883) һәм **Фридрих Энгельс** (1820 - 1895) тарафыннан XIX гасырның икенче яртысында төзелә һәм тагы да киңрәк тәгълиматның - **марксизмның** бер өлеше була, ул фәлсәфә белән берлектә икътисадны (политэкономияне) һәм социаль-сәяси мәсьәләләрне (фәнни коммунизмны) үз эченә ала.

**Марксизм һәм марксисистик фәлсәфә барлыкка килүгә этәргән күренешләр:**

- ✔Материалистик фәлсәфәгә кадәрге (Демокрит, Эпикур, XVIII гасыр инглиз материалистлары һәм аеруча XIX гасырның урталарындагы Людвиг Фейербахның атеистик-материалистик фәлсәфәсе)
- ✔Фән һәм техниканың көчле үсеше;
- ✔ Бөек француз революциясе идеалларын җимерү (азатлык, тигезлек, туганлык, Франөуз Мәгърифәтчелек идеяләре), аларны тормышка ашырып булмавы;
- ✔социаль-сыйнфи каршылыклар һәм конфликтлар үсүе( 1848 – 1849 еллар, реакция, сугыш, 1871елгы Париж коммунасы);
- ✔ буржуазиянең преволюционнан консерватив көчкә әверелүе, традицон буржуаз кризисы (никах, әхлак)

**Марксизмга нигез салучыларның төп әсәрләре :**

- **✔К. Маркcның «Фейербах турында тезислар»;**
- **✔К. Маркcның «Капитал»;**
- **✔ К. Маркcның«1844 елгы икътисадый-фәлсәфи кулъязмалар»;**
- **✔К. Маркс һәм Ф. Энгельсның «Коммунистик партия манифесты;**
- **✔ К. Маркс һәм Ф. Энгельсның «Изге гаилә» һәм «Немец идеологиясе»;**
- **✔ Ф. Энгельсның «Табигать диалектикасы»;**
- **✔Ф. Энгельсның «Анти-Дюринг»ы;**
- **✔Ф. Энгельсның маймылның кешегә әйләнеү процессы барышында хезмәтнең роле»;**
- **✔ Ф. Энгельсның «Гаиләнең, шәхси милекнең һәм дәүләтнең барлыкка килүе».**

# 2. Марксистик фәлсәфәнең төп юнәлешләре

**Тарихи материализм:**
• кешеләр үзләренең һәр иҗтимагый үсеш баскычында үз эшчәнлекләрен тәэмин итү өчен аерым, объектив, аларның ихтыярына бәйсез булган җитештерү мөнәсәбәтләренә керәләр (үз хезмәтеңне сату, материаль җитештерү, бүлү);
• җитештерү мөнәсәбәтләре, җитештерүче көчләр дәрәҗәсе икътисадый системаны барлыкка китерә, ул дәүләт һәм җәмгыять институтларына, иҗтимагый мөнәсәбәтләргә нигез булып тора;
• әйтелгән дәүләт һәм иҗтимагый институтлар, иҗтимагый мөнәсәбәтләр икътисадый базиска (нигезгә) карата өскормә сыйфатында чыгыш ясый;
•җитештерүче көчләр һәм җитештерү мөнәсәбәтләре үсеше дәрәҗәсенә, билгеле нигез төре һәм өскормага карап, иҗтимагый-икътисадый формацияләр бүленеп чыга —борынгы община строе (җитештерү көчләр һәм җитештерү мөнәсәбәтләренең түбән дәрәҗәсе, җәмгыятьнең яралгылары); кол биләүчелек җәмгыяте (икътисад колларга нигезләнә); азиая
• җитештерү ысулы - махсус иҗтиагый-икүтисадый формация, аның икътисады массалы, коллектив, ирекле кешеләрнең – эре елгалар үзәнлекләрендәге (Борынгы Мисыр, Месопотамия, Кытай) игенчеләрнең хезмәте дәүләт тарафыннан катгый идарә ителүенә нигезләнә; феодализм (икътисад эре җир милегенә һәм буйсынучы крестьяннар хезмәтенә игезләнгәнә);
 капитализм (ирекле, әмма җитештерү чараларына милекче булмаган ялланган эшчеләр хезмәтенә нигезләнгән сәнәгать җитештерүе; социалистик (коммунистик) җәмгыять — киләчәк җәмгыяте, җитештерү средстволары дәүләт милегендә (иҗтимагый) булган тигез хокуклы кешеләрнең ирекле хезмәтенә нигезләнгән;
• җитештерү көчләре үсеше җитештерү мөнәсәбәтләре, иҗтимагый-икътисадый формацияләрнең һәм иҗтимагый-сәяси строй үзгәрешенә китерә;
• икътисад дәрәҗәсе, материаль җитештерү, җитештерү мөнәсәбәтләре дәүләт һәм җәмгыять язмышын, тарих барышын хәл итә.

**Диалектик материализм**:
•фәлсәфәнең төп мәсьәләсе яшәеш файдасына хәл ителә (яшәеш аңны билгели);

• аң мөстәкыйль асыл буларак түгел, ә материянең үз үзен чагылдыру үзенчәлеге буларак аңлана;

• материя даими хәрәкәттә һәм үсештә була;

• Алла юк, Ул идеаль образ, кешелеккә аңлашылмаган күренешләрне аңлатыр өчен кеше фантазиясе җимеше, һәм кешелек дөньясына (аеруча аның томана өлешенә) юаныч һәм өмет бирә; Алла әйләнә-тирә чынбарлыкка бернинди дә йогынты ясамый;

• материя мәңгелек һәм чиксез,даими рәвештә үз яшәешенең яңа формаларын кабул итә;

• гамәл(практика) үсешнең мөһим факторы- кеше тарафыннан әйләнә-тирә чынбарлыкны үзгәртүе һәм кеше тарафыннан кешене үзен үзгәртүе;

• үсеш диалектика законнары буенча бара — капма-каршылыклар берлеге һәм көрәше, күләмнең сыйфатка күчеше, икарь итү.

# 3. Икътисадый теория

Икътисадый теория

Төп положениеләр

Социалистик иҗтимагый-икътисадый мөнәсәбәтләр урнаштыру тәртибе

**-җитештерү средстволары -** уникаль товар, югары дәрәҗә хезмәт функциясе, яңа товар җитештерүгә булышлык итүче. Яңа товар җитештерү өчен җитештерү средстволарыннан тыш аларны хезмәтләндерүче көч кирәк, - ягъни «эшче көче».

-Капитализм эволюциясе барышында төп эшче массаны җитештерү средстволарыннан читләштерү процессы бара һәм, димәк, хезмәт нәтиҗәләреннән**. Төп** товар – җитештерү средстволары – азчылыкны тәшкил иткән милекчеләр кулында туплана, ә җитештерү средстволарына ия булмаган һәм мөстәкыйль хезмәт хакы чыганаклары юк төп хезмәт массалары, үзләренең мөһим ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатында җитештерү средстволары милекчеләренә хезмәт хакы өчен ялланган эшчеләр булып мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була.

-ялланган эшче көчләр җитештергән продукт бәясе аларның хезмәтенә караганда югарырак (хезмәт хакы төсендә), Маркс буенча, алар арасындагы аерма өстәмә кыйммәт була, аның бер өлеше капиталистның кесәсенә керә, ә бер өлеше киләчәктә тагы да зуррак өстәмә кыйммәт алыр өчен яңа җитештерү средстволарына салына.

- Бу хәлдән чыгу юлын марксистик фәлсәфәгә нигез салучылар яңа, **социалистик (коммунистик) иҗтимагый-икътисадый мөнәсәбәтләр** урнаштыруда күрәләр

-Җитештерү средстволарына хосусый милекне бетерү

-Кешенең кешене эксплуатацияләвен һәм чит хезмәт нәтиҗәләрен бер төркем кешеләр тарафыннан үзләштерүне бетерү

-хосусый милек җитештерү средствосын иҗтимагыйга алыштыру

-Җитештерү продуктын һәм хезмәт нәтиҗәләрен җәмгыятьнең барлык әгъзалары арасында гадел бүлү

# 43нче сорау. Огюст Контның позитивизм фәлсәфәсе

**Позитивизм** — фәлсәфә юнәлеше, аның асылы фәлсәфәне ныклы фәнни нигезгә бастыруга омтылудан гыйбарәт. Позитивизм фәлсәфи фикер агымы буларак XIX гасырның 30нчы — 40нчы елларда барлыкка килә, зур эволюция юлы үтә (махизм, неопозитивизм, постпозитивизм һ.б.лар.). Безнең заманда да киң таралыш тапкан һәм популяр.
Позитивизмга нигез салучы дип **Огюст Конт** (1798 — 1857) исәпләнелә – француз фәлсәфәчесе, Сен-Симон укучысы. Шулай ук аның үсешенә Джон Милль (1806 - 1873) һәм Герберт Спенсер (1820 - 1903) да зур өлеш кертә.

## Огюст Конт фәлсәфәсе

### Позитив белем

- фәлсәфи белем абсолют төгәл һәм дөрес булырга тиеш;
- аңа ирешү өчен фәлсәфәтанып белүдә фәнни ысул кулланырга тиеш һәм башка фәннәр казанышына таянырга тиеш;
- фәлсәфәдә фәнни белем алу өчен төп юл — эмпиристик күзәтү;
- фәлсәфә тик фактларны гына тикшерергә тиеш, ә аларның сәбәбен түгел, әйләнә-тирә дөньяның «эчке асылын" һәм башка фәннән ерак булган мәсьәләрне;
- фәлсәфә кыйммәтлелек ысулыннан һәм тикшерү барышында бәһалау характерыннан азат булырга тиеш;
- фәлсәфә «фәннәр патшабикәсе», аерым гомумтеоретик дөньяга караш булуга омтылырга тиеш түгел — ул нәкъ фәнни (ә башка түгел) средство арсеналына таянучы конкрет фән булырга тиеш, һәм башка фәннәр арасында үзенең урынын биләргә тиеш.

### Эволюция ике төрлелеге

#### интеллектуаль үсеш стадияләре

- теологик (дингә нигезләнгән дөньяга караш);
- метафизик (дөньяга караш, интеллектуаль үсеш системасыз, ихтимал белемгә нигезләнгән үсеш);
- позитив (фәнгә нигезләнгән).

#### техник үсеш стадияләре

- традицион җәмгыять;
- индустриальгә кадәрге җәмгыять;
- индустриаль җәмгыять.

## 44нче сорау.Шопенгауэр, Ницше, Дильтейның классик булмаган идеалистик фәлсәфәләр.

### *1.Классик идеалистик фәлсәфәгә гомуми төшенчә. Аның немец классик фәлсәфәгә карата мөнәсәбәте*

**Классик идеалистик фәлсәфәүзенең максаты итеп** немец классик фәлсәфәне тәнкыйтьләүне куя, аеруча Гегельны, яңа ысуллар кулланып түгел, ә искеләрен (материалистлар һәм позитивистлар эшләгәнчә). Классик булмаган фәлсәфә вәкилләре дөнҗяны «классик»лар кебек идеализм күзлегеннән аңлатырга, әмма иске изеализм, гегелҗгә чаклы һәм классикка чаклы күзлегеннән, (мәсәлән, платонча һ.б..) һәм иске классик идеализмга кадәрге кысаларында яңа, оригиналь ысуллар табарга тырышалар.

Немец классик фәлсәфә (аның гәүдәләнеше булып Кант, Фихте, Шеллинг һәм аеруча Гегель ижаты булды) дөнья фәлсәфә үсешенә зур өлеш кертteләр һәм үз вакыты өчен максималь дәрәҗәдә яшәеш, аң, башка фәлсәфи мәсьәләләрен идеализм күзлегеннән асылын аңлатып бирделәр.

Немец классик фәлсәфә тәнкыйде юнәлеше (XIX гасырның икенче яртысы)

- Л. Фейербах, К. Маркс и Ф. Энгельсның материалистик фәлсәфә белән күрсәтелгән «султан тәнкыйть";
- классик булмаган идеалистик фәлсәфә белән «уңнан тәнкыйть", представленная так называемой неклассической идеалистической философией.

Төп юнәлешләре

| | |
|---|---|
| Иррационализм (Шопенгауэр) | «яшәү фәлсәфәсе» (Ницшей, Дильтей) |

# 2.Иррационализм. Артур Шопенгауэр фәлсәфәсе

**Иррационализм** табигатьтәге логик бәйләнешләрне, әйләнә-тирә дөньяны бөтен һәм закончалыклы система буларак кире кага, Гегельның диалектикасын һәм үсеш идеясен үзен тәнкыйтьли.

Иррационализмга нигез салучы дип **Артур Шопенгауэр** (1788 - 1860) санала.

Шопенгауэрның фәләсәфәсе тулаем алганда пессимистик рух, кеше мөминлекләренең әйләнә-тирә дөньяга һәм үз тормышына йогынты ясый алу ына ышанмау.

«Дөнья ихтыяр һәм гәүдәләнеш буларак" китабында фәлсәфәче җитәрлек нигезләү логик законын чыгара. Бу законга ярашлы, хак фәлсәфә объекттан да (материалистлар кебек), суъекттан да (субъектив идеалистлар кебек) гына түгел, ә тик аң факты булган күзаллаудан гыначыгып эш итәргә тиеш.

Үз чиратында күзаллаулар (ә объектив чынбарлык һәм танып белүче субъект түгел) объект һәм субъектка бүленә.

**волюнтаризм,** аңа ярашлы, әйләнә-тирәдә төп хәрәкәт иттерүче көч ул – ихтыяр

**Воля**, Шопенгауэр буенча, - абсолют башлангыч,бар нәрсәнең тамыры, бар нәрсәне билгели алучы һәм аңа йогынты ясаучы идеаль көч. Ихтыяр шулай ук югары космос принцибы, ул гамләм нигезендә ята.

Шопенгауэр ихтыярны әйберләрнең гомуми асылы буларак аңлатканда кантианлыкка таяна, төгәлрәк Кант теориясенә, аның ярдәмендә аңда әйләнә-тирә әйберләрнең бары тик образлары гына чагыла, ә аларның асылы ачылмаган табышмак булап кала («үз эчендәге әйбер).

Тулаем алаганда фәлсәфәче карашы пессимистик характер йөртә. Кеше нигезенә һәм аның аңына Шопенгауэр ихтыярны салуга карамастан, ул кешенең табигать өстеннән генә түгел, үз-үзе өстеннән дә хакимлек итәчәгенә ышанмый.

- әйләнә-тирә дөнья кеше аңында туган дөнья гына ул;
- дөнья асылы, аның әйберләре, күренешләре ул "үз эчендәге әйбер түгел", ә ихтыяр;
- күренеләр дөньясы һәм асы дөньясы, димәк, күзаллаулар дөньясы һәм ихтыяр дөньсы була;
- кешенең ихтыяры аның гамәлләрен билгеләгән кебек, бөтен дөньяда хәрәкәт итүче гомуми ихтыяр, предметлар һәм күренешләр ихтыяры дөньядагы тышкы вакыйгаларны, предметлар хәрәкәтен, куренешләр барлыкка килүен китереп чыгара;
- ихтыяр тере организмга гына түгел, җансыз табигатькә дә "аңсыз", "йокымсыраган" ихтыяр буларак хас;
- әйләнә-тирә асылы белән ихтыярның тормышка ашырылуы.

# 3. Фридрих Ницшенең «Яшәү фәлсәфәсе"

Фридриха Ницшенең (1844 – 1900) «Яшәү фәлсәфәсе» хәзерге көнчыгыш фәлсәфәнең элгәре концепциясе була, аларның нигезендә кеше һәм аның тормышы проблемалары ята, - прагматизм, феноменология, экзистенциализм һ.б.лар.

Фәлсәфә максаты, Ницше буенча, — кешегә тормышта мөмкин кадәр үз урынын табарга, әйләнә-тирә дөньяга күнегергә ярдәм итү.

Әлеге фәлсәфәнең үзәк төшенчәсе - тормыш төшенчәсе, ул танып белү субүектының дөнҗяны барлыгы аспектында булуы, конкрет кеше өчен бар булган бердәнбер чынбарлык.

Яшәү һәм әйләнә-тирә дөнья нигезендә ихтыяр ята.

- «яшәүгә ихтыяр";
- кешенең үзе эчендәге ихтыяр («эчке үзәк»);
- идарә итеп булмый торган, аңсыз ихтыяр - көчле теләк, омтылыш, аффектлар;
- «властька ихтыяр".

Соңгы тәр — "властька ихтыяр" — фәлсәфәче аерым игътибар бүлә. Ницше буенча, «властька ихтыяр« күбрәк яки азрак дәрәҗәдә һәр кешегә хас. Үзенең табигате буенча "властька ихтыяр" үз-үзеңне саклау инстинктына якын, кеше эчендә яшерелгән хәвефсезлеккә омтылуның чагылышы һәм аның гамәлләренең хәрәкәт иттерүче көче булып тора. Ницшега ярашлы, һәр кеше (дәүләт кебек үк) аңлы яки аңсыз рәвештә тышкы дөньяда үзенең «Мин»ен киңәйтергә омтыла.

## 4. *Вильгельм Дильтейның «Яшәү фәлсәфәсе»*

Вильгельм Дильтейның «Яшәү фәлсәфәсе»

Фәлсәфи фикерләр

Дильтей Гегель фәлсәфәсен тәнкыйтьләп чыга, аңарда әйләнә-тирә дөньяның бар төрлелеге һәм кеше гомеренң уникальлеге фикерләүгә (идеягә) барып тоташа. Фикерләү урынына Дильтей фәлсәфә нигезенә «яшәү» төшенчәсен салырга тәкъдим итә.

Дильтейга ярашлы, фәлсәфә материя, аң, диалектика һ.б.лар турында "схоластик" бәхәсләрен туктатырга тиеш, һәм игътибарны аерым бер феномен буларак яшәүне өйрәнүгә юнәлтергә тиеш.

Фәлсәфәче тарих – прогресс ягына юнәлүче, алдан билгеле һәм закончалыклы процесс дигәнгә ярашлы концепцияләрне инкарь итә. Дильтей буенча, тарих — очраклылк, хаос, чоңгыл чылбыры, ул үзенә аерым кешене дә, тулы милләтләрне дә тартып алып керә ала. Тарихка йогынты ясап булмый.

Яшәү – кешенең дөньядагы яшәеш ысулы

Тормыш билгеләре

- бөтенлек;
- төрле рухи башлангыч барлыгы;
- югары дөнья белән аерылгысыз берлеге.

# III бүлек. Төп фәлсәфи проблемалар

## 45нче сорау. Яшәеш

**Онтология- фәлсәфәнең яшәеш проблемасын өйрәнүче үзәк бүлекләренең берсе, ә яшәеш проблемасы үзе — фәлсәфәдә иң мөһиме. Фәлсәфәнең аякка басуы нәкъ яшәеш мәсҗәләсен өйрәнүдән башланып китә. Борынгы һинд, борынгы кытай, антик фәлсәфә беренче чиратта онтология белән кызыксына, яшәеш псылын аңларга омтыла**

**Яшәеш - бар асылны үзенә керткән *реаль бар булган, тотрыклы, мөстәкыйль, объектив, мәңгелек, чиксез субстанция*.**

**Яшәешнең юклыгы — нәрсәнең булса да тулысынча юк булу, абсолют берни түгел. Яшәешнең юклыгы— яшәеш белән бердәм халәт *(шулай ук реаль) һәм аңа капма-каршы*.**

**«Яшәеш» фәлсәфи категория эчтәлеген ачучы положениеләр**

Әйләнә-тирә дөнья, предметлар, күренешләр реаль бар; ул (әйләнә-тирә дөнья) бар

әйләнә-тирә дөнья үсешә, эчке сәбәбе бар, үз үзендә хәрәкәт итү чыганагы

материя һәм дух — бердәм, әмма шул ук вакытта капма-каршы асыллар, реаль бар

субстанцияләр — мөстәкыйль асыллар, ул үзеннән башка ул бернәрсәдә дә мохтаж түгел.

**Яшәешнең төп формалары**

- *материаль (матди) яшәеш — материаль булган (* озынлык, масса, күләм, тыгызлыкка ия) җисем, әйбер, табигать күренешләре, әйләнә-тирә дөнья
- *идеаль яшәеш — идеалҗ бар булган мөстәкыйль чынбарлык кебек индивидуальләштерелгән рухм яшәеш һәм обуективлаштырылган (индивидуальдән тыш) рухи яшәеш*
- кеше яшәеше - *материаль һәм рухи (идеаль) берлеге буларак кеше яшәеше*, кешенең үз-үзеннән генә яшәеше һәм аның материаль дөньяда яшәеше
- *социаль яшәеш, ул кешенең җәмгыятьтәге һәм җәмгыятьнең үзенең яшәешеннән үз эченә кертә (тормыш, бар булу, үсеш).*

- *ноуменаль яшщеш* ("ноумен« сүзеннән — үз үзеннән әйбер) — яшәеш, ул аны читтән күзәтеп торучының аңыннан тыш бар була
- *феноменаль яшәеш* ("феномен" сүзеннән - күренеш, тәҗрибәдән алынган) — күренгәндәй яшәеш, ягъни танып белүче субъект аны ничек күрә, шундый яшәеш

# 46нчы сорау. Материя (материаль яшәеш)

## *1. Материаль яшәеш һәм «материя» төшенчәсенә төп якын килү юлы*

***Материя төзелеше элементлары***

**Җансыз табигать баскычлары**

- ✔ Субмикроэлементар (кварки, глюоны, суперструннар – материянең иң вак кисәкчәләре, атмнарга караганда да кечерәк);
- ✔ Микроэлементар (кварклардан торган адроннар, электроннар);
- ✔ Төш (атом төше);
- ✔ Атом (атомнар);
- ✔ Молекуляр (молекулалар);
- ✔ Бердәнбер әйберләр дәрәҗәсе;
- ✔ Макроҗисем баскычы;
- ✔ Планеталар дәрәҗәсе;
- ✔ Планеталар системасы дәрәҗәсе;
- ✔ Галактика дәрәҗәсе;
- ✔ Галактика системалары дәрәҗәсе;
- ✔ Мегалактика дәрәҗәсе;
- ✔ Галәм дәрәҗәсе, тулысынча дөнья.

**«Материя» төшенчәсенә якын килү**

Материалистик ысул, аңа ярашлы, материя яшәеш нигезе ул, ә башка яшәү формалары– рух, кеше, җәмгыять – материя тудырган; материалистлар билгеләвенчә,материя беренчел һәм үзе белән булган яшәешне гәүдәләндерә;

- ✔ Объектив-идеалистик ысул – материя беренчел идеалҗ (абсолют)рухның тудырган нәрсәсе ббуларак объектив бар була;
- ✔ Субъектив-идеалистик ысул – материя мөстәкыйлҗ чынбарлык буларак бөтенләй юк, ул тик субүектив (кеше аңында гына яшәүче) рухның продукты (феномен – бар кебек тоелган күренеш, «галлюцинация») она лишь продукт субъективного;
- ✔ Позитивистик - «материя» төшенчәсе ялган, чөнки аны фәнни тикшерү тәҗрибәсе белән дәлилләп булмый.

**Материя (материаль яшәеш)** (дәвамы)

***Материя төзелеше элементлары*** (дәвамы)

Материягә хас сыйфатлар

- Хәрәкәт барлыгы;
- Үз оешканлык;
- Пространство һәм вакыт эчендә урнашуы;
- Гәүдәләндерүгә сәләт.

Социум (җәмгыять)

Социум баскычлары

- Аерым индивид;
- Гаилә;
- Төркем;
- Төрле дәрәҗәдәге коллективлар;
- Социальные группы (классы, страты);
- Этнослар;
- Милләтләр;
- Расалар;
- Аерым җәмгыять;
- Дәүләтләр;
- Дәүләтләр берләшмәсе;
- Тулаем алганда кешелек.

Тере табигатҗ баскычлары

- Күзәнәккә кадәрге (ДНК, РНК, аксым);
- Күзәнәкле;
- күп күзәнәкле организмнар баскычы;
- Төрләр баскыч;
- Популяция баскычы;
- Биоценозлар;
- тулаем биосфера дәрәҗәсе.

## 2. Хәрәкәт

### Хәрәкәт - материянең аерылгысыз үзенчәлеге

#### Үзенчәлекләр

•материянең үзеннән барлыкка килә (аңа салынган капма-каршылыклардан, аларның берлегеннән һәм көрәшеннән)

• бөтенесен эченә алучан (барысы да хәрәкәт итә: атомнар һәм микрокисәкчәләр бер-берсеннән читәшәләр һәм тартылалар; тере организмнарның даими эше бара — йөрәк, ашкайнату системасы эшли, физик процесслар башкарыла; химик элементлар, тере организмнар хәрәкәт итә, елгалар хәрәкәт итә, табигатьтә әйбреләр әйләнеше бара, даими җәмгыять, Җир үсешә, башка күк җисемнәре үз күчәре һәм Кояш (йолдызлар) тирәли хәрәкәт итә; йолдыз системалары галактикада хәрәкәт итә, галактика - Галәмдә)

• даими (һәрвакыт бар; бер төрле хәрәкәт формасы туктавы яңа формалар барлыкка килү белән алыштырыла).

#### Хәрәкәт төрләре

• механик хәрәкәт

• физик хәрәкәт

• химик хәрәкәт

• биологик хәрәкәт

• социаль хәрәкәт

#### Хәрәкәт типлары

• сыйфатлы — материя нең үзен үзгәртү, эчке структураны үзгәртеп кору һәм яңа материаль объектлар һәм аларның яңа сыйфатлары барлыкка килү

• күләм, сан - материя һәм энергияне пространствода күчерү

Динамик хәрәкәт - иске форма кысаларында эчтәлек үзгәрүе, элекке материаль формаларның "потенциалын ачу«.

Популяцион хәрәкәт — объект структурасының кардиналь үзгәреше, ул тулысынча яңа объект барлыкка килүгә, материянең бер формасыннан икенчесенә күчүгә китерә. Популяцион хәрәкәт- үзгәрешләр эволюеион да, шул ук вакытта "эмерджменталь" да (бер нәрсә белән дә аңлатып булмаган «шартлау» юлы белән») барлыкка килә.

# 3. *Материянең үзоешканлык сәләте*

**Материянең үз оешканелыгы — тышкы көчләрдән башка үз-үзеңне тудыру, камилләштерү, үз-үзеңне җитештерү**

*флуктуация* — материягә даими хас очраклы чайкалу һәм тайпылу.

Синергетика – материянең үзоешканлыгы турындагы тәгълимат. Рус фәлсәфәчесе  И. Пригожин синергетика төп нигез салучысы.

диссипатив структура – материянең яңа тотрыксыз хәле, флуктуация нәтиҗәсендә барлыкка килә

Диссипатив структура үсеше вариантлары

"диссипатив структура" ныгый һәм ахыргача яңа төр материягә әйләнә, тик энтропия шартларында — тышкы мохиттәге энергия агымыннан —  һәм динамик типта үсешә башлый

"диссипатив структура« таркала һәм үлә- яки эчке көчсезлек нәтиҗәсендә, табигыйлек булмаганда, яңа элемтәләрнең ныклы булмавында, ягъни энтропия юклыганнан  — тышкы мохиттән килүче энергия

# 4. Материянең вакыт һәм пространствода урнаштырылуы

**Вакыт һәм пространстводагы урнаштырылуы**

*Мәсьәләгә якынаю юлы.*

*Субстанциональ* (Демокрит, Эпикур) — вакыт һәм пространствоны аерым чынбарлык итеп санаганнар, материя белән беррәттән мөстәкыйль субстанция, ә материя һәм пространство, вакыт арасындагы мөнәсәбәт субстанцияарабуларак караганнар.

*Реляцион* ( лат. Теленнән *relatio — мөнәсәбәт*) (Аристотель, Лейбниц, Гегель) — вакыт һәм пространствоны материаль объектлар үзара бәйләнешеннән барлыкка килгән мөнәсәбәтләр буларак кабул иткәннәр.

Төп положениеләр

- вакыт — материя яшәеше формасы, ул материаль объектларның озак яшәешен һәм үсеш процессында элеге объектларның эзмә-эзлекле үзгәрешләрен (халәте үзгәрүен) чагылдыра
- пространство — материя яшәеше формасы, ул материал объектлар эчендәге элементларның озынлыгын, төзелешенең үзара бәйләнешен  һәм материаль объектларның үзара бәйләнешен характерлый

Вакыт һәм пространство үзара тыгыз бәйләнгән. Пространствода булганнар, бер үк вакытта вакыт эчендә дә бара, вакытта барган, простаранствода була

Альберт Эйнштейнның (XX  гасыр уртасы) чагыштырмалылык теориясе. Әлеге теориягә ярашлы, пространство һәм и вакыт чагыштырмача, һәм алар материал җисемнәрнең үзара бәйләнеш шартларына бәйле чагыштырмача. Теория реляцион теориянең дөреслеген дәлилләде, ягъни вакыт һәм пространствоны материя эчендәге мөнәсәбәтләр буларак аңлыйлар, вакыт һәм пространствога мәңгелек, үзгәрешсез зурлык буларак элеккеге карашларны үзгәртте.

# 5. Материя үзенчәлеге буларак чагылыш

Чагылыш - способность материальных систем воспроизводить в самих себе свойства взаимодействующих с ними других материальных систем. Материальным доказательством отражения является наличие следов (одного материального объекта на другом материальном объекте) — следы человека на грунте, следы грунта на обуви человека, царапины, эхо, отражение предметов в зеркале, гладкой поверхности водоема.

Аң – чагылышның югары дәрәҗәсе (төр). Материалистик концепциягә ярашлы, аң — югары оешкан материянең чагылдыру сәләте ул.

Биологик

Биологик чагылыш стадияләре:
-бушандырылу
-сизгерлек
- Психик чагылыш

Механик

Химик

Физик

# 47нче сорау. Аң. Гомуми төшенчә,төп якынаю юллары, килеп чыгышы.

## *Фәлсәфәдә аң мәсьәләсендә төп якынаю юллары*

Аң: әлеге вакытта фәлсәфә чыннан да аң барлыгы һәм аерым, идеаль табигатьле (асыл) булы турында чыннан да дәлилли ала — әлеге по ложениене материалистлар да кабул итә, тик шул ук вакытта идеаль аң материядән җитештерелгән дип исәплиләр.

**Аң мәсьәләсенә якынаю юллары**

**Физикализм** — аң мәсьәләсенә чиктән тыш материалистик якын килү, аңа ярашлы, аң мөстәкыйль субстанция буларак юк, ул материя дәвамы гына һәм физика һәм башка табигый фәннәр карашыннан аңлатыла.

**Физикализм таянган фәнни фактлар.**

- кешенең баш мие чыннан да катлаулы табигать "механизмы« була,материя оешуның югары дәрәҗәсе
- конкрет кешенең аңы баш миеннән башка яши алмый, ә баш мие — биологик орган
- кешелек ясалма интеллект барлыкка китерү мөмкинлеге алды, аның иясе - машина (ком пьютер) — матди объект
- кеше организмына медикаментоз йогынты анда чагылырга мөмкин (мәсәлән, психотроп матдәләр куллану).

**Аңның идеальлеге физикалистларның логик дәлилләре барып төртелгән бердәнбер проблема.**

- кеше уенда яшәүче образларның материаль характеристикалары юк - масса, ис, төгәл үлчәме, формасы
## Үзенчәлекләр

- ✔Дьюи кешелек дөньясының тормышның барлык өлкәләрендә дә югары нәтиҗәләргә ирешүенә игътибар итә (аеруча фән һәм техникада — ягъни җитетерү өлкәсенә яңа фәнни методлар, “ югары технологияләр кертүгә бәйле фәнни-техник революция ясады)
- ✔ шул ук вакытта фәнни методлар да, югары технологияләр дә җәмгыять, әхлак, тәҗрибә белән идарә итүдә бөтенләй кулланылмый.
- ✔ Димәк, тәҗрибәне фәнни метод һәм югары технологияләрне файдаланып үзгәртеп була, әйтергә кирәк, бу фәнни метод һәм технологияләрне иң элек мәгарифкә кертергә кирәк (башлангыч, урта, югары) һәм мәгариф аша.

**Аңны камилләштерү** (шулай ук фәнни методлар нигезендә).

**Социаль яңартып төзү**

- милек мөнәсәбәтләрен камилләштерү, ул мөмкин кадәр кешеләргә милектән өлеш бүлеп бирү, милекчекләр арасында милекне ваклап бүлеп бирү, һәм аны җитештерү-хуҗалык максатларында максималь берләштерү (милекне акцияләштерү турында сүз бара);
- акционләштерү һәм милек мөнәсәбәтләренең башкача камилләштерү — кешене үз хезмәте нәтиҗәләренә якынайту, хезмәт нәтиҗәләренең бер өлешен үзләштерүче паразитар катламны киметү (эре ялгыз милекчеләр, эш бирүчеләр, монополистлар һ.б.);
- матди җитештерү байлыкларын гаделрәк бүлү;
- ярлылык белән көрәш, дәүләтнең даими рәвештә гражданнарның мул тормышын яхшырту турында хәстәрлек күрү;
- кеше хокукларын тәэмин итү һәм демократик дәүләт корылышын камилләштерү;
- җәмгыятьтә тәртип урнаштыру, кеше тормышының барлык өлкәләренңә һәм эшчәнлеге белән идарә итүне камилләштерү;
- эчке һәм халыкара конфликтларны йомшарту.

## *5. Дж. Дьюиның фәнни метод турындагы тәгълиматы*

**Дж. Дьюиның фәнни метод турындагы тәгълиматы**

***Төп положенияләр***

• метод — кеше тәҗрибәсе барышында белем алу һәм алынган белемне куллану тәртибе (процесс);

• фәннең һәм фәнни методның төп бурычы — кешенең үз максатлдарына оптималь ирешү;

• фәнни метод никадәр максатларга ирешүдә ярдәмләшүдән аның хак булуы тора; ягъни максатка ирешү барышында кулланылган метод, — хакыйкый (дөрес);ә максатка илҗтмәгән метод,яки аңа ирешүне катлауландырган метод, — ялган;

• димәк, фәнни метод кешенең уңышлы эшчәнлеге өчен, максатларга ирешү корал булып тора.

*Максатка ирешү чарасы буларак кулланылган метод* ***инструментализм дип атала***

Дьюди инструментализм һәм диалектика идеяләреннән ясаган нәтиҗәләр

• «гомумән методлар” булуы мөмкин түгел (я практик нәтиҗәгә юнәлтелмәгән методлар игътибарга лаек түгел);

• конкрет максатларга ирешү өчен конкрет методлар яшәп;

• димәк, методның конкрет эшләү тәртибен ачыкларга кирәк

Методның конкрет механизмын эзләү өчен
Д. Дьюи проблемалы ситуация һәм аны хәл итү юллары турындагы тәгълиматны тәкъдим итә

***Тәгълимат асылы***

• методка ихтыяҗ (тәҗрибә буларак) киләчәк хәрәкәтләргә комачаулаучы актуаль шикләнү булганда барлыкка килә;

• әлеге актуаль шикләнү «проблемалы ситуацияне" тудыра — конкрет (теләсә нинди) тормыш ситуациясен, аларны конкрет адымнар ярдәмендә хәл итәргә кирәк;

• проблемалы ситуацияне хәл итү еш кына альтернативалар сайлауга бәйле (карaралада һәм гамәлләрдә;

• фәнни метод максаты — проблемалы ситуацияне хәл ителгән ситуациягә әйләндерү;

• фәнни метод проблемалы ситуацияне хәл итү барышындагы процесс вакытында гамәлгә ашырыла;

• димәк, фәнни метод (аның конкрет гамәлне гәүдәләндерүендә) проблемалы ситуацияне хәл ителгән ситуациягә әйләндергән вакыттагы адымнар ул.

***Конкрет адымнар (проблемалы ситуацияне хәл ителгәнгә әйләндерү этаплары)***

• кыенлыклар, каршылыкларга очрау тойгысы (гадәттә шомлы, ажлатып булмый торган) — әлеге очракта кирәк: бу шомның чыганагын ачыклау; проблемага төшенү; проблема нидән гыйбарәт булуын ачык билгеләү;

• булган проблема анык итеп билгеләнгәч, билгесез ситуация проблемалыга әйверелә; бу этапта кирәк: ахыргы максатны анык куярга; мөмкин булган кыенлыкларны аңлап-төшенү;

• гипотеза тәкъдим итү (эш-хәрәкәтләрнең эзмә-эзлелеген хәл итү), бу проблеманы хәл итүгә, проблемалы ситуацияне юкка чыгаруга китерәчәк;

• гипотезага тәнкыйди анализ; куелган максатны хәл итүнең һәр этабында гипотеза гамәлләрен теоретик модельләштерү (тәҗрибәгә нигезләнгән алдан күзаллау);

• ахыргы карараны кабул итү, модельләштерелгән гипотезаны тормышка ашыру, проблемалы ситуацияне хәл итү, кулланылган гипотезаны тәҗрибш ярдәмендә дөреслеген (нәтиҗәгә ирешкән очракта) яки ялган булуын (нәтиҗәгә ирешә алмаганеда) тикшереп карау. .

Д. Дьюи **фәнни методка туры килергә тиешле билгеләрне** бүлеп чыгара

- үзлегеннән төзәтү мөмкинлеге (яңа алынган тәбрибәдән чыгып, уңайдан да, тискәредән дә);
- хәрәкәт итү сәләте (кулланылган фәнни метод әйләнә-тирә чынбарлыкны гына чагылдырырга тиеш түгел, теләсә нинди ситуациядә хәрәкәт итергә тиеш);
- дөреслек (максатка китергән методлар гына дөрес һәм киләчәктә кулланугa лаеклы).

*6. Дж. Дьюи гносеологиясе. Танып белүдәге идеализм һәм материализм проблемасы.*



Кешеләрнең тарихи хезмәте түбән физик эшчәнлек һәм югары рухига бүленүгә бәйле булуга нигезләнеп, ике төрле дөньяга караш (һәм танып белү)яшәп килә

***Материалистик***

***Идеологик***

***Үзенчәлекләр***

- Материализм һәм идеализм арасындагы бәхәс (дөньяга караш, танып белү ысулы белән) хезмәтнең тупас физик эшчәнлек һәм югары рухига бүленгән вакытта актуаль булган һәм яшәгән;
- физик һәм акыл хезмәте арасындагы кырлар югала барган саен, алар якынайган саен материализм һәм идеализм арасындагы конфликт кими бара, аралар шомара;
- Киләчәктә, Дьюи буенча, акыл хезмәте физик эш белән кушылган чакта, аларның чиктләре югалачак, материалзим һәм идеализм арасындагы конфликт та юкка чыгачак.
- Нәкъ акыл хезмәте җиңеп чыкканга, физик эшне йотканга күрә (ә киресенчә түгел) һәм ахыр чиктә җиңүгә ирешкәнгә, идеализм материализмны ахыргача җиңәчәк һәм төп дөньяга караш һәм танып белү ысулына әйләнәчәк;
- Әлегә атап әйтелгән процесс булмады,шуңа да идеалистик та һәм материалистик та танып белү ысулларын кулланырга кирәк, тик югары акыл эшчзнлеге тора-бара тупас физик хезмәтне кысрыклап чыгарганга күрә, ике төр танып белү ысулын кулланып (идеалистик та, материалистик та), идеалистикка авышырга кирәк.

Дж. Дьюи фәнни метод теориясе һәм проблемалы ситуация турындагы тәгълиматны төзегәндә ясаган ачыш

- дөрес белем һәм фәнни методны дөрес куллану проблемалы ситуацияне хәл ителгәнгә әйләндергәнгә күрә, бу яңа ситуация бөтенләү башка сыйфатка ия була;

- Димәк, танып белү **танып белү объектының сыйфат ягыннан үзгәрүенә китерә,** танып белү танып белү предметының гомумән булмышын үзгәртә.

## 7. Дж. Дьюиның социаль фәлсәфәсе. Әхлак проблемасы.

Дж. Дьюи иҗатында социаль фәлсәфә һәм әхлак проблемасы

***Төп положениеләр***

• кешелек дөньясы омтылырга тиешле бердәнбер «югары байлык-игелекләр» юк;
• максатлар һәм байлыклар плюрализмы бар;
•максатлар һәм байлыклар абстракт була алмый, алар конкрет;
• төп байлык-игелекләр – сәламәтлек, байлык, намус, яхшы исем, дуслык, җәмгыять ягыннан югары бәя, укымышлылык, гаделлек, уртачалык, киң күңеллелек;
• күпчелек кешеләр әйтелгән игелекләргә омтыла, өстәвенә гомумән игелекләргә түгел, ә аларның конкрет үлчәменә;
• теләсә кайсы игелкккә ирешү ул тәҗрибә үзгәрүе сыйфатында була;
• димәк, барлык очракта да үсеш үзе төп әлакый максат була;
• әхлакый дини кануннар (үтермә, урлама һ.б.лар) абсолют характерга ия түгел (мәсәлән, сугышта дошманга карата) һәм конкрет аерым бер очракта гадел (яки гадел түгел);
• демократия кешелек гомумяшәешенең оптималь формасы булып тора;
• «максат чараларны аклый" лозунгы үзенең асылды белән дөрес түгел һәм кире кагылырга тиеш;
• максатлар чараларга тәңгәл килергә тиеш, ә чаралар - максатларга; начар чаралар куллану мотлак рәвештә максатның сыйфат ягыннан үзгәрүенә китерәчәк (максатлар чараларга тәңгәлләшүгә китереләчәк);
• демократия көчләү, сугышлардан баш тартырга һәм тынычлык чараларын гына кулланырга тиеш(бу барлык кешелеккә дә кагыла);
• җәмгыять социаль каршылкларны, социаль төзеп коруларны тигезләүгә мохтаҗ;
• социаль төзеп коруларның төп этәргече - фәнни методлар һәм мәгариф һәм әхлакта югары технологияләр куллану.

# 61нче сорау. Психоанализ

## *1. Психоанализга гомуми төшенчә.*

**Психоанализ** — аңсыз эшләнгәннең ролен, кеше һәм җәмгыять тормышындагы башка психик процессларны аңлатучы хәзерге фәлсәфә юнәлеше.

Психоанализга нигез салучы итеп австрия галиме - психиатр **Зигмунд Фрейд** (1856 - 1939) исәпләнә.

**3.Фрейд ясаган төп ачышлар**

**Аңсыз эшләнелгән** — һәр кешегә хас булган махсус үзгә психик чынбарлык, аң белән янәш бара һәм күпчелек дәрәҗәдә аңны контрольдә тота;

Аңсыз эшләнгәннең аерым бер яшәеш формасы — төшләр. Фрейд буенча, төшләр — бу кешенең яшерен омтылышларын тормышка ашыру, реаль чынбарлыкта тормышка ашырылмаганнар.

**Этщреп чыгару реакциясе** (аңлыдан аңсыз эшләнгәнгә) тискәре тойгылар, тискәре тәҗрибә, ягъни психик саклану ысулы буларак, тигезлек һәм психик сәламтлекне бозучы барлык нәрсәләр.

Тискәре тойгылар, тормышка ашмаган теләкләр — аңсыз эшләнгәнгә этеп чыгарылган барлык нәрсә, «очраклы», «тиз, эчке сәбәпләр аркасында туган» хәрәкәт, гамәлләр, ялгыш сүз, язудагы хата, «мәзәклекләр» рәвешендә иртәме, соңмы үзен сиздерә.

## *2. Фрейд тәкъдим иткән психиканың топографик һәм динамик схемалары*

**Психиканың топографик схемасы**

**Үзенчәлекләр**

- Аңсыз эшләнгәннәр үзе белән зур коридорны хәтерләтә, биредә кешенең төрле уйлары, теләкләре, тойгылары үз сәгатен көтеп тора.
- Аң — зур булмаган кабинет, бирегә даими рәвештә килүчеләр “чакырыла”: кешенең уйлары һәм теләкләре.
- Алгы бүлмә һәм кабинет арасында сакчы тора, ул аңга бары тик аңа яраклы уйларны гына кертә.
- Кайвакыт сакчы китә, йоклый, һәм «яраксыз килүчеләр» кабинетка – аңга үтеп керә ала.
- Әмма аннары алар кабат йокыдан уянучы сакчы тарафыннан алгы бүлмәгә чыгарыла.

**Психиканың динамик схемасы**

психика өч катлам буларак тәкъдим ителә –Ул(**Оно), Мин, Чиктән тыш - Мин.**

- «Ул" — аңсыз эшләнелгән дөньясы, биредә кешенең уйлары һәм теләкләре була.
- «Мин" – кеше аңы, психиканың бар компонетлары арасындагы арадашчы.
- «Чиктән тыш-Мин" — шәхескә басым һәм йогынты ясаучы тышкы чынбарлык,
- «тышкы цензура": законнар, тыюлар, әхлак, мәдәни традицияләр.

**Үзенчәлекләр**

- «Мин» үзенә «Ул»ны буйсындырырга тырыша. Моны бик сирәк эшләп була. Гадәттә «Ул» яшерен яки ачык формада «мин»не үзенә буйсындыра.
- Фрейд «Мин»не җайдак 1әм ат белән чагыштыра: җайдак («Мин") беренче карашка атны контрольдә тота, аңа әмерләр бирә, тик ат («Ул") — җайдактан көчлерәк һәм чынбарлыкта җайдакны үзендә алып бара. Кайчак җайдак бөтенләйконтрольне югалта һәм ат белән бергә чабарга, ул кайда алып бара, шунда барырга мәҗбүр була.
- . Шулай ук «Чамадан тыш-Мин" — нормалар һәм тыюлар – еш кына «Мин»не буйсындыра.

**Кеше «Мин«е (Фрейд буенча - «бәхетсез кеше Мине) өч яктан көчле басым тоя*:***

- Аңсыз эшләнгәннәр - «Ул";
- тышкы дөнья;
- нормалар, тыюлар - «Чиктән тыш -Мин";

## *3. Психиканың нигез факторлары*

**Кешенең психикасы белән идарә итүче һәм юнәлтүче төп факторлар**

• **рәхәтлек** — психика компаска охшаган, болй яки тегеләй рәхәтлек юлларын эзли;
• **кысрыклау** — психика тыю салынган теләк һәм идеяләрне (җәмгыятькә каршыларны, сексуаль) аңсыз эшләнгәннәргә кысрыклап чыгара.

**Аңсыз эшләнелгәннәргә этеп чыгарылган, "цензура«ны үтмәгән теләкләр, фикерләр сублимациягә дучар була — башка «рөхсәт ителгән» социаль эшчәнлек һәм мәдәни иҗат төрләренә әйләндерелә.**

## *4. Фрейдның беренче һәм икенче психологик системалары.*

**Беренче психологик системага ярашлы, аңсыз эшләнгәннәр нигезендә "либидо« ята — сексуаль омтылыш, сексуаль инстинкт**

***Либидо үзен түбәндәгеләрдә эзли:***

- сексуаль гамәлләрдә;
- тормышның башка өлкәләрендә сексуаль энергиянең сублимация (үзгәрешләр) аша сексуаль булмаганга.

***Сексуаль импульс,* Фрейд буенча, өч төрле тормышка ашырыла ала:**

- ✔ турыдан-туры ясалган хәрәкәт аша (сексуаль, я сексуаль булмаган) «иреккә чыгарыла";
- ✔ Аңсыз эшләнгәннәргә этеп чыгарыла;
- ✔ боеккан, реактив төшенчәләр аша (оят, әхлак) энергиядән ваз чиктерелә.

*Кешенең психик эшчәнлеге ул аның сексуаль инстинкт үзгәреш процессы. Әлеге теория Европада ризасызлык тудыра.*

**ХХ гасрының 20нче елларында Фрейд икенче психологик система уйлап чыгара, биредә ул аңсыз башкарылганнарның энергиясе барлыкка килү проблемасына яңача карый.**

**Үзәк төшенчәләр һәм системаның асылы:**

- Кешенең конструктив тәртибе, тудыру нигезендә **Эрос (тормыш инстинкты)** ята. Аңа бәйле кеше үзенең ихтыяҗларын тәэмин итә һәм нәселен дәвам итә.
- **Танатос (үлем инстинкты)** кешене деструктив эшчәнлеккә этәрә, аңа «ят» һәм хәвефле тоелганнарның барын да җимертә.
- Кеше тормышы — Эрос һәм Танатосның даими үзара бәйләнеше.

## 5.Кеше мөнәсәбәтләре, кеше массалары, мәдәният проблемалары

Фрейд **кеше мөнәсәбәтләренә, кеше массалары, мәдәният мәсьәләләренә** аерым игътибар булә.

**Үзенчәлекләр:**

❖Фрейдка ярашлы, кешелек җәмгыяте бары тик аңсыз башкарылган гадәтләр, теләк-омтылышлар, дәртне үзара бастыру шарты булганда гына яши ала, югыйсә җәмгыять эчтән җимереләчәк.

❖Бастырылган энергияне **масса-күләм сублимацияләү** һәм аның мәдәнияткә әйләнүе бара.

❖Җәмгыять бастырылган энергиянең алмаштыргычын ритуалларны тудыра.

❖ **Ритуал** — коллектив аңсыә башкарылганнар — этеп чыгарылган теләкләрне тормышка ашыру формасы. Ритуаллар шактый күп – дин, әхлак, сәнгать, шигърият, музыка, тамаша, масса-күләм чаралар.

**Фрейд эшләгән нәтиҗәләр:**

❖ цивилизация үскән саен кеше дәрте ныграк бастырыла бара.

❖Бу масса-күләп психозга, гомум халык депрессиясенә (төшенкелеккә) китерә;

❖һәм тагы да катлдаулырак, үткен ритуаллар төзү кирәклегенә китерә.

## 6. Масса (халык төркеме) феномены.

**Халык төркеме(масса) феномены**

**Феномен асылы:**

✓Бастырылган теләкле шактый кеше массага, төркемгә оеша һәм үз энергиясен лидерга (җитәкчегә) юнәлдерә. Төркемнең һәр әгъзасын, тулаем массаны, төркем лидерын тиңләштерү процессы бара.

✓Төркемнең(халыкның) һәр әгъзасы автоматик рәвештә үзенә лидер (башлык) сыйфатларын, ә башлык (лидер) үзенә масса сыйфатын күчереп ала.

✓Кешеләрнең массага берләшүе, лидер белән тиләштерелүе “аңсыз” халык өерендә кыйммәтләр, көч (төркемгә һәм лидерга бәйле булу аркасында), хәвефсезлекнең үзен юкка чыгаруга булышлык итә.

✓Халык өере агрессив, җиңел кабызып җибәрелүчән, кискен, аяусыз.

✓Халык төркеме лидерының ролен, Фрейд буенча, бары тик ачык психик аномалияле, үзенең үзенчәлекле булуына үзе дә ышанган һәм үзе артыннан халыкны алып барырга сәләтле шәхес кенә башкарып чыга ала.

# 7. Основные направления неофрейдизма

**Фрейд тәгълиматы нигезендә аның дәвамчылары - Альфред Адлер, Вильгельм Райх, Густав Юнг, Эрих Фромм эшкәртеп чыгарган неофрейдизм фәлсәфи агымы барлыкка килә.**

**Г. Маркузе (1898 - 1979) теориясе (маркузианлык)**

**Теория асылы**

- Маркузеның төп әсәре — "Одномерный Человек« («Бер үлчәмле Кеше»). Аның асылы заман «бер үлчәмле җәмгыять»нең нормаль, әмма “бер үлчәмле”, тик бер юнәлештә-куллану кысаларында гына теләк, кызыксынулар, мавыгуларга ия булган кеше тәрбияләүдә.
- Кулланучы – кеше тора-бара «шөреп”кә, җәмгыятькә бәйлегә әйләнә, шәхес буларак баклана, үзенең табигый теләкләрен баса, ягъни үзен-үзе баса.
- Әлеге хәлдән чыгуны, бер үлчәмле җәмгыятьне “ерып чыгуны” Маркузе тулысынча сексуаль азатлыкта һәм иркенлектә, сексуаль революөиядә күрә.

**Эрих Фроммның кеше яшәешенең каршылыклы булуы проблемасы**

**Каршылыклар нигезе**

- патриархат һәм матриархат;
- Гуманистик һәм авторитар аң;
- власть һәм буйсыну;
- Ия булырга омтылу һәм гади генә яшәү
- Шәхси яшәеш (тормыш тарихы) һәм тарихи яшәеш (тарих);
- “фәләннән азат булу” һәм “фәлән өчен азат булу”- негатив һәм позитив азатлык;

- Фәлсәфә максаты – бу каршылыкларны гомум мәхәббәт тарату ярдәмендә хәл итү, «яшәү теләге» «үлү теләге»н этәреп чыккан чакта.

**Карл Густав Юнг (1875 - 1961) теориясе**

Теория асылы

- Юнг буенча,кешенең тормыш (сексуаль генә түгел)энергиясе, тормыш каршылыкларына очрап, индивидуаль аңсызлыкка түгел, ә архетиплар рәвешендәге гомуми аңсызлыкка күчерелә;
- **архетиплар** — универсаль образлар, гомумкеше этеп чыгарылган тормыш энергиясе «код»ы. Алар күргән төшләр эчтәлеге, акылына зыян килгән авырулар саташуы, парапсихологик эффектлар, хыяллар, галлюцинация-саташулар булырга мөмкин. Архетиплар — кешелекнең "шифрланган" тарихы;
- Фәлсәфә максаты - кешегә архетипларны «чишәргә», аларның мәгънәсен, ә алар аша — үзеңне һәм әйләнә-тирә чынбарлыкны аңларга ярдәм итү.

**Альфред Адлер (1870-1937) теориясе**

Теория асылы

- Кешенең “бөек” гамәлләре, чамадан тыш активлыгы, артык омтылучанлыгы нигезендә, шулай ук психик чирләрендә кимчелеклелек комплексы ята
- Кеше бизнеста, сәясәттә, фәндә, сәнгатьтә, шәхси тормышта уңышка ирешеп, компенсацияләргә тели.

**Вильгельм Райхның фрейд-марксизмы (1897 - 1957)**

# Теория асылы

- Кешенең нормаль яшәве һәм эшчәнлеге нигезендә космик табигатьле сексуаль энергия ята.
- Җәмгыять кеше энергиясен котылгысыз рәвештә баса, аның аффектлары мораль, мәдәният, этикет ярдәмендә.
- Кеше мәдәният кысаларында яшәүгә дучар ителә, гомум яшәеш нормаларына, башка кешеләргә ияләшергә, начальствога, властка буйсынырга тиеш — бу кешенең нервалы хәленә китерә, аның чын “Мин”е, мөстәкыйльлекнең үлүгә китерә.
- Кешене бердәнбер коткару чарасы — мәдәниятнең абруен тулысынча төшерү (мораль, тыюлар, субординация), иркен тоту**, сексуаль революция.**

# 62нче сорау. Хәзерге теологик фәлсәфә.

## *1. Теологик фәлсәфәгә гомуми төшенчә*

**Теологик мәктәп**

**Каралган сораулар**

- ✔Барлык яшәешне булдыручы буларак Алла барлыгы;
- ✔Аның иң югары иҗат җимеше буларак кеше яшәеше, кеше тормышы

**Хәзерге теологик фәлсәфәнең үзенчәлекләре**

- ✔технологическая философия стала ближе к человеку;
- ✔ байтак догмнардан азат булды;
- ✔ социаль гармонигә, әхдак, әдәпкә, халыклар арасындагы татулыкка зур игътибар бүлә башлады.

## 2. Неотомизм

**Хәзерге теологик фәлсәфәнең иң абруйлы агымы — неотомизм. Аның күренекле вәкилләре - Э. Жильсон (1884 - 1978), Ж. Маритэн (1882 - 1973), Ю. Бохельский (1902 елда туган), Е. Корет ( 1919 елда туган), К. Ранер (1904 - 1984), Ф. ван Стенберген (1904 елда туган), К. Войтыла (әлеге Рим папасы Иоанн Павел II, 1920 елда туган).**

**Үзенчәлекләр**

- ✔Неотомизм нигезе — Фома Аквинский тәгълиматы. Үзәк принцип — ышану һәм акыл гармониясе.
- ✔Хәзерге неотомистлар материя һәм идея арасындагы каршылыклар,гностицизм һәм агностицизм, эмпиристик һәм рациональ танып белү формасы өстеннән күтәрелергә омтылалар,
- ✔Рим папасы Иоанн Павел II(К. Войтыла) католиклар Чиркәве үткәннәр хаталарын танып, шул исәптән, индульгенция тарату, инквизиция учаклары, фәнне әзерлекләәүләралар өчен гафу үтенергә тиеш дигән идея тәкъдим итә.

| Неотомистлар максаты | Тәгълиматның төп өлешләре | Төп идеяләре |
|---|---|---|
| ✔Католицизм һәм католиклар фәлсәфәсенең дөреслеген, хак булуын дәлилләү; | ✔общая метафизика, состоящая, в свою очередь, из онтологии (учения о бытии) и природной теологии (философского учения о Боге); | ✔креационизм (әйләнә-тирә дөньяның Алла тарафыннан яратылуы); |
| ✔Католицизмны хәзерге шартларга яраклаштыру; | ✔ кулланма метафизика — әйләнә-тирә дөнья һәм кеше турындагы тәгълимат; | ✔ачыш (үзендәге Алланы — Инҗилдә (Библиядә)); |
| ✔Католицизмны гади кешеләргә якынайту. | ✔гносеология; | ✔Асыл һәм яшәешне бүлеп карау (эссенцияләр һәм экзистенцияләр); |
| | ✔натурфилософия | ✔Асыл һәм Алладагы яшәеш берлеге; |
| | | ✔Кешенең Аллага охшашлыгы; |
| | | ✔кеше — материаль һәм рухи субстанцияләр берлеге. Неотомизм җәмгыятькә, кыйммәтләргә, әхлаккә аеруча игътибар бүлә. |

# 3. Хәзерге технологик фәлсәфәнең башка юнәлешләре

**Хәзерге теологик фәлсәфә юнәлешләре**

**Тейярдизм**

- ✔Хәзерге теологик фәлсәфәгә нигез салучы — Пьер Тейяр де Шарден (1881 - 1955).
- ✔Тейяра де Шарденның максаты: феноменология — үзендә фән казанышларын һәм теологик фәлсәфәне берләштергән, Галәм нигезләрен аңлатып биргән комплексы фән төзү.
- ✔Тейяр де Шарден фәлсәфәсенең мөһим принциплары— эволюционизм, аңа ярашлы, дөньядагы һәрнәрсәгә (тере, ьансыз табигатькә) эволюция хас.
- ✔Үзенең юнәлеше буенча тейярдизм теологик фәлсәфәсендә *реформатор агымы була*, күпчелек табигый фәннәр казанышларына таяна, католицизмның күп кенә догмаларын тәнкыйтьли.

**Азат булу теологиясе**

**Үзенчәлекләр**

- төп идея — кешенең мөмкин кадәр үзен иркен тотышы
- Латин Америкасында киң таралыш ала.

**Теологи к фәлсәфәнең протестант юнәлеше**

- либераль теология (Шлейермахер, Гарнап, Трельч)
- Кризис теологиясе (Барт, Нибур);
- экзистенциональ теология (Тиллих);
- "демифоногизацияләнгән христианлык" (Бультман);
- динсез христианлык — Больхьоферра. Бу тәгълиматларның төп идеяләре исемнәрендә үк салынган.

63нче сорау. Хәзерге позитивизм фәлсәфәсенең төп юнәлешләре

*1. Позитивизмның төп төшенчәләре һәм төп үсеш этаплары*

**Позитивизм —XIX гасырның 30-40нчы елларында барлыкка килгән фәлсәфә юнәлеше (Огюст Конт,1798 — 1857).**

**Теория асылы**

- Фәлсәфә фәнни сыйфатлардан азат ителергә һәм ышанычлы фәнни белемгә генә таянырга тиеш.
- Позитивистлар фикеренчә, фәлсәфә тик фактларны гына өйрәнергә тиеш(ә аларның эчке асылын түгел), барлык бәяләүдән бушанырга, тикшеренүләрдә нәкъ фәнни чараларга таянып эш итәргә (теләсә кайсы башка фән кебек үк), фәнни методка таянырга.

**Позитивизмның төп үсеш баскычлары**

- классик позитивизм (О. Конт һәм Г. Спенсер);
- махизм;
- неопозитивизм;
- неопозитивизм;

## 2. *Махизмның гомуми төшенчәләре һәм төп проблемалары*

**Махизмны еш кына «позитивизмның икенче формасы» дип атыйлар. Аны Э. Мах (1836 — 1916) һәм Р. Авенариус барлыкка китерүче дип исәпләнелә.**

### Төп идеяләр

- позитивизм". Аны Э. Мах (1836 — 1916) һәм Р. Авенариус барлыкка китерүче дип санала. Махизмның төп идеясе — фәлсәфә нигезендә тәнкыйди тәбрибә ятарга тиеш (моңа бәйле бу юнәлешнең икенче исеме дә бар — эмпириокритицизм).
- эмпириокритицизм субъектив-идеаллистик позициядән чыгыш ясый: әйләнә-тирә дөньяның барлык предметлары, күренешләрекешегә «тойгы-сиземләү җыелмасы" буларак күз алдына килә.
- Димәк, әйләнә-тирәне өйрәнү кеше тойгы-сизүләрен тәҗрибә ярдәмендә тикшерү буларак кына мөмкин
- Кеше тойгы-хисләре барлык фәннәрдә булганга күрә, фәлсәфә булырга тиешле: беренчедән, интегратив, «гомуми» фән булырга
- икенчедән, кеше тойгы-сиземләве турында ышанычлы фән булырга, абстракт фәнни төшенчәләрне тойгы-сиземләү теленеә күчерергә (мәсәлән, масса, үлчәм үзеннән-үзе генә яшәми, ә кеше масса һәм үлчәм белән тойган-сиземләгән төшенчәләр бар).

### Үзенчәлекләр

**Үзенең субъектив идеализмы булганга күрә эмпириокритицизм позитивизмның үз принциплары белән өлешләтә аерыла, моңа бәйле ул киң таралыш алмады.**

# 3. Неопозитивизмның гомуми төшенчәләре һәм төп проблемалары

***Неопозитивизм (XX гасырның беренче яртысында һәм уртасында популяр була һәм киң таралыш ала)***

**Төп вәкилләре**

- **"Вена түгәрәге « фәлсәфәчеләре (М. Шлик - нигез салучы; аның дәвамчылары - Р. Карнап, О. Нейрат, Г. Рейехенбах);**
- **Львов-Варшава мәктәбе вәкилләре (А. Тарский, Я. Лукасевич);**
- **Б. Рассел (1872 - 1970);**
- **Л.Витгенштейн (1889 - 1951).**

**Төп идеяләре**

- неопозитивизмның төп идеясе — фәлсәфә фән теленең логик анализы белән шөгыльләнергә тиеш, чөнки тел, фән теле кебек үк, — кеше әйләнә-тирә дөньяны позитив (ышанычлы, фәнни) кабул итә алырдай төп чара.
- Фәлсәфә текст, билге, төшенчә, билге системаларының эчке элемтәләрен, билгеләрдәге семантиканы (мәгънә) логик анализлау белән шөгыльәнергә тиеш (бу аны герменевтика белән якынайта).
- Неопозитивизмның төп принцибы — верификация принцибы — фәннең барлык положениеләрен тәҗрибә фактлары белән чагыштыру. Положение, төшенчә бары тик шунда гына мәгънәгә ияики, кайчан фән өчен кызыклы, кайчан верификацияләп була — фактлар ярдәмендә тәҗрибәле тикшерүгә дучар итү.
- Элеккеге фәлсәфәнең күпчелек проблемалары (яшәеш, аң, идея, Алла) — верификациягә **ярамый**, ә димәк, бу проблемалар псевдо проблемалар була, ышанычлы фәнни рөхсәте булмаган. Алар фәлсәфәдән алып ташланырга тиешле.
- Неопозитивизмның башка төп максаты (фән теленә логик анализ ясаудан тыш) фәлсәфәне метафизик (ышанычлы фәнни хәл итәлә алмаучы) проблемалардан азат итү.

# 4. Постпозитивизмның гомуми төшенчәсе һәм төп проблемалары

Потивизмның яңа варианты **постпозитивизм булды** (XX гасырның икенче яртысы һәм ахыры.).Аның төп вәкилләре итеп К. Поппер (1902 — 1994), Т. Кун (1992 елда туган) санала.

## Үзенчәлекләре

- ✔постпозитивизм символларны (тел, фәнни аппарат) беренчел логик тикшерүдән читкә китә һәм фән тарихына мөрәҗәгать итә.
- ✔**постпозитивизмның төп максаты** — *фәнни белемнең (тел, төшенчәләрнең) төзелешен (неопозитивистлар кебек) түгел, ә фәнни белем үсешен тикшерү.*
- ✔постпозитивизм фәлсәфәгә тулаем алганда, танып белү проблемаларына карата үз мөнәсәбәтен йомшарта.
- ✔постпозитивистлар фикеренчә,фән мәгънәсе һәм фән теле арасындагы катгый каршылык булмаган кебек үк, теориянең дөреслеге һәм аның верификацияләнүе (тәҗрибәне фактлар белән тикшерү мөмкинлеге) арасында бернинди дә мәҗбүри үзара бәйлелек юк, шулай ук верификациләнмәгән проблемаларны (метафизик, фәнни булмаганнарны) фәлсәфәдән алып ташларга кирәк димәгән.
- ✔фән үсешенә килгәндә, постпозитивистлар фикеренчә, фән җитди линия буенча үсми, ә сикереп-сикереп, бер менеп китә, бер төшә, әмма гомум тенденция үсеш һәм фәнни белемне камилләштерүгә юнәлдерелгән.

## Постпозитивистларны кызыксындырган төп мәсьәләләр

- ✔Яңа теория ничек барлыкка килә?
- ✔Ул ничек танылу ала?
- ✔Фәнни теорияләрнең, шул исәптән туган һәм конкурент булган, критерийларын чагыштыру ничегрәк?
- ✔ Тарафдарлар арасында альтернатив теорияне аңлау мөмкинме?

## Хәзерге заман постпозитивизмның төп проблемалары

- ✔проблеманы фальсификацияләү (бозып күрсәтү) (берничә ялган яки дөрем булмаган фактны тапканнан соң фәнни теориядән тулаем баш тартырга кирәкме икән);
- ✔фәнни теорияләрнең дөреслеге проблемасы (фәнни теорияләрнең дөреслеген нинди критерияләр буенча тикшерү);
- ✔ Рациональлек проблемасы (нәрсә ул фәндәге рациональлелек);
- ✔фәнни теорияләрнең үлчәнешлелек проблемасы (фәнни теорияләрдә нинди критерийлар буенча аларның туганлыгын, үлчәнешлелеген ачыкларга кирәк);
- ✔антагонистик теория вәкилләренең уртак караш ноктаkаларын табу, аңлау проблемасы.

# 64нче сорау.Герменевтика

## *1. Герменевтиканың төп төшенчәләре*

**Герменевтика** - аңлату, инерпретация, төшенү теориясе һәм гамәлен тикшергән фәлсәфә юнәлеше. Үзенең атамасын алла һәм кешеләр арасындагы арадашчы булган борынгы грек алласы Гермеска бәйле алган – аллара ихтыярын кешеләргә һәм кешеләр теләгeн аллаларга җиткергән.

**Төп принциплар**

- ✔Герменевтиканың төп идеясе: бар булу - аңлашылган булу.
- ✔тикшеру предметы, гадәттә, текст була.
- ✔Герменевтика герменевтик ситуацияләр барлыкка килү белән туа - текстны дөрес төшену һәм дөрес аңлатып бирү кирәк булган очракларда

**Герменевтиканың төп мәсьәләләре**

- ✔ Аңлау ничек мөмкин?
- ✔аңлау эчендә яткан яшәеш, асыл нәрсәдән гыйбарәт.

**Нигез төшенчәләр**

- ✔"герменевтик өчпочмак" - текст авторы, текстның үзе һәм укучы арасындагы үзара мөнәсәбәт
- ✔"герменевтик боҗра" — танып белү процессының цикллы характеры.

## *2.Герменевтиканың мөһим вәкилләренең төп идея эчтәлеге*

**Герменевтиканың төп вәкилләренең төп фәлсәфи юнәлешләре**

Беренче герменевтлар эшләре → Урта гасыр теолог-схоластлары (Фома Аквинский һ.б.лар), алар Инҗил (Библия) текстына салынган илаһи идея мәгънәсен “чишү” белән шөгыльләнәләр.

Ф.Шлейермахер (1768-1834) теориясе

**Төп положениеләр**

- ✔ **Шлейермахерга ярашлы, текстны аңлатып бирү барышында ике төрле метод** — грамматик һәм психологик кулланыла. Беренчесе ярдәмендә «тел рухы» ачыклана, икенчесе ярдәмендә «автор рухы».
- ✔герменевтика (текстны аңлатып бирү) автор рухы һәм укучы рухы тугандаш кына булганда мәгънәгә ия. Әгәр дә автор укучыдан бик ерак икән, текст герменевтиканың барлык тырышлыгын салсаң да, ул беркайчан да ахыргача аңлашылган булмаячак һәм автор һәм укучы бер-берсенә охшаш икән, текстта бернинди дә яшерен мәгънә калмаячак, һәм ул аңлатуга мохтаж булмаячак.
- ✔аңлауга ике юл ярдәмендә ирешелә: беренчедән, дивинация — әсәр авторы рухы белән ясалма рәвештә берләшү;
- ✔икенчедән, чагыштырулар — фактларны һәм башка мәгълүматны чагыштыру.
- ✔дивинацияләү чагыштыру белән чиратлашырга тиеш һәм киресенчә. Укучы ахыргача тел тәртибен, автор рухына төшенгәч, текст тулысынча аңлашылачак.

Герменевтиканың төп вәкилләренең мөһим фәлсәфи юнәлешләре (дәвамы)

## М.Хайдеггерның (1889-1976) экзистенциаллар турындагы тәгълиматы

**Үзенчәлекләр**

✔взгляды раннего яшь **Хайдеггернең** карашлары үзендә герменевтика һәм экзистенциализмны берләштерә һәм герменевтиканың яшәеш (онтологик), ә танып белү (гносеологик) ягына багышланган

✔кеше яшәеше, Хайдеггер буенча, баштан ук *герменевтикалы* (аңлауга нигезләнгән).

**Экзистенциаллар** - кешенең яшәү шартлары

✔*салынганлык* — кеше яшәеше фикерләү белән түгел, ә аның дөньяда булу факты белән билгеләнә, (кеше иң элек «салынган» , ягъни ул бар, ә аннары гына фикерли);

✔*аңлау* — кеше үзенең аңлый башлавын ачыклый, ә аңлау — аңлату һәм төшендерү ул (кеше үзенең дөньядагы яшәешен билгеле бер образда аңлатып бирә, һәм бу аңлатма үзенең яшәү мәгънәсен, үзенең бу тормыштагы урынын аңлау дип кабул итеп була.

## Ганса Гадамер (1900 елда туган) теориясе

**Төп положениеләр**

✔**Ганс Гадамер** фәлсәфәнең танып белү (гносеология) позииясеннән аңлау (герменевтика) позициясенә күчәргә тиеш дип чакыра.

✔ Кеше гомере буена, беренчедән, тәҗрибә туплый, (әйтергә кирәк аның күпчелек өлешен башка буын туплаган тәҗрибә тәшкил итә, — «дөнья тәҗрибәсе"), икенчедән, «дөнья тәҗрибәсенә” үз өлешен кертә.

✔»дөнья тәҗрибәсе”н үткән буыннан бүгенгесенә һәм бүгенгесеннән киләчәк буынга тапшыру, башлыча, китаплар аша - текстлар, “тел” аша башкарыла.

✔**димәк**, текстлар теленә төшенү, аны аңлау фәлсәфәнең әйдәп баручы юнәлешләренең берсе булырга тиеш.

## П.Рикер (р.1913) теориясе

**Төп положениеләр**

✔**Поль Рикер фәлсәфәсенең үзәк төшенчәсе — шәхес.** Лшәхес — барлык кешелек мәдәниятын иҗат итүче.

✔фәлсәфә максаты **— кеше субъективлыгын аңлау методын** барлыкка китерү.

✔шундый метод итеп Рикер "регрессив-прогрессив« методны тәкъдим итә, аның асылы кешене аның өч үлчәме - үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге аша аңларга кирәк дигәннән гыйбарәт.

✔ Рикер буенча, кеше шәхесе телеологик — киләчәккә юнәлдерелгән.

## 65нче сорау. Экзистенциализм (Кьеркегор, Ясперс, Сартр, Камю, Хайдеггерның экзистенциональ фәлсәфәсе)

## *1. Гомуми төшенчәләр. Экзистенциализм караган төп проблемалар.*

**Экзистенциализм** — фәлсәфә юнәлеше, анның төп предметы - кеше, анның проблемалары.

Экзистенциалистик фәлсәфә түбәндәге күренешләргә җавап булып туа. **Фәлсәфәче-экзистенциалистлар игътибар биргән пролблемалар:**

- ✔беренче бөтендөнья сугышы алдыннан, беренче һәм икенче дөнья сугышы вакытында һәм алар арсында кешелекне ялмап алган әхлакый, икътисадый һәм сәяси кризислар;
- ✔ Фән һәм техниканың көчле үсеше һәм техник казанышларны кешегә каршы куллану (хәрби техника, автомат, пулемет, мина, бомбаларны камилләштерү, хәрби хәрәкәтләр барышында агулы матдәләр куллану h.б.);
- ✔ Кешелек дөньясы һәлак булуы хәвефе (атом-төш коралы уйлап табу һәм куллану, якынлашып килүче экологик катастрофа);
- ✔ катылыкны көчәйтү, Кешегә карата кешелексез мөнәсәбәт (ике дөнья сугышында, концлагерь, хезмәт лагерьларында 70 миллион һәлак булуы);
- ✔тулысынча кеше шәхесен ихүче фашистик һәм башка тоталитар режимнар таралуы;
- ✔кешенең табигать һәм техноген җәмгыять алдында көчсезлеге.

Экзистенциализмтарафыннан каралган проблемалар

- ✔кеше шәхесенең уникальлеге, анын хисләре, кичерешләре, өметләренең, гомумән алганда тулысынча гомернең тирәнлеге;
- ✔ разительное противоречие между человеческим внутренним миром и окружающей жизнью;
- ✔ Кшенең ераклашу проблемасы (җәмгыять, дәүләт кеше өчен бөтенләй чит, кешене санга сукмаган чынбарлык, анын “минен” бастырыклый);
- ✔ Кешенең ялгызлыгы, ташланганлыгы проблемасы (кеше әйләнә-тирә дөньяда ялгызы гына, анын үзен иркен тоярга координат системасы юк;
- ✔ Тормышнын мәгънәсезлеге проблемасы;
- ✔эчке сайлау проблемасы;
- ✔ Кешенең үз эчке һәм тышкы «Минен» эзләү проблемасы — тормыштагы урынын.

## 2. Сьорен Кьеркегор фәлсәфәсе – экзистенциализмның барлыкка килүе

Экзистенциализмга нигез салучы Сьорен Кьеркегор фәлсәфәсе (1813-1855)

Экзистенциализм барлыкка килү сәбәпләре

Фәлсәфәче билгеләгән төшенчәләр

Чын яшәешне яралу вакытында кешенең өч баскычы

Ул шундый сорау куды: ни өчен фәлсәфә шулкадәр күп мәсьәләләре— яшәеш асылы, материя, Алла, рух, танып белү чикләре һәм механизмы белән шөгыльләнә — һәм бөтенләй диярлек кешегә игътибар бирми, алай гына да түгел, конкрет кешене аның эчке рухи дөньясы, гомуми, абстракт борчылулар белән, гадәттә, аны кызыксындырмаган һәм аның көндәлек тормыш мәсьәләләрендә эретә?
Кьеркегор фәлсәфә кешегә, аның кечкенә проблемаларына борылырга, аңа аңлаешлы һәм аның өчен яши алырдай хакыйкатьне табарга ярдәмләшергә, кешегә эчке сайлауда һәм үзенең “мин”ен аңларга ярдәм итәргә тиеш дип исәпләгән.

- чын булмаган яшәү — кешенең тулысында җәмгыятькә буйсынуы, “бөтенесе белән тормыш итү”, “башкаларныкы кебҗек үк тормыш”,«агым буенча йөзеп", үзенең аңсыз «Мин»еннән башка», шәхесенең кабатланмаслыгыннан башка, чын багланышын тапмыйча;
- чын яшәү — җәмгыять изүеннән чыгу, аңлы сайлау, үз-үзен табу, үз язмышы хуҗасына әйләнү.

- Эстетик чорда кеше тормышы тышкы дөнья тарафыннан билгеләнә. Кеше “агым буенча йөзә” һәм ләззәт алуга омтыла.
- Этик чорда кеше аңлы сайлау ясый, аеруча үзен сайлый, хәзер аны бурыч төшенчәсе хәрәктләндерә.
- Дини чорда кеше үзенең вазыйфасын тирән, тулысынча аңлый, тышкы дөнья аңа әһәмиятле түгел, ул аңа каршылык булып тора алмый. Шул вакыттан һәм соңгы көннәренә кадәр кеше барлык михнәтләрне һәм тышкы хәлләрне җиңеп “үз тәресен үзе алып бара” “(Иисус Христоска охшатып).

## *3. К. Ясперс фәлсәфәсе*

**Карл Ясперс** (1883 - 1969) – немец фәлсәфәчесе – XX гасырда иң беренчеләрдән булып экзистенцичлистик проблемаларны күтәреп чыга (1919 елда – беренче бөтендөнья сугышы тәмамлангач чыккан «Дөньяга карашлар психологиясе» китабында).

Фәлсәфә үзенчәлекләре

- ✔ Ясперска ярашлы, кеше «ташландык», мәгънәсе булмаган тормыш белән яши — «барысы кебек". Шул ук вакытта ул үзенең чынбарлыкта кем икәнен дә аңлап бетми, үзенең яшерен сәләтләрен, мөмкинлекләрен, чын «Минне» белми.
- ✔ Әмма аерым очракларда чын табигате, бирелгән яшерен сыйфатлары тышка чыга. Ясперс буенча, чиктәге ситуацияләр — тормыш һәм үлем арасында, кешегә мөһим булган, киләчәге өчен шһшмиятле булган ситуацияләр.
- ✔ Бу вакыттан кеше үзен таный һәм үз-үзенә әйләнә, ул трансцедентальлеккә кагыла — югары яшәеш белән.
- ✔ Кешенең барлык тормышы аңлы яки аңсыз рәвештә трансцеденциягә юнәлдерелгән — тулысынча энергиянең ирекккә чыгуына һәм ниндидер югары абсолютлыкка төшенүгә.
- ✔ Кеше транцеденциягә, абсолютка якынлаша, энергияне азат итә, үзен «трансцендентал ь “шимфрлар” аша үз-үзен аңлый.

Трансцедентал ь булганның «шифр»лары:
- эротика, секс;
- үзеңнен эчке дөньяң белән берлекүз-үзең белән килешеп яшәү);
- азатлык;
- үлем — яшәеш ахыры.

## 4. Ж. – П. Сартр фәлсәфәсе

**Жан – Поль Сартр (1905-1980) фәлсәфәсе һәм аның сайлау проблемасы. Фәлсәфәнең төп төшенчәләре һәм положениеләре:**

- ✔ Сартр фәлсәфәсенең үзәк төшенчәсе – «үзем өчен яшәеш».
- ✔ «Үзем өчен яшәеш" – кеше өчен иң югары чынбарлык, иң элек аның өчен үзенең эчке дөньясы беренчел булып тора. Әмма ул «башкалар өчен яшәеш» — башка кешеләр белән төрле мөнәсәбәтләр аша гына үзен тулысынча кеше итеп аңлый ала. Кеше «башка» берәүнең мөнәсәбәте аша гына үзен күрә һәм кабул итә.
- ✔ Кеше яшәешенең мөһим шарты, аның “үзәге”, активлык нигезе — азатлык.
- ✔ Кеше үз азатлыгын табып, аны сайлауда тормышка ашыра, тик гадидә түгел, икенчелдә (мәсәлән, бүген нинди кием кияргә), ә тормыш өчен әһәмиятледә, язмыш хәлиткечтә, кайчан карар кабул итеүдән баш тартып булмый, (яшәү һәм үлем мәсьәләсе, экстремаль ситуацияләрдә, кеше өчен тормыш өчен хәлиткеч мәсьәләләрдә). Мондый хәл итү карар төрен Сартр экзистенциаль сайлау дип йөртә. Экзистенциаль сайлау кабул итеп, кеше үзенең язмышын бик күп еллар алга билгели, бер яшәештән икенчесенә күчә.
- ✔ Бөтен гомер — төрле «кечкенә тормышлар» чылбыры, үзенчәлекле «тѳеннәр» белән тоташтырылган төрле яшәеш өзеге— экзистенциональ карaралар белән. Мәсәлән: һөнәр, тормыш иптәше, эш урыны сайлау, һөнәрне алыштыру карары, көрәштә катнашырга карар кажул итү, сугышка бару һ.б.лар
- ✔ Сартр буенча, кеше азатлыгы абсолют (ягъни нисбәтсез). Кеше тели алганга күрә генә дә ирекле. Мәслән, төрмәдә утырган кеше ни булса да теләгән чакта ирекле: төрмәдән качараг, утыруын дәвам итәргә, үз үзенә кул салырга теләгәндә. Кеше ирекле булырга дучар ителгән ( теләсә нинди хәлләрдә, тышкы чынбарлыкка буйсынудан тыш, ләкин бу да сайлау булып тора).
- ✔ Азатлык проблемасы белән беррәттән җаваплылык проблемасы да туа. Кеше эшләгән һәр нәрсә өчен, үз-үзе өчен җаваплы («Минем белән булган бөтен нәрсә, — минеке").
- ✔ Бердәнбер нәрсә өчен кеше җавап бирә алмый, — үзенең тууы өчен. Әмма башка барлык нәрсәдә дә ул ирекле һәм ирке белән бар җаваплылык белән кулланырга тиеш, аеруча экзистенциональ (язмышны хәлиткеч) сайлау ясаганда.

## 5. А. Камю фәлсәфәсе

**Альбер Камю (1913-1960) һәм аның мәгънә проблемасы**

Төп положениеләр:

- ✔ Кеше гомере асылында мәгънәсез. Күпчелек кешеләр үзләренең кечкенә хәстәрләре, шатлыклары белән, дүшәмбедән якшәмбегә кадәр яшиләр, еллар үтүән саен гомеренә максатчан мәгънә бирмичә. Ә кемнәр тормышларын мүгънә салганнар, энергия сарыф итәләр, алга омтылалар, һәм иртәме, соңмы алда үлем торганын аңлыйлар. Бернәрсә. Барысы да үләчәк — гомерләрен мәгънә белән тутыручылар да, тутырмаучылар да. Кеше гомере – абсурд(мәгънәсез) (тәрҗемәдә нигезе булмаган).
- ✔ Нәтиҗәдә гомер мәгънәсе, Камю буенча, тышкы дөньяда түгел( уңыш, уңышсызлык, үзара мөнәсәбәтләрдә), кешенең үз яшәешендә.

Мәгънәсезлек дәлиле, тормышның нисбәтсез булуы:

- үлемгә кагылу — аңа кагылганда, аеруча кинәт һәм якыннан, күп нәрсә, элегрәк кеше өчен әһәмиятле тоелганнар, - мавыгулар, карьера, байлык — үзенең әһәмиятлелеген югалта һәм мәгънәсез, яшәеш өчен тормаган итеп тоела;
- әйләнә-тирә дөнья, табигать белән кисешү — кеше меңәр ел яшәп килгән табигать алдында көчсез («мин үләннәр исен тоям һәм йолдызларны күрәм, тик Җирдәге бернинди белем дә миңа бу дөнья минеке булуына ышаныч бирми").

## 6. М. Хайдеггер фәлсәфәсе

Мартина Хайдеггер (1889 — 1976) фәлсәфәсе (фәлсәфә предметы һәм бурычын экзистенционалистик аңлау нигезләрен үзен эшкәртү белән шөгыльләнә)

Фәлсәфәнең төп төшенчәләре һәм положенияләре:

- Экзистенция, Хайдеггер буенча, - кеше үзен караткан яшәеш, кеше яшәеше конкретлык белән тулы булуы; аның тормышы нәрсәсе бар, шунда, бу аның өчен асыл булып тора да инде.
- Кеше яшәеше әйләнә-тирә дөньяда бара (фәлсәфәче тарафыннан «дөньядагы яшәеш”дип атала). Үз чиратында «дөньядагы яшәеш” түбәндәгеләрдән тора:
- "Башкалар белән яшәеш" кешене үзен эченә суырып ала, аның тулысынча ассимиляцияләнүенә, шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, “барысы да кебек”кә әйләндерүгә юнәлтелгән.
- «Үз-үзенең яшәеше» «башкалар белән яшәеш» белән бер ук вакытта «Мин»нең башкалардан аерылып торганда гына мөмкин.
- Димәк, кеше үз-үзе булып калырга теләп, «башкаларга» каршы торырга тиеш, үзенең охшашлыгын якларга тиеш. Бары тик шул вакытта гына ул ирекле булачак.
- Әйләнә-тирә дөньяда үзенең охшашлыгыңны яклау – кешенең төп мәсьәләсе һәм хәстәре.

## 7. Экзистенциализм киләчәге

Экзистенциализм фәлсәфәсе үсешенең алшартлары

- Экзистенциализм фәлсәфәсе хәзерге Көнбатыш Европада бик популяр һәм аның өчен актуаль
- Хәзерге вакытта проблемасы, аның әйләнә-тирәдәге тормышы, үз-үзен эзләве, кабатланмаслыгын саклау, яшәү мәгънәсенә бәйле фәлсәфи тикшеренүләрнең кеше авырлык үзәге кушылу тенденциясе күзәтелә.
- Әлеге проблематика (кеше тормышы, аның проблемалары) киләчәктә материя һәм аңның беренчеллеге проблемасын икенче планга этәреп, фәлсәфәнең төп мәсьәләсенә әверелергә мөмкин.